ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МГАРИФ ИДАРӘСЕ

# ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘРГӘ НИГЕЗЛӘНГӘН ТАТАР ТЕЛЕ һәм ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕ

## Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән

**2017**

**Проект җитәкчеләре:**
***Шәмсетдинова Р.Р.,*** *Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, доөент, филология фәннәре кандидаты*
***Һадиева Г.В.,*** *Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы*

**Төзүчеләр:**
***Сәләхова Р.А.,*** *ТР Зеленодол муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе укыту-методик булегенең мили мәгариф һәм төбәкара хезмәттәшлек буенча методисты*
***Сәлахова З.Ү.,*** *«ТР Зеленодол муниципаль районы 5 нче номерлы гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең милли эшләр буенча директор урынбасары, югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
***Зәйнуллина Р.К.,*** *«ТР Зеленодол муниципаль районы 7 нче номерлы гомуми белем мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең милли эшләр буенча директор урынбасары¸ югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
***Минһаҗева М.К.,*** *«ТР Зеленодол муниципаль районы 3 нче номерлы гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең милли эшләр буенча директор урынбасары, югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
***Нәҗметдинова М.Л.,*** *«ТР Зеленодол муниципаль районы 10 нчы номерлы гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең милли эшләр буенча директор урынбасары, югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Заманча технологияләргә нигезләнгән татар теле һәм әдәбияты дәресләре (Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) – Яшел Үзән: Прима – Колор, 2017. – 189 бит.

ПРИМА – КОЛОР, 2017

# ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# МИЛЛИ МӘГАРИФ СИСТЕМАСЫНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕ



*Роза Әбрар кызы Сәләхова,*
*Зеленодол муниципаль районы*
*Башкарма комитетының мәгариф идарәсе*
*укыту - методик булегенең милли мәгариф һәм*
*төбәкара хезмәттәшлек буенча методисты*

***«Укытучылар тырышлыгы - ил бавыры ныклыгы! »***
***Суфиян Поварисов***

Район мәгариф системасында 98 белем бирү оешмасы, шуларның 53-е мәктәпкәчә белем бирү оешмасы, 42-се мәктәпләр, 2-се өстәмә белем бирү үзәге. Районыбызда милли белем бирү оешмалары челтәре сакланып килә. 16 татар мәктәбе, 12 татар балалар бакчасы эшли.

Район мәктәпләрендә 14984 укучы укый: 4153-е (28,25%) татар, 2366-сы (15,8%) катнаш гаилә балалары, 8094-е (53,74%) рус милләтеннән, калганнары чуваш, мари, удмурт, башкорт, украин, әрмән, үзбәк, әзербәйҗан, таҗик милләтеннән. Район буенча татар балаларын туган телендә укыту 41,95% тәшкил итә.

Балар бакчаларында 8704 бала: 2583-е (29,6%) татар, 1613-е (18,53%) катнаш гаилә балалары, 4359-ы (50,08%) рус милләтеннән, калганнары чуваш, мари, мордва, башкорт, украин милләтеннән. Район буенча татар балаларын туган телендә тәрбияләү 24,42% тәшкил итә.

Әлеге проблеманы хәл итү максаты белән татар сыйныфлары, балар бакчаларында татар төркемнәре ачу өстендә эш алып барабыз.

Зеленодол муниципаль районы мәгариф идарәсе «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законына, «2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, үстерү» Дәүләт программасы нигезендә алып барыла. Районда телләрне саклау буенча муниципаль программа төзелде. Зеленодол муниципаль районында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү программасын тормышка ашыру буенча милли белем һәм тәрбия бирү өчен шартлар һәм мөмкинлекләр бар. Район милли мәгарифенең эше «Татар теле һәм әдәбиятын укытуда заманча инновацион укыту технологияләрен кулланып белем сыйфатын күтәрү» дип аталган методик тема өстендә оештырыла. Методик тема буенча эшнең нәтиҗәлелегенә ирешү максатында түбәндәге бурычлар куелды:

1. Укыту-тәрбия эшендә системалы рәвештә заманча технологияләр, инновацион алымнар, әйдәп баручы укытучыларның эш алымнарын, эш тәҗрибәләрен кулланып, белем сыйфатын күтәрү;

Укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү өстендә эшләү;

2. Конкурентлыкка сәләтле шәхес тәрбияләү;

3. Укучыларда татар халкының мәдәниятенә, тарихына мәхәббәт, милли үзаң тәрбияләү.

Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик берләшмә эше өч юнәлештә алып барыла:

- татар мәктәпләрендә татар телен һәм әдәбиятын укыту;

- рус мәктәпләренең татар төркемнәрендә татар телен һәм әдәбиятын укыту;

- рус төркемендә татар телен һәм әдәбиятын укыту.

Ел дәвамында тематик семинарлар, практикумнар уздырыла.

Районда милли мәгариф эшчәнлеге берничә юнәлештә алып барыла:

1. Аналитик эшчәнлек (методик эшне оештыру, планлаштыру, анализ ясау);

2. Укытучылар белән эшне оештыру (өйрәту характерындагы, тематик семинарлар уздыру, методик ярдәм күрсәтү, белем күтәрү курслары);

3. Сәләтле балалар белән эш (сәләтле укучылар базасын булдыру, олимпиадалар, конференцияләр, бәйгеләр уздыру);

4. Укучыларны бердәм республика һәм дәүләт имтиханнарына эзлекле әзерләү;

5. Ана телендә белем һәм тәрбия бирү өчен шартлар тудыру (балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп арасында дәвамчанлык эшен булдыру, татар сыйныфларын, татар төркемнәрен ачу, ата-аналар белән эшне тиешле дәрәҗәдә оетыру);

6. Төбәкара хезмәттәшлек эшен алып бару, элемтәләрне киңәйтү.

Район мәктәпләрендә 197 татар теле һәм әдәбияты укытучысы эшли. Нигездә, район мәктәпләре кирәкле күләмдә педагогик кадрлар белән тәэмин ителгән. 98,5% укытучы профилле югары филологик белемле. 68,52% укытучы югары һәм беренче категорияле: 24 (12,2%) - югары, 111 (56,34%) укытучы – беренче категорияле. Бу сан республиканың гомуми күрсәткечләреннән югарырак (республика буенча күрсәткеч – 67%).

Милли мәгарифне үстерү юнәлешендә алып барыла торган эшнең күп төрлелеген һәм шул ук вакытта нәтиҗәле икәнен республика күләмендә үткәрелгән олимпиадаларда, бәйгеләрдә, конференцияләрдә укытучылар һәм укучылар яулаган уңышлар раслый.

Методик эшнең әһәмиятле юнәлеше булып педагогларның профессиональ осталыгын күрсәтү конкурсларында һәм грантларда катнашуларын оештыру тора. Ел саен татар теле һәм әдәбияты укытучылары һөнәри бәйгеләр һәм грантларда катнашалар.

2017 нчы елда республика укытучылары профессиональ үсешен тәэмин итү гранты кысаларында җиңүчеләр: «Укытучы – яшьләр җитәкчесе»/ «Учитель-наставник» номенациясендә Нәҗметдинова М.Л., 10 нчы гимназия; Гайсина С.И., 16 нчы мәктәп (2016 нчы елда шулай ук 2 укытучы җиңүче булдылар). 2016 нчы елда Приоритетлы милли проект «Мәгариф»/ ПНП

«Образование» җиңүчесе – 10 нчы гимназия укытучысы Нәҗметдинова М.Л. булды.

Сәләтле балалар белән ресурс үзәкләрендә системалы эш алып барыла, нәтиҗәләр дә шатландыра: Республика дәрәҗәсендә татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадада – 10 җиңүче һәм призер, татар теле һәм әдәбияты буенча Халыкара олимпиадада - призер, Бөтенроссия дәүләт телләре олимпиадасында – 4 призер, милли мәктәпләр өчен үткәрелә торган рус теле һәм әдәбияты буенча Халыкара олимпиадада – 4 призер. Болар барысы да белем бирүнең сыйфат күрсәткече.

Балаларга милли белем – тәрбия бирүдә шулай ук дәрестән тыш үткәрелә торган чаралар зур әһәмияткә ия. План буенча районда ел саен фәнни-гамәли конференцияләр, бәйгеләр, фестивальләр уздырыла:

К.Насыйри исемендәге Халыкара фәнни - гамәли конференция;

Регионара фәнни - практик конференция «Танылган татарлар»;

Регионара фәнни - практик конференция «Тау ягы шәхесләре»;

А. Шамов исемендәге укулар;

Ф. Шәфигуллин исемендәге укулар, һ.б.

Милли мәгарифнең әһәмияткә ия булган тагын бер тармагы – чит төбәкләрдәге милләттәшләребез белән тыгыз элемтәдә, һөнәри бердәмлек булдыру. Яшел Үзән районы мәктәпләре Россия Федерациясенең 10 регионыннан 20 мәктәп белән килешүләр нигезендә хезмәттәшлек итә. Регионнардан укытучылар районыбызда үткәрелә торган фәнни-гамәли конференцияләрдә ел саен актив катнашып киләләр. Шулай ук район мәктәпләре укытучылары интернет аша семинарларда, конференцияләрдә дими катнашып киләләр. 2017 нче елның март аенда районыбызның өч укытучысы Курган өлкәсендә профилле лагерда укучыларга татар телен укытып кайттылар.

Регионара хезмәттәшлек кысаларында быелгы уку елында ике семинар уздырылды: 10 нчы гимназия базасында «Дәресләрдә һәм дәрестән тыш чараларда инновацион методика һәм технологияләр кулланып укучыларның коммуникатив компетенцияләрен үстерү» темасына һәм «Укучыларда мили үзаң формалаштыру һәм толерантлык тәрбияләүнең актив формалары» темасына Зөя гомуми урта белем мәктәбе базасында.

Укытучыларга методик ярдәм күрсәтү максатыннан ел дәвамында өйрәтү характерындагы, алдынгы тәҗрибә уртаклашуга юнәлтелгән муниципаль, республика семинарлары, практикумнар, стажировкалар уздырыла.

Яшел Үзән районы мәктәбе укытучылары татар теле дәресләрендә шәхескә якын килү, проблемалы укыту, коммуникатив технология һәм башка инновацион алымнарны уңышлы кулланалар.

Әлеге җыентыкка заманча технологияләрне уңышлы кулланган татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсен чагылдыра торган, семинарларда тәкъдим ителгән дәресләрдән методик эшкәртмәләр тәкъдим ителә.

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЕРЫМ ФӘННӘР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН 11 НЧЕ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**



**14 нче сентябрь, 2016 нчы ел**

Зеленодол муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен практик семинар
**«Татар теле дәресләрендә телне аралашу чарасы буларак өйрәтү»**

Практический семинар для учителей татарского языка и литературы общеобразовательных организаций Зеленодольского муниципального района
**«Татар теле дәресләрендә телне аралашу чарасы буларак өйрәтү»**



***Татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен мастер – класс***

***Педагогика фәннәре докторы, Яр Чаллы педагогик технологияләр һәм ресурслар институты доценты, дәреслекләр авторы Хәйдәрова Роза Зәки кызы***

## IV сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

***Яруллина Илсия Шәүкәт кызы,***
***«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 11нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең 1 квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Тема:** Белем бәйрәме.
**Максат**:
1. «Белем бәйрәме» темасын күнегүләр системасы аша үзләштерү.
2. Сингапур укыту алымнарын кулланып, укучыларның тыңлап, аңлап сөйләм күнекмәләрен, аралашу күнекмәләрен, логик фикерләү сәләтләренен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын үстерү, укучыларның үз фикерләрен тиз һәм төгәл әйтә белүләренә ирешү, шулардан чыгып нәтиҗә ясый белүләренә ирешү.
3. Сыйныфта дустанә мөнәсәбәт булдыру; кешеләргә хөрмәт тәрбияләү.
**УУЭ**
**Регулятив:**
- укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү;
- кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- билгеләнгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү.
**Танып белү:**
- укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- төшенчәгә якын килү өчен нәтиҗә ясау.
**Коммуникатив:**
- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңлый һәм аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү;
- парлап эшли белү.
**Шәхси:**
- ярдәмчеллек, башка кешеләргә карата кайгыртучан булу.
**Җиһазлау:** мультимедиа экран, компьютер, ситуатив биремнәр, презентация.
**Кирәкле материаллар:**
**Дәреснең тибы:** яңа белем-күнекмәләрне ныгыту.
**Предметара бәйләнеш: тарих**
**Дәрес барышы:**
**1. Оештыру**
а) Исәнләшү, хәл сорашу. Хәерле көн, балалар!
Хәерле көн үземә.
Хәерле көн ике күземә,
Хәерле көн, әнигә,
Хәерле көн, әтигә,
Хәерле көн, сезгә.

б) уңай халәт тудыру.Үзебезне мактап китик әле. Мин акыллы, яхшы, әйбәт укучы. Мин татарча яхшы сөйләшәм, дөрес язам.

**II. Белемнәрне актуальләштерү. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.**

*(1нче слайд)*

**ТЭЙК ОФ – ТАЧ ДАУН** (втать-сесть)

(Әйтелгән җөмлә белән килешсәгез - басасыз, килешмәсәгез - утырасыз).

- Сез татарча яхшы сөйләшәсез. Көз житте. Бүген 14 нче сентябрь, чәршәмбе.
- Сез 3 нче сыйныфта укыйсыз. Дөресме?
- Юк, мин килешмим. Без 4 нче сыйныфта укыйбыз.
- 1 сентябрь - Яңа ел бәйрәме. Юк, мин килешмим, 1сентябрь - Белем бәйрәме. Вот раньше , ребята, Новый год действительно отмечали 1 сентября.Только при Петре I начали отмечать Новый год 1 января.Традиционно на Руси начинали учиться после оканчания полевых работ.

**Дәрескә максат һәм бурычлар кую.**

*(Смарт тактада 1 нче файл)*

Нинди бәйрәм турында сөйләшербез икән?

**Белем бәйрэме**

**Нәтиҗә: -** Әйе, бүген без дәрестә 1 сентябрь - Белем бәйрәме турында сөйләшәчәкбез.

**III. Яңа белем - күнекмәләр булдыру.**

**Уку мәсьәләсен кую.**

- Укучылар, бүген без Белем бәйрәме турында диалоглар төзербез, 1 сентябрь кемгә бәйрәм? Шул турыда фикерләрегезне тыңларбыз.

*(Смарт тактада 2 нче файл)*

**Уку мәсьәләсен чишү.**

1) **Сүзлек эше. http://tatarschool.ru/media/ktt4**

«Белем бәйрәме» темасы. Лексика бүлеге. 1нче кунегү.

**Бәйрәм, шат, күңелле, белем, уйный, яңа** сүзләренең тәрҗемәсен табу.Һәр сүз белән җөмлә төзетү.

1сентябрь-Белем бәйрәме. Балалар шат. Күңелле музыка уйный. Яңа уку елы башлана.

2 ) Ә хәзер *КОНТИНИУС РАУНД РОБИН* (продолжительный раунд робин) структурасы ярдәмендә мәктәп темасына үзегез сүзләр әйтәсез.

(1 укучы әйтә, 2 укучы беренче укучының сүзен кабатлый, һәм үзенекен әйтә, 1-2 рәткә бүленеп эшлибез).

3) **Сүзлек эше. http://tatarschool.ru/media/ktt4**

«Белем бәйрәме» темасы. Лексика бүлеге. 2 нче кунегү, 5, 6 нчы биремнәр.

5 нче бирем. Попроси себе эти предметы

6нчы бирем. Узнай нужны ли ему эти предметы.

4. Физкультминутка . **Ял минуты**. Без сезнең белән хәзер аз гына ял итеп алабыз. Моның өчен без *МИКС-ФРИЗ-ГРУП* структурасын кулланабыз.

- Барыбыз да бастык, урындыкларны рәтләдек,  бер әйләнә ясап басабыз. *(Смарт тактада вложениядэ)* «Өйрәтәләр мәктәпләрдә» җыры куела, сез шул музыкага бии-бии әйләнәсез. Музыка туктагач, үзегезгә пар табасыз.
- Сделайте друг-другу комлимент. Ул сиңа нәрсә диде? Маша миңа «Син бүген бик матур» - диде.
- Поздравьте друг-друга с Днем Знаний.
- Скажите свои пожелания друг-другу.
- Ул сиңа нәрсә диде?
- Ваня миңа бәхет , сәламәтлек телим диде.
- Ваня,дөресме? Мин аңа тагын күп акча телим дидем, (теләдем).
- Попроси себе какую-нибудь учебную принадлежность.Анжелика, аңа нәрсә кирәк?

Ул миңа дәфтәр кирәк диде.

**IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.**

Презентациядәге рәсемнәр буенча дилоглар төзү.

*( Смарт тактада 3 нче файл)* Слушаю диалоги в парах.

Чей диалог интересней?

1 диалог (разговор о подготовке к школе)

2 диалог (попроси тетрадь  у друга)

3 диалог ( поздравить с 1 сентябрем)

4 монолог (12 нче бит , 4 нче бирем)

**V. Рефлексия.** (*дәрескә йомгак ясау*).

1 сентябрь кемгә бәйрәм? Уку кемгә бәйрәм?

*(Смарт тактада 4 нче файл)*

Кем күбрәк түгәрәк җыйды? **Тырыш укучыга уку бәйрәме.**

Кем татарча иң яхшы сөйләшә ? Билгеләр кую.

## IV сыйныфта укучы рус балаларына  -  татар теле

***Мөхетдинова Илсия Ильяс кызы.,***
***«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 11нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәрес тибы:** ЛГКК

**Максаты:**

1. Сөйләм телен үстерү,
2. Фикерләү, күзәтә һәм нәтиҗә ясый белү сәләтен үстерү;
3. Укучыларда кеше хезмәтен хөрмәт итә белү сыйфатлары тәрбияләүне дәвам итү, икмәккә сакчыл караш тәрбияләү.

**Җиһазлау.** Дәреслек, сүзлекләр, компьютер, проектор, слайдлар

**Материал.**

1. Р.З. Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева. Татар теле. 8 нче сыйныф (рус телендә сөйләшүче балалар өчен дәреслек).

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру.**

- Исәнмесез, укучылар! ( Исәнмесез! )
- Хәлләрегез ничек? ( Рәхмәт, әйбәт! )

**2. Ишетеп аңлау күнегүе.**

- Укучылар, тыңлагыз, текстта сүз нәрсә турында бара? Сүзнең нәрсә турында барганын кемнәр аңлады ? ( Видиоязма куела)

**3. Дәрескә максатны балалардан куйдыру.** – Бүгенге дәрестә сүз нәрсә турында булыр икән? - Дөрес, укучылар, хезмәт турында.

**III. Яңа тема.**

*1.* – Әйдәгез, исебезгә төшерик әле. Һөнәрләр турында әйткәндә без нинди кушымчалар кулланабыз? *( - чы,- че )*

- Дөрес, ә кайсы очракта - чы кушымчасын ялгыйбыз, һәм кайсы очракта - че кушымчасын кулланабыз? *(калын, нечкә)*
- Яхшы. Укучылар, ә сез нинди профессияләр беләсез? *(Укытучы, сатучы, табиб һ.б. )*
- Дуслар, сезнең фикерегезчә, кайсы профессия кирәклерәк? *( Табиб, янгын сүндерүче),* ә җыештыручы? *( Кирәк).*
- Димәк, һәр һөнәр дә кирәкле һәм мактаулы!

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

1. **Мәкальләрне аңлатыгыз.**

- Биредәге мәкальләрне ничек аңлыйсыз? Үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

*Агач – җимеше белән, кеше – эше белән.*

*Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи.*

*Кем эшләми, шул ашамый.*

*Хезмәт төбе - хәзинә.*

*Ашаганың белән мактанма, эшләгәнең белән мактан.*

*Хезмәте каты - җимеше татлы.*

2. – Әйтегез әле, укучылар, дөньядагы бар әйберне сайлап буламы? *( Юк, әти-әнине, туган илне, тышкы кыяфәтне)*

- Әйе, бу әйберләрне сайлап алып булмый, ә менә киләчәкне, язмышны без сайлый алабызмы? *( Әйе )*
- Әйе, укучылар, профессия сайлау – язмыш сайлау дияр идем мин, чөнки мөстәкыйль тормыш юлы һөнәр сайлаудан башлана. Дуслар, ә сез нинди профессияләр сайлар идегез? *(1-2 укучы үз сайлаган профессия турында сөйли, 2 укучы табышмак формасында сөйли, калганнары һөнәрнең исемен атарга тиеш).*

3. **Ситуатив күнегүләр.**

- Укучылар, хәзер сез парлап диалог төзергә тиеш буласыз. 1,5 минут сезгә. Вакыт китте. (2 пар диалог сөйли ).

4. **Репликаларны куй.** (Укучыларга карточкалар таратыла)

Бирем: Җөмләләрдәге төшеп калган репликаларны куярга.

**V. Өй эшен бирү.**
- Укучылар, шундый ситуация. Сезнең дустыгызның киләчәген, аңа үзенә ошамаган профессияне әти һәм әнисе сайладылар. Ул аларны бик ярата һәм каршы тора алмый, ләкин алар сайлаган һөнәрне дә кабул итә алмый. Аңа нишләргә? Бу сорауга сез өйдә җавап табырсыз.
**VI. Йомгаклау.**
- Укучылар, бүгенге дәрестә без нинди максатларга ирештек*? ( Диалог сөйләргә өйрәндек).*
- Бу дәрестән сез үзегезгә нинди яңа материал алдыгыз?
- *Чыннан да, һәр һөнәр иясе, һәр хезмәт кешесе мактауга, хөрмәткә лаек.* Киләчәктә сезнең алдыгызга да: «Нинди һөнәр сайлыйм икән? » - дигән сорау килеп басачак. Нинди генә һөнәр сайласагыз да, аңа хөрмәт белән карарга, күңелегезне биреп эшләргә өйрәнегез.
- Дәрестә катнашканнарга билге куям. Дәрес тәмам. Сау Булыгыз!

## III сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

***Зарипова Миләүшә Хабибулла кызы,***
***Батталова Рамилә Габделхак кызы,***
***«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 11нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең 1 квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары***

**Тема: «Белем бәйрәме»**
Максат:
Предметка карата - Мәктәп турында сөйләргә өйрәтү
Метапредмет - укучыларның хәтерен, игътибарлылыгын, логик фикерләү сәләтен үстерү
Шәхескә кагылышлы - укучыларда төгәллек, җаваплылык кебек уңай сыйфатлар тәрбияләү.
Җиһазлау: дәреслек “ Күңелле татар теле” Р.З.Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова, Л.А.Гыйниятуллина,презентация, интерактив такта.
**1. Оештыру өлеше**
Исәнләшү.
Дежур белән әңгәмә.
- Исәнмесез, балалар. Хәлләрегез ничек?
- *Яхшы, рәхмәт. Ә сезнең хәлләрегез ничек?*
- Яхшы, рәхмәт. Утырыгыз. Бүген ничәнче числа? Урамда нинди ел фасылы? Бүген нинди көн?
- *Бүген 13нче сентябрь. Урамда көз ел фасылы. Бүген матур көн.*
- *Яңгыр ява. Җил исә. Кошлар җылы якка очалар. Агачлардан яфраклар коела. 10 градус җылы.*

- Көз нинди?
- *Алтын көз.*

*(1 - 8 слайдылар)*

**2. Актуальләштерү**

- Тактада сүзләр бирелгән. Артык сүзне табыгыз, һәм ни өчен артык икәнен аңлатыгыз.

*(9 нчы слайд)*

- *Артык сүз куян, чөнки калган сүзләр мәктәп темасына кагыла.*
- Димәк, дәрес темасы «Мәктәп»

*(10 нчы слайд)*

**3. Үткәнне кабатлау.**

2 нче сыйныфта өйрәнгәннәрне искә төшерәбез

- Сезнеңчә, 1нче сентябрь бәйрәмме?

*(11 нче слайд)*

- *Минемчә, 1нче сентябрь бәйрәм түгел.*
- Ни өчен?
- *Иртә торырга кирәк.*

*(12 нче слайд)*

- *Ә, минемчә, 1нче сентябрь бәйрәм.*

(13 нче слайд)

- Нинди бәйрәм?
- *1нче сентябрь - Белем бәйрәме. Күңелле бәйрәм.*

*(13-15 нче слайд)*

- Сез Белем бәйрәме белән кемнәрне котлыйсыз?
- *Без Белем бәйрәме белән укытучыларны, дусларны котлыйбыз.*
- Ничек котлыйсыз?
- *Кадерле укытучылар! Без сезне Белем бәйрәме белән котлыйбыз. Сезгә бәхет, исәнлек, уңышлар телибез.*

*(16 – 17 нче слайд)*

- 1нче сентябрь көнне без кая барабыз?
- *Без мәктәпкә барабыз.*
- Мәктәптә нәрсә башлана?
- *Мәктәптә уку башлана.*

*(18 – 20 нче слайд)*

**4. Ныгыту**

- Продолжите предложения

*Мин сине бәйрәм белән ... .*

*Сиңа уңышлар ... .*

*Синең күлмәгең бик ... .*

*(21нче слайд)*

**5. Сөйләм телен үстерү. Белемнәрне туплау** Диалог өстендә эш.

- Привет, Никита.
- Привет, Аня. Ты сегодня очень красивая!
- Да, сегодня праздник, День знаний.

- Я тебя с праздником поздравляю!
- Я тоже тебя поздравляю!

*(22 – 25 нче слайд)*

6. **Рефлексия** .

**-** Без нәрсә турында сөйләштек?

Дәреслек белән эш.

7. **Йомгаклау.** Белемнәрне бәяләү. Үзбәя. Сез әфәринме?

Өй эше: диалог_____ көн. ______ бит

Балалар, дәрестә сез бүген яхшы эшләдегез.

**VI сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле**


***Сибгатуллина Рәфидә Дамир кызы,***

***Адиятуллина Алсу Рәшит кызы,***

***«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 11нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең 1 квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***


**Тема:** Яңа уку елы белән!

**Дәрес тибы**: Диалогик,монологик сөйләм.

**Дәрес максатлары:**

**1. Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):** үзеңнең уку – язу әсбапларыңның барлыгы-юклыгы турында әйтә белү,үзеңә сорап алу,иптәшеңә тәкдим итү күнекмәләрен сөйләмдә куллану , бәйрәм белән котлый белү.

**2. Үстерү максаты** (дәреснең метапредмет нәтиҗәсе): уку хезмәтендә үзеңә максат куя,бурычларны билгели белү; нәтиҗә ясый белү; парларда һәм күмәк эшли белү күнекмәләрен үстерү.

**3. Тәрбия бирү максаты (**дәреснең шәхси нәтиҗәсе): аралашу этикетын булдыру

**Җиһазлау**: дәреслек «Татар теле » 6нчы сыйныф. Авторлар: Р.З. Хәйдәрова, З.Р. Нәҗипова,__Казан: « Татармультфильм»_2014 ел; методик ярдәмлек, дәрескә әзерләнгән презентацион материаллар.

**Дәрес барышы.**

**1. Оештыру.**

1) уңай психологик халәт тудыру;

2) дежур укучы рапорты;

**2. Белем күнекмәләрен актуальләштерү.**

- Хәзер җыр тыңлап алабыз,сезгә нинди таныш сүзләр бар, игътибар белән тыңлагыз, дәрес темасын билгеләгез.

- Димәк , без бүген сезнең белән нәрсә турында сөйләшәбез. Әйе.бик дөрес, **яңа уку елы**, мәктәп турында сөйләшербез.

*(Слайд)*

Дәрес мәсьәләләре (без өйрәнергә тиеш):
1) Беренче тукталышта без уку-язу әсбапларын сорап ала белергә тиеш;
2) Икенче тукталышта сез иптәшегезгә уку-язу әсбапларын тәкъдим итә белергә тиеш**;**
3) Өченче тукталышта сез диалог төзергә тиеш.
Укытучы: Киттекме? Әйдәгез киттек.
Укытучы: Башта өйрәнелгән сүзләрнең тәрҗемәсен, дөрес әйтелешен искә төшереп алыйк.
*(Слайд)*
Яңа уку елы - [йаңа уку йылы]
Котлыйм - [къотлыйм]
Уңышлар - [уңошлар]
Яңгырый - [йаңгърый]
Сәламәтлек - [сәләмәтлек]
килешә - [килешә]
Укытучы: уйлап карагыз әле, балалар, транскрипция ни өчен кирәк? Дети, для чего нужна транскрипция? *(көтелгән җавап: Для того чтобы правильно читать, произносить слова).*
Укытучы: Ә хәзер тактадагы сүзләрне кулланып, кунакларны,бер-берегезне яңа уку елы башлануы белән котлап алыйк әле (*көтелгән җавап: балалар бер берен,кунакларны котлый.)*
Мин дә барыгызны яңа уку елы башлануы белән котлыйм.
Укытучы: Мәктәптә белем бәйрәме бик күңелле узды, сез минем белән килешәсезме? Бәйрәм көнне яңгыр яуды. Бәйрәмдә Татарстан гимны яңгырамады (*көтелгән җавап: килешәм яки килешмим җаваплары әйтелә*).
Укытучы: Сез бүген бик матур киенеп килгәнсез! Әйдәгез, кәефебезне тагын да күтәреп җибәрик әле, бер - берегезгә комлиментлар әйтик әле. Сүзләр кабатланмаска тиеш *(көтелгән җавап: укучылар бер – берсенә комплиментлар әйтәләр)*
Сезгә мактау сүзләре ошадымы? Миңа бик ошады. Ул сүзләрне дусларыгызга, эти-әниегезгә, туганнарыгызга ешрак әйтегез! *(көтелгән җавап: балалар парларда эшлиләр).*
Укытучы: Ә сез яңа уку елына әзерме соң?
*(Слайд)*
Мәктәпкә нәрсәләр алдыгыз? Бер –берегездән сорагыз. Кемнең сүзлеге,кемнең китабы юк. Кайдан алабыз?
Укытучы: Мин сезне бүген сәяхәткә, уку-язу әсбаблары кибетенә чакырам. Без бүген поезд белән башкалабыз Казан шәһәренә барырбыз. Моның өчен сезгә билетлар алырга кирәк.
Билетларның төсләренә карап үз вагоннарыгызга утырыгыз. Укытучы: бу гади генә билетлар түгел, бу универсаль билетлар. Билетларның икенче ягында бәяләү шкаласы. Һәрбер этапта (тукталышта) үзегезгә билгеләр куя барасыз.
Укытучы: Укучылар, әйтегез әле: китап, дәфтәр, каләм, сүзлек безгә ни өчен кирәк? (*көтелгән җавап: уку-язу өчен кирәк).*

Димәк, без дәрестә нәрсә турында сөйләшербез?
**1) Аудиоязма. Ишекләр ябыла киләсе тукталыш – «Китап дөньясы» тукталышы.**
Укытучы: Укучылар, ә хәзер сезнең мәктәпкә барыр өчен нәрсәләр бар икәнен тикшереп карыйк?
**ЦОР:** Скажи, какие из этих предметов у тебя есть, каких нет. Һәрбер командадан бер укучы чыга.
Укытучы: Сезнең бөтен әйберләрегез бар икән. Бик яхшы!
Әйдәгез балалар бергә әйтеп карый әле.
Беренче команда кабатлый: Минем дәфтәрем бар.
Икенче команда: Минем китабым бар. Өченче команда: Минем сүзлегем бар. *(көтелгән җавап: Минем дәфтәрем бар, минем китабым бар. Минем сүзлегем бар..)*
Укытучы: Молодцы. Бу тукталышта үзегезгә билге куегыз.
2) **Аудиоязма. Сак булыгыз, ишекләр ябыла, киләсе тукталыш,**
**«Канцтовар кибете» тукталышы. Вагон төсенә карап үз биремегезне сайлап алыгыз.**
*(Слайд)*
Ситуатив күнегү:
1) Купим вместе тетрадь;
2) Купим вместе ручку;
3) Купим вместе дневник.
Укытучы: Билетларны алдык, бу тукталышта үзегезгә билге куегыз.
**5. Ныгыту этабы:**
**Киләсе тукталыш «Әйдә сөйләшик» тукталышы**
1. Таратма материаллар белән эшләү.
Укытучы: Һәрбер командага, алдыгызда диалог бирелгән. 2 минут вакыт бирелә, музыка уйный.
Диалогны тулыландырыгыз.
Диалог:
- Синең китабың бармы?
- *Әйе, минем китабым бар.*
- Миңа китап бир әле?
- *Мә,ал.*
- Рәхмәт!
Парда эшләү, билетларны алдык бу тукталышта үзебезгә билге куйдык.
**6. Йомгаклау, бәяләү.**
Укытучы: Давайте вспомним, какие задачи мы сегодня решили?
*(Слайд)*
Дәрес мәсьәләләре (без өйрәнергә тиеш):
1) Беренче тукталышта без уку-язу әсбапларын сорап алырга белергә өйрәндек;
2) Икенче тукталышта без иптәшебезгә уку-язу әсбапларын тәкъдим итергә өйрәндек**;**
3) Өченче тукталышта диалог төзедек.

Укучылардан сорау;
1) Как ты скажешь, есть ли у тебя книга?
2) Попроси у друга ручку
Булды! Әфәрин! Ә хәзер билгеләрне санагыз!
9 - 10 - «3»
10 - 12 - «4»
14 - 15 - «5»
**7. Өй эше:** Составить диалог: яңа уку елы белән!

1. из 4 реплик.
2. из 6 реплик.
3. из 8 реплик и более.

## II сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

***Ильясова Миннәзия Тимергали кызы,***
***«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 11нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең 1 квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

### Дәреснең технологик картасы

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сыйныф | 2б | | |
| Төркем | Рус төркеме | | |
| Число | 14.09.2016 | | |
| Дәреслек | Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Н. Г. Галиева Татар теле. 2 нче сыйныф: Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен) Казан: «Татармультфильм» нәшрияты, 2013. | | |
| Дәреснең темасы | «Без мәктәпкә барабыз» | | |
| Дәреснең максаты | Метапредмет – уку – язу әсбапларының атамаларын дөрес кулланып диалогик һәм монологик сөйләмгә чыга алу.<br>Предмет – әлеге бүлектә өйрәнгән материалны кабатлау, үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү.<br>Шәхескә кагылышлы – укучыларда туган тел , тирә – юньгә сакчыл караш тәрбияләү, үз эшең, тырышлыгың белән горурлану хисләрен булдыру | | |
| Планлаштырылган нәтиҗәләр | Предмет | Метапредмет | Шәхескә кагылышлы |
| | Мәктәп | укучыларның | укучыларда |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турында сөйләргә өйрәтү | хәтерен, игътибарлылыгын, логик фикерләү сәләтен үстерү | төгәллек, җаваплылык кебек уңай сыйфатлар тәрбияләү |
| Дәрес төре | ЛГКК | | |
| Җиһазлау | Р.З. Хәйдәрова" Татар теле", (4- 10 битләр ); дәрескә әзерләнгән презентацион материаллар; | | |

| **Дәрес этабы** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Формалаштыры-лачак универсаль гамәлләр** |
|---|---|---|---|
| 1. Оештыру - мотивлаштыру | *Укучыларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру.*<br>- Хәерле көн, укучылар!<br>- Кәефләрегез ничек?<br>- Бүген ничәнче?<br>- Дәрестә игътибар белән тыңларга, бер-берегезне бүлдермәскә, тулы җавап бирергә, үз фикереңне әйтергә кирәк. | *Дәрескә игътибарлы булу.*<br>- Хәерле көн!<br>- Бик яхшы.<br>-14 нче сентябрь | Коммуникатив: укытучы һәм сыйныфташлары белән теләктәшлек планлаштыру |
| 2. Актуальләштерү | Укучылар тактага карагыз әле. Безнең хәрефләребез үз урыннары югалтканнар. Әгәр аларның урыннарын дөрес билгеләсәк ,дәресебезнең темасы Ачыкланыр | Балалар җавап бирә.<br>МӘКТӘП – темасы | Танып-белү: иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру<br>Коммуникатив: тыңлый белү, фикер алышуда катнашу.<br>Регулятив: күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.Үткәнне кабатлау. 1 нче сыйныфта өйрәнгәннәрне искә төшерәбез | Портфельне җый! Балалар без мәктәпк ә барыр алдыннан портфельгә уку – язу әсбапларын тутырабыз. Безнең портфельдә нинди предметлар бар икән. Слайд буенча уку- язу әсбапларын кабатлау. Ә хәзер үзегезнең парталарыгызга карагыз , шушы предметлар бармы? Кем әйтә? Партада нәрсә бар? | Предметлар-ның исемнәрен кабатлыйлар | Танып-белү: Аңлый белү, кирәкле мәгълүматны таба белү. Коммуникатив: Коллектив фикералышуда катнашу Регулятив: кагыйдә, интсрукцияләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу. |
| 4. Ныгыту | Үткән дәрестә безгә Шүрәле нинди сүзләрне истә калдырырга кушты? Сүзләр: (кирәк, кирәкми, (кирәкме) Ә хәзер дусларыгызга бу предметлар кирәкме,әллә кирәкмиме? Ничек | Укучыларның җавабы. Сиңа китап кирәкме? Миңа китап кирәкми Ә нәрсә кирәк? | Танып-белү: иҗади характердагы проблеманы чишү юлларын мөстәкыйль эзләү Коммуникатив: үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү Регулятив: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сорарсыз? | | |
| 5. Сөйләм телен үстерү. Белемнәрне туплау | Безнең портфель җыелды инде. Без каябарабыз? Ничәнче сентябрьдә барабыз, 1 сентябрь нинди бәйрәм. Ул көнне без нинди булабыз? Әйдәгез бер – беребезгә комплимент әйтәбез. Диалог сөйләмгә чыгу. Допустим син урамда дустыңны очраттың, аның кызыксынасың (ул кая бара, ничәнче сыйныфта укый) Кайчан мәктәпкә барабыз (көз көне) , Ә хәзер сезнең партaларда көзге яфраклар, алар серле. Һәр пар биремне укый җавап бирә, диалог төзи -Твой друг пошел в школу, спросить куда | Укучыларның диалоглары, җаваплары Син бүген бик матур! | Танып-белү: Белемнәрне структуралаштыру Коммуникатив: Мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү, иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү Регулятив: үзконтроль, биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | он пошёл?<br>- Поздравить друга с Днём Знаний<br>- Спросить у друга вежливо , 1 сентября какой праздник?<br>Спросить у друга куда он пошёл и предложить вместе пойти? | | |
| 6. Рефлексия | - Без нәрсә турында сөйләштек?<br>Сез бүген әфәриннәр, диалог сөйләмгә чыга алдыгыз, безнең арада бәйләнешле сөйләм туды<br>Экранда «Сез булдырдыгыз» дигән язу. | Бер – берең сорау бирә белделәр.<br>Бирелгән эшләрне башкардылар | Танып-белү:<br>туган проблеманы иҗади характерда чишү юлларын табу.<br>Коммуникатив:<br>әйтергә теләгән фикереңне сөйләм нормаларына китереп формалаштыру.<br>Регулятив:<br>Коррекция |
| 7. Йомгаклау | 1. Белемнәрне бәяләү. Үзбәя. | | Регулятив:<br>үз эшчәнлегеңне контрольгә алу |

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ 7 НЧЕ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**



**15 нче сентябрь, 2016 нчы ел**

Зеленодол муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре
татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен практик семинар
**«Федераль белеем бирү стандартлары нигезендә татар теле дәресләрен заманча проектлаштыру»**

Практический семинар для учителей татарского языка и литературы
общеобразовательных организаций Зеленодольского муниципального района
**«Проектирование современного урока в условиях внедрения ФГОС»**



***Татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен мастер – класс***

***Педагогика фәннәре кандидаты, КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты, дәреслекләр авторы***
***Фатхуллова Кадрия Сөнгать кызы***

## II сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

***Измайлова Зөлфия Хәлиулла кызы,***
***«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының 7 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Тема: Мәктәптә**
**Максат:** Укучыларның мәктәп турында белемнәрен системалаштыру, сүзләрне аңлап сөйләмдә куллана белү; укучыларның уйлау – фикерләү сәләтен үстерү; укучыларда үзара дуслык, ярдәмчеллек хисләре тәрбияләү.
**Җиһазлау:** компьютер, экран,тема буенча презентация, рәсемнәр, татар теле дәреслеге**.**
Дәреслек: К.С.Фәтхуллова «Татар теле һәм уку китабы» (Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 2нче сыйныфы өчен дәреслек –рус балалары өчен) Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2013нче ел

**Дәрес барышы:**
**I. Укучыларда уңай психологик халәт тудыру.**
Укытучы: Исәнмесез, укучылар! Хәерле иртә! Кәефләрегез ничек?
*Кояшлы иртә кебек.*
*Тукай телен, татар телен*
*Өйрәнергә дип килдек.*
**Диалог: укытучы - укучы**
- Синең исемең ничек?
- *Минем исемем....*
- Син кайда укыйсың?
- *Мин мәктәптә укыйм.*
- Син ничәнче мәктәптә укыйсың?
- *Мин җиденче мәктәптә укыйм.*
- Син ничәнче сыйныфта укыйсың?
- *Мин икенче сыйныфта укыйм.*
- Дәрестә сез нишлисез?
- *Язабыз, укыйбыз, тыңлыйбыз, сөйлибез, җырлыйбыз.*

**2. Фонетик күнегү.**
[о ]-[ө ] [а ]-[ә ] [ж ]-[ч ] [в ]-[w ] – авазларын дөрес әйтү күнегүләре.
Укытучы: Бик яхшы, балалар. Минем арттан сүзләр кабатлыйбыз.
*өйрәнә, әйтә, җавап бирә, тәнәфес, вакыт, аңлый, тыңлый.*

**II. Актуальләштерү.**
Укытучы: Укучылар, әйдәгез өй эшен тикшереп үтик. Укучылар өй эшен тикшерәләр, дөреслеге экраннарда күрсәтелә.
***(****Слайд)*
Слайдка карыйбыз. Анда бирелгән сүзләрләрне укыйбыз,тәрҗемә итәбез:
*Укый*

*Тыңлый*
*Аңлый*
*Сүз*
*Күнегү*
*Мисал*
**(***Слайд)*
Текст.
Укытучы: Ә хәзер, балалар, текст укыйбыз һәм тәрҗемә итәбез.
*Дәрестә без татарча сөйләшәбез. Без укыйбыз, сөйлибез, язабыз. Без укытучыны тыңлыйбыз.Ул татарча җөмләләр әйтә, ә без кабатлыйбыз. Без татарча аңлыйбыз. Татар теле - матур тел.*
Укытучы: Укучылар тактага хәрефләр язылган. Шул хәрефләрдән нинди сүз төзеп була? Уйлап карагыз әле.
К, Ә, П, Ә, М, Т.
*«МӘКТӘП» сүзе.*
- Безнең мәктәп нинди? *(зур, яңа, матур,чиста)*
- Мәктәп ничә катлы? *(өч катлы)*
- Мәктәпнең беренче катында нәрсәләр бар?
- Димәк безнең бүгенге дәреснең темасы нинди?
- Мәктәп.

**II. Яңа белемнәрне үзләштерү.**

**1. Яңа сүзләр өстендә эш:** *(Тактада сүзләр язылган)* Балалар сүзләрне эчтән һәм кычкырып укыйлар.
*белә - знает*
*өйрәнә - изучает*
*әйтә - говорит*
*сорау бирә - задает вопрос*
*җавап бирә - отвечает*
*тәрҗемә итә - переводит*
*тәнәфес - перемена*

**2. Яңа сүзләр белән җөмләләр төзү.**

*Мин татарча беләм.*
*Укытучы сорау бирә.*
*Балалар җавап бирә.*
*Малай тәрҗемә итә.*
*Мин матур укырга, язарга өйрәнәм.*
*Катя татарча сүзләрне дөрес әйтә.*
*Тәнәфестә без уйныйбыз, йөгерәбез, сикерәбез.*

**3.Физкультминут.**

*Матур сүзләр уйладык,*
*Ял итәргә туктадык.*
*Җилкәләрне турайттык,*
*Тирән итеп суладык,*
*Башны як-якка бордык,*

*Чүгәләдек һәм тордык***.**

**4.** Ишек шакыган тавыш ишетелә.

Укытучы: Балалар бу кем икән?

Су анасы керә.

- Исәнмесез, балалар.

- *Исәнмесез. Түрдән узыгыз. Рәхим итегез.*

- Рәхмәт балалар. Сезне сагынып килдем әле. Ә сез мине таныдыгызмы, мин кем?

- *Су анасы.*

- Әйе, балалар, мин Су анасы. Ә «Су анасы» әкиятен кем язган?

- Габдулла Тукай язган.

*(Слайд)*

Габдулла Тукай портреты.

- Габдулла Тукайның нинди әкиятләрен, шигырьләрен беләсез? *(балалар җавап бирәләр).*

-Татар халкының бөек шагыйре Г.Тукай бик күп әкиятләр, шигырьләр язган. Балалар аларны бик яратып укыйлар.

Су анасы:

- Рус балалары мәктәптә татар телен өйрәнәләр дип ишеттем. Дөресме бу? *(балалар җавап бирәләр).*

- Ә минем рус телен өйрәнәсем килә. Миңа ярдәм итегез әле укучылар. Бу сүзләрне тәрҗемә итеп бирегез әле.

*(Су анасы сүзләрне русча укый, балалар тәрҗемә итәләр)*

*знает*

*задаёт вопросы*

*отвечает*

*пишет*

*разговаривает*

*слушает*

Су анасы балалардан кабат-кабат сүзләрнең тәрҗемәсен сорый, кабатлый.

- Бу сүз тәрҗемәсе ничек була әле ,балалар, онытып та җибәргәнмен - дип яңадан сүзләрне кабатлата.

- Рәхмәт сезгә балалар. Мин бу сүзләрне инде онытмам. Сез дә исегездә калдырыгыз.

- Балалар, сез минем әкияттәге малайга нинди булырга киңәш итәр идегез?

- *Әдәпле бул, тәртипле бул, акыллы бул.*

- Мин бу сүзләрне аңа әйтермен. Ә мин китим инде. Сау булыгыз.

**III. Яңа белемнәрне ныгыту.**

***1. Артык сүзне табу.***

Балалар сүзләрне укыйлар, тәрҗемә итәләр,артык сүзне табалар.

*а) укый, кабатлый, җәй, аңлый*

*ә) өйрәнә, кечкнә, сөйләшә, белә*

***2. Рәсемнәр буенча җөмләләр төзү.***

*(Слайд)*

- Балалар, бу кем?
- *Бу Саша.*
- Ул нишли?
- *Саша яза.*
- Димәк ул нинди малай?
- Ә бу кем?
- *Бу Наташа. Наташа китап укый.*

**3. Матур язу күнегүе.**

Бу Саша. Ул яза.  Бу Наташа. Наташа китап укый.

Ни өчен кайбер сүзләрне баш хәреф белән яздыгыз?

-*Чөнки алар кеше исемнәре.*

- Әйе.

**4. Җөмләне дәвам итү.**

*(Слайд)*

*(Экраннан дөреслеген тикшерәләр)*

- Мин татарча ... .
- Дәрестә без ... .
- Без татарча яхшы ... .
- Тәнәфестә без ... .
- Без мәктәпне ... .

**IV. Рефлексия.**

- Дәрестә сез бүген нәрсәләр өйрәндегез?
- Дәреснең кайсы өлеше сезгә ошады?
- Ни өчен?

-Үзегезгә нинди яңалыклар алдыгыз?

**V. Өй эше.**

1. Яңа сүзләрне истә калдыру.
2. 7нче бит, 3нче күнегү.
3. Г.Тукайның «Су анасы» әкиятенә рәсем ясап килергә.

**VI.Үзбәя.** Смайликлар тарату. Укучыларга үзләренең белемнәрен бәяләргә тәкъдим итәм.

Яшел смайлик - биремнәр минем өчен җиңел булды - «5» ле куела.

Сары смайлик - биремнәр үтәгәндә кыенлыклар туды - «4» ле куела.

Кызыл смайлик - минем өчен авыр булды - «3» ле куела.

## «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ 5 НЧЕ ГИМНАЗИЯСЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ



**12 нче октябрь, 2016 нчы ел**

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләренең квалификация күтәрү курсларын тыңлаучы татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен республика семинары

**«Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә һәм дәрәстән тыш чаралар аша укучыларда төп компетенцияләр формалаштыру»**

Стажировка учителей татарского языка и литературы общеобразовательных организаций Республики Татарстан – слушателей курсов повышения квалификации

**«Формирование базовых компетенций учащихся на уроках татарского языка и литературы и во внеурочное время»**



***Республика мәктәпләрененнән татар теле һәм әдәбияты укытучыларының тәҗрибә уртаклашу мәйданчыгы***

## V сыйныфта укучы татар балаларына - татар теле

***Сәләхова Зөлфирә Үрнәк кызы, Нәҗипова Тәнзилә Марс кызы,***
***«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының***
***5 нче гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү***
***учреждениесенең югары квалификацион категорияле***
***татар теле һәм әдәбияты укытучылары***

**Дәрес темасы: Алынмалар.**

**Дәреснең максаты**: «Татар телендә алынмалар» темасы аша уку танып-белү мотивациясе формалаштыру, түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү өчен укучылар эшчәнлеген оештыру:

**Шәхескә кагылышлы:**

Татар теленең эстетик кыйммәтен аңлау; туган телгә карата хөрмәт, горурлык хисләре тәрбияләү; туган телнең чисталыгын саклау ихтыяҗы булдыру;

Сөйләм камиллегенә омтылу; аралашу процессында фикер һәм хисләрне иркен җиткерә алуда сүзлек запасының, үзләштергән грамматик чараларның җитәрлек дәрәҗәдә булуы; сөйләм теленә бәя бирә белү.

**Метапредмет:**

Сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләренә ия булу: сөйләү һәм уку: телдән һәм язма мәгълүматлар, текстның темасы, төп фикер; төп һәм өстәмә мәгълүмат);

текст укуның төрле төрләренә ия булу (эзләнү, карау, танышу, өйрәнү) ;

массакүләм мәгълүмат чаралары, Интернет ресурслар аша төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү; төрле типтагы сүзлекләрдән, белешмә әдәбияттан иркен файдалана алу; билгеле бер темага материал таба һәм системалаштыра белү; мәгълүматларны мөстәкыйль таба алу;

уку һәм сөйләү һәм тыңлау нәтиҗәсендә туплаган мәгълүматны үзгәртә, саклый, җиткерә белү;

эчтәлеге, стилистик үзенчәлекләреннән чыгып, сөйләм текстларын чагыштыра белү; сөйләү һәм язу булдыру: алда торган уку эшчәнлегенең максатын билгели алу (индивидуаль һәм күмәк), эшчәнлекнең эзлеклелеге, ирешелгән нәтиҗәләрне бәяләү һәм аларны телдән һәм язма сөйләмдә формалаштыру; телдән һәм язмача төрле типтагы текстлар төзи алу;

телдән һәм язма формада үз фикереңне иркен һәм дөрес җиткерә алу (логик, эзлекле, бәйләнешле, темага туры килү һ.б. ); әйләнә-тирә чынбарлыктагы фактлар, күренешләр турында укыган, ишеткән, күргәннәреңне адекват җиткерү;

**Предметара:**

Телнең төп функцияләрен , тел һәм халыклар культурасын, кеше һәм җәмгыять тормышында телнең ролен күзаллау ;

текст формалаштыру үзенчәлекләрен аңлау, текст төзегәндә тел-сурәтләү чараларын уңышлы куллану;

**Бурычлар.**

**Өйрәтү:**
төшенчәләрне формалаштыру күнекмәләрен үстерү;
тексттан алынмаларны таба белү күнекмәләрен үстерү;
сөйләмдә алынмаларны куллана белү күнекмәләрен формалаштыру;
алынмаларның этимологиясен билгеләү күнекмәләрен үстерү;
укучыларның сүзлек байлыгын арттыру;
орфографик күнекмәләрне камилләштерү.
**Үстерелешле**:
укучыларда тәнкыйди фикерләү тәрбияләү;
укучыларда игътибарлылык тәрбияләү ;
УУГ формалаштыру (шәхсиятле, регулятив, танып-белү):
үз фикереңне тәгъбир итә һәм исбат итә белү;
анализ ясый, чагыштыра, йомгаклый алу күнекмәләрен үстерү;
яңа белемнәрне куллана белү күнекмәләрен үстерү;
укучыларның иҗади һәм сөйләм күнекмәләрен үстерү;
логик фикерләү күнекмәләрен формалаштыру;
билгеле булган яки субъектив тәҗрибәңә таяна белү күнекмәләрен үстерү ;
проблеманы формалаштыра белү күнекмләрен үстерү;
төркемнәрдә һәм парлап эшләү күнекмәләрен үстерү.
**3.Тәрбияви**:
туган телгә карата кызыксыну һәм хөрмәт уяту;
сүз кыйммәтен бәяләргә өйрәтү;
коммуникатив УУГ үстерү:
кызыксынучанлык, теләктәшлек, хөрмәт һәм хезмәттәшлек итү өчен уңай шартлар тудыру;
укучыларны төркемнәрдә һәм парлап эшләү эшчәнлегенә тарту: бер-беренә хөрмәт тәрбияләү.
Дәрес тибы: Уку максаты кую
Укучылар эшчәнлеге формалары: индивидуаль, парлап, төркемнәрдә
**Техник чаралар**: ПК; проектор
**Уку - укыту курсында теманың тоткан урыны:** 5 нче сыйныфта лексикология бүлегенә 21 сәгать тәкъдим ителә. Алынмаларга тематик бүленештә бер сәгать вакыт бирелгән. Курс эчендә ул 12 нче сәгать буларак өйрәнелә Укучылар сүзгә – телнең төп берәмлеге буларак билгеләмә бирәләр. Төрки-татар сүзләре һәм алынма сүзләр сүзләр арачсындагы аерма үзенчәлекләрен ассызыклыйлар.
Бәяләү критерийлары: Укучылар дәрес барышында системалы- эшлекле якын килү хисабына “үзтамга” җыя. Дәрес башында бәяләү критерийлары белән танышалар.
11 - 12 балл - «5»
9 - 10 - «4»
7 - 8 - «3»
**Дәреснең төзелеше һәм барышы**
I. Мотивлаштыру - ориентлаштыру.

А) психологик уңай халәт тудыру.
- Исәнмесез укучылар, татар теле дәресенә рәхим итегез.
*Гыйлемлелек яшерен хәзинә,*
*Кем таба, ике дөнья байлыгы булыр аңа.*
*Шундый байлык ул гел өстәп тор аны*
*Ул сарыф иткән саен арта бара.*
*Габдрахим Утыз Имәни*
Бүгенге байлыкның авырлыгы (бонус)
11 - 12 балл - «5»
9 - 10 - «4»
7 - 8 - «3»
ә) белемнәрне актуальләштерү.
1 нче максат. Укучыларның орфографик белем камиллеген тикшерү. Шаблон буенча үзара тикшерү, үзбәя.
- Сезнең алдыгызда беренче номерлы карточкалар ята. Төшеп калган хәрефләрне куярга кирәк.
Карточка №1. Сәл..м, х...рмәт, т...лефон, сәг...ть, бә...ет, тракт...р, к...яфәт, җ...мга, кәг...зь, җә...нәт, фон...тика, якш...мбе, м...нитор, ят...м, кә..ф, мәхә...бәт, орфо...пия, ...лма, д...шәмбе, б...бай, б...ркет.
2 нче максат. Сүзләрне төркемләгәндә, укучыларның нинди база белемнәренә таянуын ачыклау.
- Карточкадагы сүзләрне төркемләп карагыз әле, укучылар. Сезнең нинди төркемнәр килеп чыкты?
(төрле вариантлар килеп чыгарга мөмкин. (язылышы, әйтелеше, хәрефләр уртаклыгы, хаталар китү мөмкинлеге, сүзләрнең мәгънәсенә игътибарны юнәлтеп, татар сүзләре икәү генә (алма, укучы, ә калганнары башка телләрдән кергән, алынган дигән фикергә китерү көтелә).
Укучыларга мөстәкыйль фикерләү, сүзләрне вариантларга төркемләү өчен вакыт бирелә.Үзбәя.

| ? | ? | ? |
|---|---|---|
| Сәлам, хөрмәт, , сәгать, бәхет, , кыяфәт, җомга, кәгазь, җәннәт, якшәмбе, ятим, кәеф, мәхәббәт, дүшәмбе, | телефон, трактор, фонетика, монитор, орфоэпия, | бабай, алма, бөркет |

-Укучылар, берничә төрле бүленеш килеп чыкты. Кемдә бүленеш 2 вариантта, кул күтәрегез әле, ә кемдә 3 вариантлы бүленеш? Игътибарыгызны тактага юнәлтегез әле, миндә 3 төркемле таблица, тик аларның исемнәре юк. Нәрсәне күздә тотып, мин 3 төркемгә бүлдем икән?
Укучыларның җаваплары тыңланганнан соң, сорау куелган урыннарга дөрес җавап куеп барыла.

| Гарәп - фарсы | Рус теле | Татар теле |
|---|---|---|

- Беренче, икенче баганадагы сүзләр турында нәрсә әйтеп була?
- Алар башка телләрдән алынганнар.

Уку мәсьәләсен куеп карагыз әле, языгыз. Сезнең фикерләрегез нинди? Дәфтәрегезгә языгыз.

II. Уку мәсьәләсен кую. Алынмалар.

Бу терминның төгәл мәгънәсен аңлау өчен, Татар теленең аңлатмалы сүзлегенә мөрәҗәгать итик әле,укучылар.(укучылар басма һәм электрон сүзлекләрдән алынма сүзенең аңлатмасын карыйлар)

Чыннан да , сез бүгенге уку мәсьәләсен дөрес билгеләдегез.

Уку мәсьәләсен адымлап чишү.

1нче адым.

Бу мәсьәләне чишү өчен, без берничә сорауга җавап табарга тиешбез.

Сораулар сезнең 2 нче номерлы карточкагызга урнаштырылган.

1. Татар теленә алынмалар ничек килеп кергән?

- Алынма сүзләрне куллану кирәкме?

Тел алынмалардан башка яши аламы?

Эзләнү өчен материал.

Татар телендә алынмалар.

Бер генә халык та аерым, изоляцияләнеп яши алмаган. Элегрәк башка кабиләләр белән аралашу, соңга таба төрле халыклар, дәүләтләр белән аралашу нәтиҗәсендә татар теленә теге яки бу телдән алынмалар килеп кергән.

Татар әдәби теленә көнчыгыш халыклары белән төрлечә тарихи бәйләнешләргә керү, аралашу җирлегендә һинд, кытай сүзләре (*алма, әрдәнә, җиз, сан, тәңре, энҗе, түбән, чан, хан, чәй, җуа, дәү, юан, шан, чын, чирү, дию*), монгол теленнән (*чаган, нохта, дилбегә, нөкер*) сүзләр үтеп керә һәм ныклап урнашып кала.

Татар телендә фин-угор телләреннән кергән алынмалар да шактый. Мәсәлән, *пилмән, бүкән, миләш, морж, пошц, пурга, норка, килька, салака, пихта, камбала*.

Татар телендә саны һәм активлыгы белән гарәп, фарсы һәм рус алынмалары аерылып тора.

Татар телендә гарәп һәм фарсы алынмалары.

Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән алынмалар хәзерге телебездә дә бик күп санлы; ә борынгырак чорда, бигрәк тә XVII-XVIII гасырларда, алар тагын да күбрәк булганнар. Бу алынмалар Болгарда ислам дине кабул ителгәннән соң сәүдә, дин, сәясәт, мәдәният, әдәбият-сәнгать бәйләнешләре аша килеп кергәннәр.

X гасырга чаклы ук Болгарга гарәп сәүдәгәрләре, сәяхәтчеләре килә башлаганнар. Алар сәүдә иткәннәр, ислам динен тотканнар, мәчетләр, мәдрәсәләр ачканнар, гарәп язуына, гарәп теленә өйрәткәннәр. XIII-XIV гасырларда Алтын Урда һәм гарәп илләре, аерым алганда, Мисыр арасында сәүдә, мәдәният мөнәсәбәтләре көчәйгән. Сарайда һәм Алтын Урданың бүтән мәдәни учакларында бик күп галимнәр, шагыйрьләр һәм әдипләр яшәгән һәм

иҗат иткән. Мондый күренешләр болгарлар теленә тәэсир итми калмаган, әлбәттә.

Кайбер алынмалар телебездә ныклап урнашып калганнар, татарлашканнар, яңа сүзләр ясау өчен нигез булып хезмәт итә башлаганнар. Әйтик, гарәп теленнән кергән тәртип, ватан, хат, рәсем, сабыр сүзләре.

Татар телендә рус алынмалары

Төркиләр славян халыклары белән тыгыз бәйләнештә яшәгәннәр. "Игорь полкы турында җыр"да ук иде төрки сүзләрне күрергә була. Төркиләр славяннардан күп кенә сүзләрне кабул иткәннәр: *арыш, мүк, буразна, уҗым, эскерт, әвен, мич, сохарый, чиркәү* һ.б. Славян халыкларына да төрки сүзләр күпләп кергән: *айран, алтын, аманат, амбар, арка, аул, балык, барс, богатырь, деньга, джигит, камыш, караван, карандаш, кетмень, кирпич, лошадь, утюг, ямщик, ясак* һ.б.

Рус алынмалары Казан ханлыгы яулап алынганнан соң күпләп кабул ителә. Рус сүзләренең татар теленә кабул ителүе берничә чорга бүлеп карала:

I чор - борынгы чор - Казан ханлыгы алынган чор (IX-XVI гасыр);

II чор - Казан ханлыгы алынганнан соң XVIII гасыр азагы;

III чор - XVIII гасыр азагы - беренче рус революциясе;

IV чор - октябрь революциясе чоры;

V чор - октябрь революциясеннән соңгы чор.

Нәтиҗәләрне карточкаларга ук теркәп барырга була? (Укытучы- фасилитор консультациясе Инсерт алымы куллану.)

1нче нәтиҗә. Ислам дине кабул итү аркасында гарәп- фарсы алынмалары, славяннар белән тыгыз мөнәсәбәттә яшәү нәтиҗәсендә, Иван Грозный яулап алулары сәбәпле рус алынмалары, рус теле аша Европа телләре алынмалары кергән.Үзбәя.

2,3 нче нәтиҗә. Укучыларның җаваплары тыңлана. Үзбәя.

2 нче адым. Дәреслек белән эш. 147 нче бит, 497 нче күнегү.

3 нче адым. 498 нче күнегү.

Бирелгән алынмаларның синонимнарын табу өчен, Сезгә аңлатмалы сүзлектән мәгълүмат әзерләнде. Ул 3 нче номерлы карточкада. Алынма сүз белән аңлатманы туры китерергә кирәк булачак. Төркемнәрдә тикшерү.Үзбәя.

4нче адым. Модельне тутыру

Алынмалар

? ?

Алынмалар

Рус теле аша Европа сүзләре гарәп - фарсы алынмалары

IV. Өй эше

500 нче күнегү- мәҗбүри

501, 502 нче күнегүләр - сайлап алу характерында

V. Рефлексия



Чәнти бармак – чамала. Мин бүген нинди белем алдым?
Атсыз бармак – аңла. Мин нәрсә эшләдем һәм нәрсәгә өйрәндем?
Урта бармак – уйла. Минем кәефем нинди иде? Ул ничек үзгәрде?
Имән бармак – исеңә төшер. Мин кемгә булыштым, бәлки миңа булышканнардыр?
Баш бармак – билгелә. Ә сәламәтлегемне саклау турында уйландыммы?

## IV сыйныфта укучы татар балаларына – әдәби уку

***Җиһаншина Җәмилә Хаҗиахмәт кызы,***
***«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының 5 нче гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары***

Әдәби уку. 4 нче сыйныф.
Тема. Р.Вәлиева. Ямь-яшь кенә бөдрә ак каен...
Максат.
1.Әдәби әсәрне анализлауның гади ысулларын кулланып, авторның яшерелгән фикерен табарга өйрәтү.
2. Иҗади фикерләү сәләтләрен үстерү өстендә эш алып бару.
3. Укучыларда игелеклелек, шәфкатьлелек тәрбияләү.
Белем чыганагы: М.Х.Хәсәнова, И.Х. Мияссарова. Уку китабы. 54 бит. Аудиокитап. А.Г. Яхин. Әдәбият теориясе.
Өйрәнелә торган әсәр: Р.Вәлиева. “Ямь-яшь кенә бөдрә ак каен...” шигыре.
Предметара бәйләнеш: әйләнә-тирә дөнья, музыка.
Планлаштырылган нәтиҗә:
Яңа мәгълүмат туплауда дәреслек белән эшли белү; сүзлекләр кулланып аңлап уку, тыңлау, ишеткәннәрнең асылына төшенү; әдәби әсәр эчтәлеге буенча үз фикереңне җиткерү, чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларны билгели белү.
**Дәрес барышы:**
**I. Ориентлашу-мотивлаштыру.**
1. Уңай психологик халәт тудыру.
- Балалар, әйдәгез, барыбыз да матур итеп басып, бер-беребезгә елмайыйк. Шушы елмаю көн буена җитәрлек көч бирсен.
2. Актуальләштерү.
-Укучылар, минем бүгенге дәресне *“Иптәшең үзеңнән яхшы булсын”* дигән мәкаль белән башлап җибәрәсем килә. Аңа нинди мәгънә салынган икән? (балалар җавабы)
**II. Уку мәсьәләсен кую.**
- Ә хәзер, балалар, бүген укыячак әсәребезнең исемен ачыклыйк әле. Моның өчен парларда ребусны чишәргә кирәк. (*Ребус чишелә һәм әсәрнең исеме ачыла)*
- Димәк дәресебезнең темасы нинди булыр икән?

- Сезнеңчә, шигырьдә сүз нәрсә турында барыр?
- Укылган мәкальнең шигырь белән нинди бәйләнеше бар дип уйлыйсыз?
- Бу сорауга җавап эзләү өчен нишләрбез икән? Димәк үз алдыбызга нинди максат куябыз? (максат куела, балаларның җавабы тактага языла)

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

1. *Шагыйрә иҗаты белән танышу.*

- Игътибар итегез әле, аны кем иҗат иткән? Шагыйрә турында нәрсә беләсез? Әйдәгез, Р.Вәлиева иҗаты белән танышып чыгабыз. (Парларда эш: кыскача биография укыла һәм җаваплар тыңлана)

2. Шигырь өстендә эш.

а) *үрнәк уку (аудиоязма)*

– укучылар, игътибар белән тыңлагыз һәм сәнгатьле уку алымын истә калдырырга тырышыгыз.

б) *үзлектән уку*

-Укучылар, хәзер сүзлекчәдән файдаланып, үзлектән укып чыгабыз.

-Аңлашылмаган сүзләр бармы? (аңлашылмаган сүзләр булса, аңлатмалы сүзлек белән эш оештырыла)

*сүзлекчә*

искитмәле дәва бәгърем телгәләнде

в) *инсерт (тамгалап уку)*

– Укучылар, шигырьдә нинди хисләр яшерелгән? Нинди тавыш төсмерләре белән укырбыз? Әйдәгез, парларда уйлап карагыз әле ( шигырь укыла һәм билгеләп барыла)

г) *сайлап уку*

- шатлыклы тавыш белән кайсы юлларны укырбыз?
- борчулы, кайгылы, үкенүле тавыш белән укый торган юлларны эзләп карыйк әле (Беркөн килсәм...- йөрдем мин)
- гаҗәпләнү хисләре кайда яшерелгән? Нәрсәгә гаҗәпләнә?
- кайсы юлларда шелтәле тавыш төсмере?
- кайсы юлларны ышанычлы тавыш белән укырбыз? Нәрсәгә ышана ул?

г) *катнашучыларны табу һәм вакыйгаларны ачыклау*

- Хәзер катнашучыларны барлыйк әле. Ә төп геройлар кемнәр соң? Алар турында нәрсә белдек?

***КАТНАШУЧЫЛАР***

бала каен автор

(вакыйгалар сурәтләнеше тактага языльп бара)

- Балага нинди сыйфатлар хас? Ни өчен?

➢ уңай * уңай
➢ тискәре

– Ни өчен малай уңай герой булды?
– Аңа нинди тискәре сыйфатлар хас? Дәлилләгез.

д) *Эпитетлар табу*

- Әйдәгез, эпитетларны табыйк әле.

яшь-яшь каен ап-ак бөдрә каен нечкә билкәе

| | | |
|---|---|---|
| бөдрә башы | искитәрлек хәлләр | яраланган каен |
| ак каен | хәлсез башкае | явыз куллар |
| чын дус | сынган күңел | |

– Игътибар белән эпитетларны укыгыз һәм ике өлешкә бүлегез (баганалап бүлү, балалрның фикерләрен тыңлау)
– Ә әсәрне ничә өлешкә бүлеп булыр? (2)
– Ни өчен? Дәлилләгез.
– Бу сорауга җавапны табу өчен кайсы эпитет ярдәмгә килде? (явыз куллар)
- Аларга нәрсә кирәк булган соң?
- Явыз куллар кылган гамәлгә кемнәр ярдәмгә килгән? (чын дуслар)
- Димәк, нинди сүз яшерелгән икән? (дус, дуслык)
- Сез, дус, дуслык сүзләрен ничек аңлыйсыз? (аңлатмалы сүзлек белән эш)
- Димәк, автор безгә нинди фикер әйтергә теләгән?
– Без сезнең белән авторның әйтәсе килгән фикерен ачыкладык. Әдәбият дәресләрендә аны ничек атыйлар әле?
– *Укучылар, мәкаль белән шигырь арасында нинди бәйләнеш булды икән?Шушы бәйләнешне "Синквейн"уены белән дәлилләп күрсәтегез әле ( төркемнәрдә эш, җаваплар тыңлана)*

**IV. Рефлексия.**

-Укучылар, бүгенге дәрестән сез нинди хисләр белән китәсез? Үзегезгә нинди нәтиҗә ясадыгыз?

- Әйдәгез, "Уңыш баскычында"үзебезнең урыныбызны билгелик.

– Иң югары баскычта кемнәр булды?
– Уртада?
– Ә кемнәр баскычның түбәнге өлешендә калды?

**V.** Дәрескә йомгак.

*"Чын дус" җыры яңгырый*

**VI. Өй эше.**

1. Шигырьне сәнгатьле укырга.
2. *Дуслык турында уйларыгызны, күзаллауларыгызны кәгазьгә төшерегез.

## VI сыйныфта укучы татар балаларына – әдәбият дәресе

***Гатауллина Айгөл Әнәс кызы,***
***«Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының 5 нче гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары***

Тема: Г.Камалның «Беренче театр» әсәрендә сюжет каршылыгы.

Максат: Галиәсгар Камалның «Беренче театр» әсәрендә көлке тудырган сәбәпләрне ачыклау. Мөстәкыйль рәвештә логик фикерләргә өйрәнү. Анализ

нәтиҗәсендә әсәрнең сюжет хәрәкәтен табу. Укучыларда юмор хисе, бер-береңә карата ихтирам тәрбияләү.
Көтелгән нәтиҗә: «Беренче театр» әсәренә анализ ясап, үзенчәлекләрен аңлата алу.
Дәрес барышы:
Мотивлаштыру-ориентлашу.
Уңай психологик халәт тудыру;
а) Исәнмесез, укучылар. Хәерле көн. Утырыгыз. Бүгенге дәресебезне күтәренке кәефтә башлап җибәрик, аның темасы да сез ярата торган жанр – комедиягә багышланган. Дәреснең шартларын аңлатып үтәм: - пьесаны эчтәлеген тулысынча белү;
- биреләчәк сорауларга төгәл һәм тулы җавап бирү;
- күренешләрне анализлау, конфликтны табу.
Әлеге шартлар үтәлә икән, сез бүгенге дәрестә 5 балл иясе булачаксыз.
ә) белемнәрне тигезләү
- Узган дәреснең УМ нинди иде әле?
Көтелгән нәтиҗә: Узган дәрестә Г.Камалның ни өчен нәкъ менә комедияләр остасы буларак танылуын ачыкларга тырыштык.
- Мисал китерегез.
(Узе турында сөйләгәннәрдән мисал китерелә – 231 нче бит)
- Әйе. Шулар язучыны сәхнә сәнгатенә тарта, пьесаларында үз заманының мөһим мәсьәләләре һәм кешеләрне борчыган уй-сораулар чагылыш таба. Нәтиҗә ясыйбыз: Г.Камал комедияләре иске гадәт-йолаларның тискәре якларын күрсәтә (1 балл)
б) белемнәрне актуальләштерү
- Өйгә бирелгән эшне тикшерәбез. Нинди биремнәр иде әле?
Г.Камал исемендәге театр тарихында “Беренче театр” куелышы – кызлар. Әлеге театрда катнашкан артистлар турында мәгълүмат тупларга.
Тикшерәм. Төркемдәгеләр җавап бирә. Үзбәя.
- Яхшы. Ә хәзер әсәрнең төзелешенә (композициясенә) игътибар итик. Әсәр 4 күренештән тора. 4 сендә дә бер үк вакыйга – җыенып, театрга китеп бару кабатлана. Һәр күренешнең үз геройлары бар һәм алар парлы: 1-2 нче күренешләрдә ирле-хатынлы, 3 нче күренештә егет белән кыз, 4 нче күренештә хуҗа белән асрау. Бибидән башка һәр персонаж үз күренешләрендә генә катнаша һәм сәхнәгә кире әйләнеп кайтмый. Бирем мондый: Биби әсәрә нинди әһәмиятле роль уйный? Уйлар өчен 2 минут вакыт бирелә. (Укучылар, Бибинең әсәрдәге вакыйга – күренешләрне бәйләп торучы персонаж икәнлеген исбатларга тиеш.)
Нәтиҗә: Әсәрнең фокусы – безгә күренми торган җепләр белән Биби барлык күренешләрне үзенә туплаган. Моңа ул һәрвакт үзе каршылык китереп чыгаруы ярдәмендә ирешә. (2 балл)
- Биби образы нинди соң?
- Көлке хәлләргә очрап торучы комик образ.

- Дәреслекне ачыгыз, автор тарафыннан катнашучылар исемлегендә ул нинди итеп бирелә?
- Аңгыра кыз.
- Сез автор белән килешәсезме?
- Әйе.
- Исбатлагыз. (4 минут вакыт бирелә. Нәтиҗә: Укучылар киресен исбатлый: Биби аңгыра түгел, ә күренеш саен бары тик дөресен сөйләве ачыклана.) 3 балл.
- Укучылар, әлеге эшчәнлегегездән чыгып бүгенге дәрескә нинди УМ куяр идегез?
- .....................
- Яхшы. Сезнең алда слайд. Анда пальто – бизәнү әйберләре – күлмәк; бозау – тиеннәр (акча) – тычкан; егет белән кыз; бай һәм асрау рәсемнәре бирелгән.

Әлеге детальләргә күз салыгыз, әсәр буенча нәрсә әйтә аласыз?

- Эчтәлек ачыла.
- Әйе. Бүгенге дәреснең темасы Г.Камалның «Беренче театр» әсәрендә сюжет хәрәкәте. Дәфтәрләргә число, тема языла.

Сезнең алда карточкалар бирелгән. 4 төркемгә бүленгән эш. Һәр төркем 4 күренештәге дә конфликтларны билгеләргә һәм аларның хәл ителешен язып куярга тиеш. (5 минут) (Тикшерелә – Вәли үзем генә театрга барам дип куркыта, шулай итеп театрга китә. Тамашачы бу урында алар өчен борчылып утыра. 2) Факиһә – “эти орышса мине орыша”, дип җаваплылыкны үз өстенә ала. 3) Фатихның асрау белән сөйләшүеннән ачыклана. 4) Әсәрдә яңалыкның искене җиңү тантанасы бирелә. Төркемнәргә гомуми бирем: әсәрдәге төп конфликт ны билгеләргә.

Нәтиҗә: Тетрга теләсә ничек барырга әзер торучы Вәли һәм көне буе спектакльне куйдырмас өчен чабып йөргән Хәмзә бай арасында. 236 нчы бит, дәреслек – 10. Автор каршылыкны геройларны очраштырмый гына чишеп куя һәм бу әсәрнең идеясен ачуга китерә : (58 нче бит – теория, тарих китабы) 4 балл

- Ә әгәр дә Вәли белән хәмзә бай очрашкан булса?
- Бу комедия булмас иде.

III. Рефлексия, бәяләү.

Дәресне йомгаклыйбыз. Бүгенге дәрестә сез ничә кешегә ярдәм иттегез? Дәрестә нәрсә үзләштердегез? Үзалдыгызга нинди максат куйдыгыз? Ничек ирештегез? Әсәрне бүгенге көндә дә ни өчен актуаль дип саныйсыз? Әлеге әсәр тормышта сезгә нәрсә бирә?

Белемнәрне бәяләү: Баллар **(слайд )** Көндәлекләрне ачыгыз һәм балларыгызны санагыз, билгене көндәлекләрегезгә куегыз.

Өй эше

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «14 НЧЕ ЛИЦЕЙ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**



**12 нче октябрь, 2016 нчы ел**

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләренең квалификация күтәрү курсларын тыңлаучы татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен республика семинары
**«Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә һәм дәрәстән тыш чаралар аша укучыларда төп компетенцияләр формалаштыру»**

Стажировка учителей татарского языка и литературы общеобразовательных организаций Республики Татарстан – слушателей курсов повышения квалификации
**«Формирование базовых компетенций учащихся на уроках татарского языка и литературы и во внеурочное время»»**









# VI сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

***Һидиятова Резеда Әнвәр кызы,***
***Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының***
***«14 нче лицей» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы:** Килешләр иленә сәяхәт. Иялек килеше.
**Дәрес максатлары:**
1. *Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):* иялек килешендәге исемнән соң килгән исем III зат берлек сан кушымчасын ала.
*Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):* эзләнү, нәтиҗә ясый белү кебек фикерләү сәләтләрен үстерү.
2. *Тәрбияви максат (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):* китап укуга, китапны тота белүгә уңай мөнәсәбәт тудыру.
**Укытучының планлаштырылган нәтиҗәләре.**
**Шәхси УУГ:**
- укуга карата кызыксыну хисе;
- укучы ролен үзләштерү;
- нәтиҗәләргә анализ һәм үзконтроль;

**Метапредмет нәтиҗәләр.**
**Регулятив УУГ:**
- бирелгән җөмләләрне татар теленә дөрес тәрҗемә итү;
- укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү;

**Коммуникатив УУГ**
- иптәшләренең сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- парларда эшли белү;

**Танып – белү УУГ:**
- укытучы биргән сорауларга дөрес һәм аңлаешлы җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү;
- исемнәрнең килешләр белән төрләнүен кабатлау

**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, интерактив такта, презентация, сүзлекләр, биремле карточкалар.
**Дәрес барышы:**
**I. Оештыру.**
1) уңай психологик халат тудыру;
2) дежур укучы рапорты.

**II. Өй эшен тикшерү** (4 күнегү, 26 бит. Китапханәдән китап алу өчен формуляр тутырырга иде, шул формулярларны җыеп алу).
**III. Актуальләштерү.**
Экранда җөмләләр язылган. Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куярга, тәрҗемә итергә: 1) Илдар мәктәп...(**тә**) укый. 2) Алсу белән Ринат урам...(**га**) чыгалар. 3) Марат китапханә...(**дән**) кайта. 4) Бу күлмәк...( ) матур. 5) Малай китапны укытучы...(**га**) бирде.

**Укытучы**: - Нокталар урынына нинди кушымчалар куйдыгыз? *( Килеш кушымчалары).*
- Искә төшереп китик әле. Татар телендә ничә килеш бар ? *( 6 килеш бар).*
- Нинди килешләр бар ? *(Килешләрне сораулары белән әйтеп чыгу).*
- Бу җөмләләрдә нинди килештәге сүзләр җитми ? *(Иялек килешендәге сүзләр юк).*
- Иялек килеше нинди сорауларга җавап бирә ? *(Кемнең ? Нәрсәнең ?).*
**Дәреслек белән эшләү**. 2 күнегү, 27 бит җөмләләрне укырга. Иялек килешендәге исемнәрне табырга. Тәрҗемә итергә. Иялек килешендәге исем белән бәйле сүзне аерып чыгарып язырга.
Азатның дәфтәре. Илгизнең китабы. Айгөлнең карандашы. Китапның бите. Укытучының соравы. Ринатның җавабы.
(Иялек килеше кушымчасы астына ак төстәге акбур, ә тартым кушымчасы астына зәңгәр акбур белән сызабыз. Укучылар белән нәтиҗә чыгару.)
Аннаң соң экранда кагыйдәне күрсәтү. Бер укучы кычкырып укый:
**Укучы: Притяжатеьный падеж – иялек килеше.**
Падежные вопросы: **кемнең**? (кого? чей ?), **нәрсәнең**? (чего?).
Притяжательный падеж выражает принадлежность предмета кому-либо: Айдарның китабы – книга Айдара.
После существительного в притяжательном падеже употребляется зависящее от него другое существительное с аффиксом принадлежности 3 лица единственного числа.
Айдарның дәфтәре – тетрадь Айдара, Айдарның хатасы – ошибка Айдара.
4 күнегү, 27 бит. Нокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп укырга. Җөмләләрнең эчтәлеге буенча сораулар язырга:
1) Китапның битләре нинди ?
2) Нәрсәнең битләре чиста түгел ?
3) Азатның сумкасы нинди ?
4) Кемнең сумкасы яңа ?
5) Кемнең энесе бишенче сыйныфта укый ?
6) Айратның энесе ничәнче сыйныфта укый ?
7) Мәктәпнең бакчасы нинди ?
8) Нәрсәнең бакчасы зур түгел ?
9) Коляның абыйсы кайда эшли ?
Экранда рәсемнәр чыга. Шул рәсемнәр буенча исемнәрне төрле килештә кулланып җөмләләр төзү (телдән). Нинди килештәге исемне кулландыгыз?
1) Малай мәктәпкә бара.
2) Әнинең күлмәге матур.
3) Апа кибеттән кайта.
4) Алсу бассейнда йөзә.
5) Кыз алма сатып ала.
6) Малай кызны туган көне белән котлый.
8 нче күнегү, 28 нче бит. Киңәшләрне дәвам итергә (телдән).
1) Китапны укы (сакла).

2) Китапка майлы әйбер куйма.
3) Китапны бөләргә ярамый.
4) Китапны чиста кул белән тот.

Китап белән бәйләнешле сорау җөмләләр төзеп бер-берсенә сорау бирәләр һәм җавап бирәләр.

1) Бу кемнең китап ?
2) Синең китабың чистамы ?
3) Син китап укырга яратасыңмы ?
4) Сезнең өегездә нинди китаплар бар ?
5) Син китапны кемгә бирәсең ?

**Өй эше.** Укучыларга карточкалар тарату. Карточкаларда бирелгән сүзләрне иялек килешенә куеп җөмләләр төзергә.

**Нәтиҗә ясау.**

**Укытучы: -** Димәк, бүген без нинди тема үттек ? (Иялек килешендәге исем белән бәйләнгән сүз III зат, берлек сан кушымчасын ала).

Билгеләр кую.

## Vсыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

***Закирова Гүзәлия Фәрит кызы,***
***Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының***
***«14 нче лицей» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы: Билгеле үткән заман хикәя фигыль.**

**Максат:**

1. *Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):* Билгеле үткән заман хикәя фигыль турында белешмә бирү.

2. *Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):* Үткән заман хикәя фигыль формасын сөйләмдә дөрес итеп куллану күнекмәләрен камилләштерү, файдалана белергә өйрәтү.

3. *Тәрбияви максат (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):* Бер-береңә матур итеп эндәшә, матур сөйләшә белү күнекмәләрен үстерү, коллективта дустанә хезмәттәшлек итү.

**Материал:** Күңелле татар теле, 5 нче сыйныф - Казан: Татармультфильм, 2014 (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) Р.З.Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова

**Җиһазлау**: Проектор, компьютер, карточкалар, дәреслек, сүзлекләр, төсле картоннар.

***Дәрес планы.***

**I. Классны дәрескә оештыру, уңай психологик халәт тудыру.**

Укучылар белән исәнләшү.

Кизү торучы укучы укытучыга укучыларның дәрескә әзерлеген, катнашуын хәбәр итә.

**II. Яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру, уку мәсьәләсен кую.**

Өй эшләрен тикшерү.
**III. Уку мәсьәләсен чишү.**
Экрандагы мисаллар ярдәмендә яңа теманы танып белү.
Физкультминут (микс-фриз- груп).
**IV. Күнекмәләр өстендә эш.**
Тактада эш (фигыльләрне төркемнәргә бүлү).
Дәфтәрләрдә эш.
Төркемнәрдә эш (сималтиниус раунд тэйбл).
Тест эше.
**V. Рефлексия.**
**VI. Үзбәя.**
**VII. Өй эше.**

**Дәрес барышы.**
**I. Классны дәрескә оештыру, уңай психологик халәт тудыру.**
1. Исәнләшү (Исәнмесез,укучылар)
(Укытучы) -Хәлләрегез ничек?
(Укучылар) -Рәхмәт,яхшы,шәп!
**II. Яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру, уку мәсьәләсен кую.**
1. Өй эшен тикшерү.
2. **Укытучы**: - Әйдәгез әле, экрандагы табышмакка күз салыйк.
*(1нче слайд)*
Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява.
Җирләр дымлана -
Бу кайчан була? (укучылар җавабын әйтәләр)
**Укытучы**: Бу табышмакта эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр бармы?
(Укучы җавабы: кала, ява, дымлана, була)
**Укытучы:** Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләрне без ничек атыйбыз?
(Фигыль)
- Нинди сорауларга җавап бирәләр?( нишли?)
- Алар кайчан эшләнгән эш яки хәрәкәтне, хәлне белдерәләр?
- Хәзер башкарыла торган эш яки хәрәкәтне, хәлне белдерәләр.
- Шулай булгач, болар нинди фигыльләр?
- Әйе, хәзерге заман хикәя фигыль.
**III. Уку мәсьәләсен чишү.**
*(2 нче слайд)*
Кырлар буш кал...,
Яңгырлар яу....
Җирләр дымлан...-
Бу кайчан бул...?
**Укытучы:** Беренче табышмак белән икенче слайдта күрсәтелгән табышмакны чагыштырабыз (укучы җавабы: кушымчалары юк)

- Әйдәгез әле, башкарылган эш-хәрәкәтне белдерүче кушымчаларны куеп, табышмакны укып карыйк әле (яңа кушымчалар ялганган сүзләргә сораулар куйдырыла).
Димәк, бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләшәбез? ( Билгеле үткән заман хикәя фигыль турында.)
- Ә хәзер үткән заман хикәя фигыльнең төгәл мәгънәсен чыгарып карыйк инде.
- Үткән заман хикәя фигыль сөйләп торган вакыттан алда булган эш, хәл, хәрәкәтне белдерә *(3 нче слайд)*
**Укытучы**: - Укучылар, әйтегез әле, бу төр фигыльләр нигез фигыльгә нинди кушымчалар ялганып ясалалар? (ашады, әзерләде, килде, барды, китте, кайтты)
Димәк, билгеле үткән заман хикәя фигыльләр:
- ды, - де, - ты, -те; кушымчалары кушып ясалалар (4нче слайд)
Ул фигыльләр җөмләдә нинди кисәк булып киләләр?
**Укучылар:** - Хәбәр.
Слайдта күрсәтелгән фигыльләргә таянып, укучылар белән берлектә - ды/ -де -ты/ -те кушымчаларының ялгану тәртибе аңлатыла. Шуннан соң слайдта кагыйдә чыгарыла.
**IV. Күнекмәләр өстендә эш.**
**Укытучы:** - (Ребята, в домиках живут слова. Нужно определить, какое слово в каком домике живет)

| | | | |
|---|---|---|---|
| - ды | - де | - ты | - те |
| бар | эшлә | кайт | бүләк ит |
| утыр | кил | чык | сөрт |
| яз | бир | яп | кит |

*(5 нче слайд)* Слайдта дөреслеге тикшерелә. Укучылар тарафыннан җөмләләр төзетелә.
Ял итү минуты «**Микс – фриз - груп**»
**Укытучы**:
1) Фигыль сүзендә ничә иҗек бар?
2) Фигыльнең ничә заманы бар?
3) Хәзерге заман хикәя фигыльнең ничә кушымчасы бар?
4) Үткән заман хикәя фигыльнең ничә кушымчасы бар?
**Дәреслек белән эш** (27нче бит, 3нче күнегү)
(Җөмләләрне укырга, билгеле үткән заман хикәя фигыльләрне табарга)
Төркемнәрдә эш. **«Сималтиниус раунд тэйбл»**
«Күз» темасына билгеле үткән заман хикәя фиг. кулланып, кечкенә хикәя язарга.
**Тест эше** (һәрбер укучыга таратыла)
Фигыльнең ничә заманы бар?
А) 2
Б) 4
В) 3
Хәзерге заман хикәя фигыль нинди сорауларга җавап бирә?
А) Нишләде?

Б) Нишли?
В) Нишләячәк?
Үткән заман хикәя фигыль нинди сорауларга җавап бирә?
А) Нишли?
Б) Нишләячәк?
В) Нишләде?
Бүләк итте фигыленең дөрес тәрҗемәсен табыгыз;
А) Дарит
Б) Подарил
В) Будет дарит
Пришел фигыленең дөрес тәрҗемәсен табыгыз;
А) Килә
Б) Киләчәк
В) Килде

**V. Рефлексия.**

Укучылар, без сезнең белән нинди тема өйрәндек? Нинди сорауга җавап бирә? Нинди кушымчалар ялгана? Тема аңлашылдымы? Авырлыклар булдымы?
Димәк, бу теманы үзләштереп белем алдыгыз, үткән заман хикәя фигыльне үз сөйләмегездә урынлы файдалана алырсыз дип уйлыйм.

**VI. Үзбәя.**

**VII. Өй эше.**

Шигырьләр таратыла,үткән заман хикәя фигыльләрне табып, дәфтәрләргә язарга.

## IV сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

***Лутфуллина Гөлнирә Тәлгать кызы,***
***Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының***
***«14 нче лицей» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәрес темасы**: Ел фасыллары
**Максат**: 1) *Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):* Укучыларга ел фасыллары турында мәгълүмат бирү, белемнәрен камилләштерү; Әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый белү, аралашу күнекмәләрен формалаштыру.
2) *Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):* Рәсем буенча җөмләләр төзи белү; уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;күмәк эшли белү.
3) *Тәрбияви максат (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):* Татар телен өйрәнүгә уңай караш булдыру; Туган якның кадерен белү; ярдәмчәнлек, башка кешеләргә карата ихтирамлы булу.
**Укытучының планлаштырылган нәтиҗәләре.**
**Шәхси УУГ:**
- укуга карата кызыксыну хисе;
- укучы ролен үзләштерү;

- нәтиҗәләргә анализ һәм үзконтроль.

**Метапредмет нәтиҗәләр.**

**Регулятив УУГ:**

- укытучы ярдәме белән проект эшен планлаштырырга өйрәнү;
- укытучы ярдәмендә ел фасылларын кабатлау.

**Коммуникатив УУГ**

- иптәшләренең сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- парларда эшли белү;
- группаларда эшли белү.

**Танып – белү УУГ:**

- укытучы биргән сорауларга дөрес һәм аңлаешлы җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү.

**Җиһазлау:** Проектор, рәсемнәр, таратма материал.

**Дәрес барышы.**

**1. Оештыру моменты**. Уңай халәт тудыру

**2. Яңа теманы ачыклау**.

**Укытучы: -** Балалар ,тактага карагыз эле( такдада һәр ел фасылына караган сүзләр языла, шул сүзләрне укып балалар нинди ел фасылы турында сүз барганын әйтергә тиеш).

- Без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез икән?( Балалар теманы үзләре ачыклыйлар).

**Укучы:** - Ел фасыллары.

**Укытучы: -** Ә сезнең яраткан ел фасылыгыз бармы?

**Укучы: -** Әйе ,бар.

**Укытучы:** - Мин сезгә ел фасыллары төшерелгән рәсемнәр элдем. Хәзер сез һәрберегез үзегезнең яраткан ел фасылыгыз янына басыгыз.

Балалар төркемләп басалар һәм үзләре сайлаган ел фасылы язылган өстәл артыны утыралар.

**Укытучы:** -Ульяна сиңа ни өчен көз ошый?( балаларның җаваплары, бер-береннән сораулары).

**3. Сүзләр өстендә эш**.( өй эшен тикшерү)Мультимедия ярдәмендә балалар такта янына чыгып сүзләрне тәрҗемәләре белән тоташтыралар)

**Укытучы:** - Балалар нәрсә сон ул туган як?

**Укучы: -** Туган як ул – без яши торган шәһәр. Яшел Үзән шәһәре.

**Укытучы:** - Әйе, укучылар. Һәрбер кеше үзенең туган илен , туган шәһәрен яратырга тиеш. Ә нәрсә соң ул табигать?

Укучы:- Табигать – ул урманнар, елгалар .......

**Укытучы:** - Бик дөрес балалар. Ә безнең ел фасылларыбыз табигатьнең төрле үзгәрешләрен күрсәтә.

4. **Укытучы:** - Ә хәзер игътибар белән тыңлагыз эле. Ел фасыллары нинди айлардан тора икән**?( аудирование)** Сораулар ярдәмендә айларны атау.

5. **Ял итү** (төркемнәргә басып лидер артыннан хәрәкәтләр ясау.

(«Туган як» җыры яңгырый)

6. **Ситуатив күнегүләр** ( Көз ел фасылы турында)

**Укытучы:** - Балалар , ә сез ничек уйлыйсыз, ни өчен мин сездән күбрәк күз турында сорадым?
Укучы: - чөнки хәзер көз ел фасылы.
7**. Кластер** (тактада төрле ел фасылына караган сүзләр эленгән, сез шулар арасыннан көз ел фасылына туры килгәннәрен генә сайлап алырга тиеш.
8. **Укытучы:** - Ә хәзер мин сезгә кечкенә генә **проект эше** тәгъдим итәм. Һәрбер төркемнән берәр укучы чыгып үзегезнең эшегезгә кирәкле материалны сайлап алыгыз һәм төркемегез белән эшләгез (һәрбер ел фасылына агач рәсемнәре һәм ел фасылына туры килгән материаллар таратыла.
9. **Проект эшләрен яклау.**
10. **Рефлексия** (Бик яхшы аңладым, яхшы беләм, тырышырга кирәк)
11. **Өй эше** (Хикәя язарга. Рәсем ясарга).

## II сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

***Минһаҗева Гөлназ Рафаэль кызы,***
***Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының***
***«14 нче лицей» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы**: Кайда? Кайдан? сораулары
**Дәреснең максатлары:**
1) *Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):* Кая? Кайда? Кайдан? сорауларын кулланып, җөмлә төзи белү.
2) *Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):* Бирелгән сорауларны аңлау һәм бирелгән ситуация буенча дөрес җавап бирә белү.
3) *Тәрбияви максат (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):* Белгәнеңне күрсәтәсе килү теләген уяту, туган якка карата хөрмәт, ярату хисе тәрбияләү.
**Укытучының планлаштырылган нәтиҗәләре.**
**Шәхси УУГ:**
- укуга карата кызыксыну хисе;
- укучы ролен үзләштерү;
- нәтиҗәләргә анализ һәм үзконтроль;

**Метапредмет нәтиҗәләр.**
**Регулятив УУГ:**
- укытучы ярдәме белән солауларны куя белүгә өйрәнү;
- укытучы ярдәмендә килеш кушыичаларын кабатлау;

**Коммуникатив УУГ**
- иптәшләренең сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- парларда эшли белү;

**Танып – белү УУГ:**
- укытучы биргән сорауларга дөрес һәм аңлаешлы җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү.

**Җиһазлау:** карточкалар, рәсемнәр, үзбәя таблицасы, дәреслек.

**Дәрес планы.**
**I . Мотивлаштыру.**
Дәресне оештыру.
Укучыларның игътибарын дәрескә юнәлтү, уңай халәт тудыру. Балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру.
**II. Актуальләштерү өлеше.** Дәреснең темасын ачыклау.
**III. Уку мәсьәләсен чишү.**
**IV. Рефлексия.**
**V. Өй эше бирү.**
**VI. Йомгаклау.** Билге кую.

**Дәрес барышы.**
**I . Оештыру өлеше.**
Укучыларның игътибарын дәрескә юнәлтү, уңай халәт тудыру.
Укытучы өчен максат: балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру.
Исәнләшү, хәерле көн теләү.
**Укытучы:**-Исәнмесез укучылар! Утырыгыз!
Хәлләр, кәефләр ничек? *( яхшы)*. Әйдәгез бер-беребезгә елмаябыз.
- Бүген сыйныфта кем дежур? *(Бүген сыйныфта ... дежур)*
- Бүген сыйныфта кем юк? *(Бүген сыйныфта ...юк) (Барысы да бар)*
- Ярар, яхшы.
**II. Актуальләштерү өлеше.**
**Укытучы: -**Балалар, бүген көн нинди? Ел фасылы нинди?
- Яңгыр явамы?
- Кар явамы?
- Җил исәме?
- Яфраклар коеламы?
- Бүген салкынмы?
**Укытучы: -** Давайте вместе произнесем звук [ә]
- Какие слова мы знаем с этой буквой в словах?
- Ребята повторяйте за мной слова.
*(дәфтәр, мәктәп, шәһәр, сәлам, каләм, нәрсә, рәхмәт)*
- Давайте переведем эти слова.
Рәхмәт – спасибо - вежливое слово.
- А какие еще вежливые слова знаете на татарском языке? Ребята нужно быть вежливыми.
В каждом столбике одно слово лишнее. Назови его.

| | |
|---|---|
| Китапта | Урманнан |
| Көндәлектә | Урамнан |
| Дәреслектә | Мәктәптән |
| Мәктәптә | Казаннан |

Бер берсенең эшләрен тикшерәләр.
**Укытучы:**
- Ребята, как вы думаете какую тему мы сегодня будем проходить?

- Правильно, вопросы *Кайда? Кайдан?*
- выбираем нужное окончание для каждого вопросительного слова.

Кая? - га/ -гә, - ка/ - кә

Кайда? - да/ - дә, - та/ - тә

Кайдан? - дан/ - дән, - тан/ - тән, - нан/ - нән

**Укытучы:** - Ребята, если мы находимся где-то, то добавляем окончания - да/ - дә, - та/ тә. А если хотим сказать возвращаемся откуда-либо, то к словам добавляем окончания - дан/ - дән, - тан/ - тән, - нан/ - нән.

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

**Укытучы:** Укучылар, хәзер мин сезгә карточкалар таратам.

1) Подбери окончания

Казан.... - да

Мин Мамадыш.... - дә яшим

Түбән Кама..... - та

Әлмәт .... - тә

**Укытучы:** Хәзер карточкаларыгызны алып, үз-үзегезне бәяләп, билге куегыз. (Үзбәя)

2) Тактада сүзләр бирелән. Шул сүзләргә тиешле кушымчаларны өстәп язарга. (-дан/ -дән, -тан/ -тән, -нан/ -нән)

Авыл..., шәһәр..., парк..., мәктәп..., урман..., Зәй..., сумка..., пенал..., идән... (Үзбәя)

**Ял минуты (күзләргә хәрәкәтләр ясау)**

3) Спроси у друга:

| | |
|---|---|
| а) есть ли в вазе | б) есть ли в сумке |
| - цветы | - пенал |
| - вода | - книга |
| - яблоки | - тетрадь |
| - конфеты | - карандаши |

(Үзбәя)

4) тәрҗемә итегез:

Я в Зеленодольске живу.

Я в Казане живу.

Я в Елабуге живу.

Я в Набережных Челнах живу.

Я в Чистополе живу.

(Үзбәя)

**IV. Рефлексия.**

**Укытучы: -** Ребята, о чем мы сегодня научились говорить по-татарски?

Научились: спрашивать и говорить о том, где мы находимся, откуда мы идем.

**V. Өй эше бирү.**

**Укытучы: -** Хәзер көндәлекләрне ачабыз. Өй эшен язабыз. 109 нчы бит, 3 нче күнегү. Самооценка учащихся.

**VI. Йомгаклау. Билге кую.**

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ОСИНОВО БИСТӘСЕНЕҢ «В.В. КАРПОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ЛИЦЕЙ» БЮДЖЕТ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ



**28 нче октябрь, 2016 нче ел**

Зеленодолмуниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең татартелеһәм әдәбияты укытучылары өчен практик семинар
**«Татар теле һәм әдәбияты укытучысының эш программасы – белем бирү сыйфаты белән идарә итү инструменты»**

Практический семинар для учителей татарского языка и литературы общеобразовательных организаций Зеленодольского муниципального района
**«Рабочая программа учителя татарского языка и литературы - инструмент управления качеством образования»**







## 1 нче сыйныфта укучы татар балаларына - әдәби уку дәресе

***Мансурова Лилия Сәлимхан кызы,***
***Татарстан Республикасы Зеленодол муиципаль районы***
***Осиново бистәсе «В.В. Карпов исемендәге лицей» муниципаль бюджет***
***белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы: [у] авазы, У, у хәрефләре.**

1. *Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):*[у] авазы, У, у хәрефләре белән таныштыру; сүз модельләре нигезендә [у] авазын дөрес әйтергә, өйрәнелә торган авазның сүздәге урынын билгеләү, баш, юл хәрефен танырга өйрәтү.
*Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):* фонематик ишетү һәм авазны дөрес әйтү.
2. *Тәрбияви максат (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә*): укуга уңай мөнәсәбәт, тотрыклы танып-белү мотивы, уку хезмәте культурасы тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**
**Шәхси УУГ:**
- укуга карата кызыксыну хисе;
- укучы ролен үзләштерү;
- нәтиҗәләргә анализ һәм үзконтроль;

**Метапредмет нәтиҗәләр.**
**Регулятив УУГ:**
- укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;
- укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү;

**Коммуникатив УУГ**
- иптәшләренең сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- парларда эшли белү;

**Танып – белү УУГ:**
- укытучы биргән сорауларга дөрес һәм аңлаешлы җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү.

**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, проектор, дәрес темасына ясалган презентация.

**Дәрес барышы**
1. **Дәресне оештыру** (исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу)

Уңай психологик халәт тудыру**.**
**Укытучы:**
- Исәнмесез, балалар!
- Хәерле көннәр сезгә!

Зиһен һәм тел ачкычлары
Телимен һәммәгезгә.
- Бер-беребезгә карап елмаегыз әле.
- Укучылар, кәефләрегез ничек?

- .......
«Бармаклар» уены. Ел фасылларын кабатлау.
*Баш бармагым кыш була.*
*Кар- бураннары туза*
*Имән бармак яз килә,*
*Карлары эреп бетә.*
*Урта бармак җәй җитә*
*Җиләк кызарып пешә.*
*Атсыз бармак көз икән,*
*Сары яфраклар сипкән.*
*Чәнти бармак ни икән?*
*Кыш, яз, җәй,көз үтеп киткән.*
- Табигатьтә хәзер кайсы ел фасылы?
- .........
- Атнаның кайсы көне?
- ........

**II. Белемнәрне актуальләштерү.**

**«Үз уеным»**

**Укытучы:** Тактада сез сөйләм, җөмлә, аваз, хәреф табличкалары күрәсез. Үзегезгә ошаган темаларны парлап сайлап аласыз һәм шуңа туры килгән биремнәрне үтисез.
*1 слайд («Куян кызы» әкиятеннән бер иллюстрация күрсәтелә)*
**Укытучы:** Бу кайсы әкияттән алынган? *(«Куян кызы» әкиятеннән алынган)*
*Укучылар арасыннан бер кыз Тиен сүзләрен әйтә:*
- Кайгырма, туганкай, йомшак куянкай, кызыңның аягын бик тиз төзәтеп була. Моның өчен доктор Айболитка барырга, аңардан киңәш сорарга кирәк.
**Укытучы:** Бу сүзләр кемнең сүзләре? *(тиен сүзләре)*
*2 слайд.*
Кече кыз бик бәхетле яшәгән. Авыру анасын да бик хөрмәт иткән. Кешеләр дә аны бик яратканнар.
**Укытучы:** Текстта ничә җөмлә бар? *(өч җөмлә)*
**Укытучы:** Җөмлә икәнен кайдан белдең? *(Җөмләнең беренче сүзе баш хәрефтән башлана, җөмлә ахырында нокта куела.)*
**Укытучы:**Авазларны без нишлибез? [а] [ы] [ә] [э] авазлары турында нәрсә әйтә аласың? *([а] [ы] калын, [ә] [э] нечкә сузык аваз)*
**Укытучы:** Хәрефләрне без нишлибез? Кеше исемнәре нинди хәрефтән языла? И хәрефенә башланган кеше исемнәре уйлап әйтергә.
*(Кеше исемнәре баш хәрефтән языла: Илнар, Илфат, Ирек һ.б.)*

***Физкультминутка***

*Без инде хәзер зурлар,*
*Күп эшли безнең куллар.*
*Без идән дә юабыз.*
*Без керләр дә уабыз,*
*Гөлләргә су сибәбез.*

*Без әле бераз ардык.*
*Ял итәргә уйладык.*
**III. Уку мәсьәләсен кую.**
**Укытучы:**Укучылар, хәзер мин сезгә сүзләр әйтәм. Игътибар белән тыңлагыз. Бу сүзләр арасында кайсы сүз артык?
Ат, сарык, әтәч, сыер, аю, бозау.
***Укучылардан көтелгән җавап:***
*Аю сүзе артык.*
**Укытучы:** Ни өчен аю сүзе артык?
***Укучылардан көтелгән җавап:***
*Аю кыргый хайван, ул урманда яши.*
*3 слайд.Урман рәсеме.*
**Укытучы:**Урман турында нәрсә әйтә аласыз?
***Укучылардан көтелгән җаваплар:***
*Урманда күп агачлар үсә, анда куян, бүре һәм башка хайваннар яши.*
**Укытучы:**Урман сүзен кабатлап әйтик әле.Сүз башында нинди аваз ишетелә?
***Укучылардан көтелгән җавап:***
*[у] авазы*
*Экранда куян рәсеме.*
**Укытучы:** Рәсемдә сез нәрсә күрәсез?
***Укучылар:*** *Куян*
**Укытучы:** Куян сүзенең уртасында нинди аваз ишетелә?
***Укучылар*:** *[у] авазы*
**Укытучы** Димәк, без бүгенге дәрестә нинди аваз һәм хәрефләрне өйрәнербез инде?
***Укучылардан көтелгән җаваплар:***
*[у] авазын, У,у хәрефләрен өйрәнербез, алар белән сүзләр уйлап әйтербез, урынын билгеләрбез.*
**IV. Уку мәсьәләсен чишү.**
**Укытучы:**Укучылар, барыбыз бергә [у] авазын әйтик әле. [у] – ничек әйтелә?
***Укучылар:*** *Сузыла, җырлана.*
**Укытучы:**[у] авазы тагын ничек әйтелер? Калынмы,нечкәме?
***Укучылар:*** *Калын сузык аваз.*
**Укытучы:** Схемада бу аваз нинди шартлы билге белән белдерелер?
***Укучылар:*** *Буш түгәрәк белән белдерелә.*
**Укытучы:** [у] авазы нинди хәрефләр белән белдерелә?
***Укучылар***: *Баш У һәм юл у хәрефләре белән белдерелә.*
**V. Беренчел ныгыту.**
**Укытучы:** [у]авазыннан башланган сүзләр уйлап әйтегез әле. *(Укучылар чиратлап сүзләр әйтәләр, ә калганнар сүз башында [у] авазын ишетсәләр,кул чабалар, ишетмәсәләр, тыныч кына утыралар)*
***Укучылардан көтелгән җаваплар:***
*Умырзая, урман, урам, усак, урындык һ.б.*
**Укытучы:** [у] авазы уртада булган сүзләр уйлап әйтегез әле.

***Укучылардан көтелгән җаваплар:***
Куян, туп, кул, сула һ.б.
**VI. Икенчел ныгыту.**
**Укытучы:** Әйдәгез әле, туп сүзенең аваз-хәреф схемасын ясап карыйк. Бу сүздә беренче аваз нинди аваз?
***Укучылардан көтелгән җавап:*** *[т]*
**Укытучы:** Бу авазны беләбезме?
***Укучылардан көтелгән җавап:*** Юк.
**Укытучы:** Икенче нинди аваз?
***Укучылардан көтелгән җавап:*** *[у] - калын сузык аваз.*
**Укытучы:** Өченче нинди аваз ишетелә?
***Укучылардан көтелгән җавап:*** *[п]*
**Укытучы:** Бу авазны беләбезме?
***Укучылардан көтелгән җавап:*** Юк.
**VII. Ныгыту.**
**Укытучы:** Ә хәзер, укучылар, дәреслектәге рәсемнәрне карыйк әле. Нәрсәләр ясалган икән монда?
***Укучылардан көтелгән җаваплар:***
*Ук, гармун, учак, кул.*
**Укытучы:** Ә хәзер шушы сүзләрдә [у] авазының урынын билгелибез.
***Укучылардан көтелгән җаваплар:***
*Ук сүзендә [у] авазы сүз башында.*
*Гармун сүзендә [у] авазы сүз уртасында.*
*Учак сүзендә [у] авазы сүз башында.*
*Кул сүзендә [у] авазы сүз уртасында.*
**VII. Рефлексия.**
- Әйдәгез, дәрескә йомгак ясыйк. Без бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләштек?
- *[у] авазы, У,у хәрефләре турында сөйләштек.*
- [у] авазы турында нәрсә белдегез?
- *[у] - калын сузык аваз*
- Кем дә кем бүгенге дәрес материалын яхшы аңладым һәм аны башкаларга да аңлатып бирә алам дип уйлый, шулар яшел фишка күтәрәләр.
- Кем материалны аңладым, ләкин башкаларга аңлатып бирергә кыенсынам ди, алар сары фишка күтәрәләр.
- Кем әле минем аңламаган урыннарым һәм сорауларым калды дип саный, ул кызыл фишка күтәрә.
- Дәрестә актив катнаштыгыз!
Дәрес тәмам.

## VI сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

***Захарова Альбина Алексей кызы,***
***Татарстан Республикасы Зеленодол муиципаль районы***
***Осиново бистәсе «В.В. Карпов исемендәге лицей» муниципаль бюджет***
***белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы:** «Әхмәт нигә елады?» тексты. Образга бәя бирү.
**Максат**:
1. Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе): Фигыль формаларын (хикәя, боерык, теләк, инфинитив) сөйләмдә куллана белүне камилләштерү.
Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе): Укучыларның сөйләм байлыгын арттыру, темага карата булган белемнәрен тулыландыру, танып белү активлыгын арттыру,бәйләнешле сөйләмнәрен киңәйтү, балаларда аралашу ихтыяҗын тудыру өстендә эшне дәвам итү.
2. Тәрбияви максат (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә): Укучыларга әти-әнигә, зурларга, бер - береңә игътибарлы булып, ярдәмләшеп эшләүнең нәтиҗәлерәк булуына төшендерү, хезмәт белән шөгыльләнергә өйрәтү.
**Укытучының планлаштырылган нәтиҗәләре.**
**Шәхси УУГ:**
- укуга карата кызыксыну хисе;
- укучы ролен үзләштерү;
- нәтиҗәләргә анализ һәм үзконтроль;

**Метапредмет нәтиҗәләр.**
**Регулятив УУГ:**
- укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;
- укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү;

**Коммуникатив УУГ**
- иптәшләренең сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- парларда эшли белү;

**Танып – белү УУГ:**
- укытучы биргән сорауларга дөрес һәм аңлаешлы җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү.

**Җиһазлау:**дәреслек, компьютер, проектор, дәрес темасына ясалган презентация, сүзлекләр

**Дәрес барышы**
**I. Мотивлаштыру.**
**1. Дәресне оештыру** (исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу)
Уңай психологик халәт тудыру**.**
**Укытучы:** - Исәнмесез!
- Хәерле көн!
- Кәефләрегез ничек?
- Бүген кем дежур?

- Бүген ничәсе?
- Атнаның нинди көне?
- Дәрестә кем юк?
- Укучылар, дәресебезне башлыйбыз, мин сезгә бүгенге дәрестә уңышлар телим!

*1слайд*

- Укучылар, без бүгенге дәрестә «Әхмәт нигә елады» дигән текст белән танышырбыз, сорауларга җавап бирербез.

Фонетик күнегү.

*2 слайд*

Әлбәттә [әлбәттә], кер юа [кер йуа], пешерә [пешерә], ерактагы [йыракътагы], булыша [булыша ],авырды [аwырды].

III Терәк белемнәрне актуальләштерү этабы:

*3 слайд*

**2. Ситуатив күнегүләр.**

Как скажешь о том, что:
- дома очень много работы;
- ты помогаешь маме;
- ты умеешь варить суп;

Как попросите сестрёнку:
- подмести пол;
- быстрее одеться;

Спроси у друга:
- помогает ли родителям;
- убирает ли он постель;

Сообщите о том, что:
- ты не идёшь в магазин
- Булат не идёт в школу
- Айсылу не моет посуду

**3. Дәреслек белән эшләү.**

Укучылар, 2 нче күнегүне дәфтәрләргә язабыз.

Яши – яшәсә – яшәмәсә
Эшли – эшләсә – эшләмәсә
Юа – юса – юмаса
Пешерә – пешерсә – пешермәсә
Җыештыра – җыештырса – җыештырмаса

Әлеге сүзләр белән җөмләләр төзик һәм дәфтәрләргә язып куйыйк.

Салкын чишмә суын эчсәм – если попью холодной родниковой воды
Сизмәс дип уйлады – думал, что не почувствует
Терелермен кебек – может, выздоровлю
Үзем авырыймдыр – наверное, сама болею

*4 слайд*

«Әхмәт нигә елады?» хикәясе белән танышу.

1) Хикәяне укытучы укып чыга.

2) Чылбырлап укучылар укый.
3) Тәрҗемәсен сөйләп карыйлар.
4) Яңа сүзләр белән эш.

**4. Уку мәсьәләсен кую.**

**Укытучы:** Ә хәзер әйдәгез әсәргә анализ ясап карыйк. Уйлап карагыз әле, әсәр күңелсез тәмамланды, безгә дә күңелсез булды, Әхмәт елады, кызарды, ә барыбызга да күңелле булсын өчен без нишләрбез икән? (Уку мәсьәләсен кую). Ә аның өчен әсәрне анализлап карыйк әле. Укучылар, әйтегез әле, бу әсәрнең төп геройлары кемнәр?

**Укучылар**: Әхмәт һәм аның әнисе.

**Укытучы:** Әйе, ә хәзер әлеге образларга бәя биреп карыйк әле, алар нинди икән?

**Укучылар:**

ӘНИСЕ – яхшы, эшчән, тырыш, матур һ.б.

**Укытучы:** Әнисенең тискәре яклары бармы?

**Укучылар:** Әниләр һәрвакыт яхшы булалар.

**Укытучы:** «Әниләргә мәхәббәт» темасына төркемнәрдә иҗади эш эшләп алыйк әле (Рәсем ясыйлар, бәлки шигырь сөйлиләр)

**Укытучы:** Ә Әхмәт нинди соң балалар?

**Укучылар:**

ӘХМӘТ – ялкау, ялганчы, тәртипсез, озак уйный, уйнарга ярата, шук, хәйләкәр.

**Укытучы:** Әйтегез әле, Әхмәт үзенең ялгышын аңладымы?

Әхмәтнең яхшы яклары бармы?

Ә хәзер әйдәгез, яхшы һәм начар якларын билгеләп чыгыйк.

(Мәсәлән, сезне кемдер берәр җиргә чакырса, сез , юк, минем әнием авырта , миңа өйгә кайтырга кирәк, дип ул кешедән котыласыз. Бу урында сезнең хәйләкәрлек сезгә ярдәмгә килә)

**Укытучы:** Әхмәтнең уңай яклары бар микән?

**Укучылар:** Ул сәламәт, чөнки көне буе саф һавада йөри, ялгышын таный, әнисен ярата һ.б.

**II. Уку мәсьәләсен чишү.**

**Укытучы:** Укучылар, ә без нинди соң? Әниләрне, өлкән кешеләрне ялганламыйбызмы, аларга булышабызмы?- Ә сез әниегезгә булышасызмы соң, ниләр эшлисез? (Җаваплар)

**Укытучы:** Сезнең җавапларны тыңладык. Ә хәзер Әхмәткә киңәшләр биреп карыйк әле?

**Укытучы:** Әхмәтнең начар якларын күп таптык, үзегезгә ошаган Әхмәт образын сөйләп карагыз әле. Бөтен яктан да килгән кешеләр булмый, һәр кешедә дә җитешмәгән яклары була, тик алар үз өстендә эшләргә, җитешсез якларын төзәтергә тиеш. Әйдәгез, Әхмәтне дә төзәтеп карыйк, сез аны ничек итеп үзгәртер идегез?

---

(Укучыларның җаваплары тыңланыла)

**III. Рефлексия**

Укучылар без бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләштек?
(Укучылар җавабы)
Димәк, нинди сорауга җавап таптык?
Барыбыз да әти – әниләрне яратабыз, өлкәннәрне хөрмәт итәбез.
**Үзбәя** .Үзләренә нинди билге куясылары килә, шул рәсемне ясыйлар.
**Өй эше.**
1. «Әнием кояшым» дигән темага иҗади эш эшләп килегез (рәсем, шигыр, яисә инша язарга)
2. Текстны сәнгатьле укырга өйрән.
3. Әниләр турында мәкальләр язып килергә.

## VI сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

***Алкина Наилә Мәхмүт кызы,***
***Татарстан Республикасы Зеленодол муиципаль районы***
***Осиново бистәсе «В.В. Карпов исемендәге лицей» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы**: Өйдәге эшләр.
**Максат:**
1. Белем бирү максаты: Өйрәнелгән лексик-грамматик сөйләмдә куллана белүне камилләштерү.
2. Үстерү максаты: Укучыларның сөйләм байлыгын арттыру, фикерләү сәләтен үстерү.
3. Тәрбияви максат: Эшчән, ярдәмчел булырга, әти-әниләргә, өлкәннәргә, хайваннарга игътибар күрсәтергә, булышырга теләк уяту.
**Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре.**
**Предмет:** Өйдәге эшләр турында сөйләргә өйрәтү
**Метапредмет:**
**Регулятив УУГ:**
-Укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;
- укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү.
**Коммуникатив УУГ:**
- башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- парларда эшли белү.
**Танып-белү УУГ:**
- укытучының сорауларына җавап бирә,тиешле мәгълүматны таба белү.
**Шәхси:** укучыларда төгәллек, җаваплылык кебек уңай сыйфатлар тәрбияләү.
**Дәрес тибы:** ЛГКК
**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, проектор, дәрестемасынаясалган презентация, сүзлекләр, интерактив такта, биремле карточкалар.

**Дәрес барышы:**
**1. Мотивлаштыру**
1. Оештыру моменты.
Укытучы: - Исәнмесез,укучылар?
Укучы: - ................
Укытучы: - Хәлләрегез ничек?
Укучы: - ...................
Укытучы: - Рәхмәт, минем дә хәлләрем бик яхшы. Дәресебезне башлыйбыз.
**II. Актуальләштерү.**
1. Кереш әңгәмә.
Укытучы:
- Хәзер нинди ел фасылы?
- Бүген ничәнче число?
- Атнаның нинди көне?
- Бүген һава торышы нинди?
- Дәрестә барыбыз да бармы?
2. Аудирование.
1) Прослушайте и укажите словосочетание, лишнее влогическом ряду.
Юына, урын җыя, кер юа, **идән себерде**, идән юа.
2) Прослушайте и скажите, как изменились бы эти глаголы, если бы эти действия делал 1- ое лицо.
Карый, эшли, себерә, юа, җыя,түгә,сибә.
(карыйм, эшлим, себерәм, юам, җыям, түгәм, сибәм)
Балалар, бу сүзләр нәрсә турында? – өйдәге эшләр турында.
О чём эти слова? – о домашних делах.
**III. Уку мәсьәләсен кую.**
Укытучы: - Экранга карыйк. Бу сүзләрнең бер-берсе белән уртак яклары бармы? Нинди?
Булыша – помогает
Булышчы – помощник
Булыш – помоги
Булышу –помощь
Укытучы: - Алар ничек тәрҗемә ителә? Алар белән җөмләләр төзегез!
Укучы: - ...
Укытучы: **-** Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшербез?
Укучы: **- ...**
Укытучы: - Әйе, укучылар, без бүгенге дәрестә хезмәт, булышу турында сөйләшербез.
**IV. Уку мәсьәләсен чишү. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.**
Укытучы: **-** Укучылар, сез үзегез «булышчы» сүзен ничек аңлыйсыз? Кем булышчы була ала? Балалар дамы? Ә алар кемгә булышчы була алалар? Ә без аларга ничек булыша алабыз соң? Сез әти-әниегезгә ничек булышасыз? *(Балалар үз җавапларын әйтәләр)* )

Укытучы: - Сез аларга булышкач, алар сезне мактыйлармы? Сезгә нәрсә әйтәләр? Сез шатланасызмы?

- Ә хәзер тактага карагыз. Бу рәсемнәрдә малай нишли?

Малай чүп чыгара.
Малай савыт-саба юа.
Малай урын җыя.
Малай тузан сөртә.
Малай өстәл җыештыра.
Малай идән себерә.
Малай машина юа.

Укытучы: -Укучылар, без җөмләләрне ничәнче затта кулландык? Хәзер бу сүзләрне 1 нче затка куегыз. Җөмләләр үзгәрерме?

- Без тагын өйдә ниләр эшли алабыз?
- Тагын кемнәргә, нәрсәләргә без булыша алабыз?

Укучы: - Кошларга, хайваннарга.
Укытучы: - Ничек?
Укучы: - Кошларга җимлекләр ясыйбыз, йорт хайваннарыбызны карыйбыз, ашатабыз.

**V. Физминутминутка**

- Без инде хәзер зурлар.
- Күп эшли безнең куллар.
- Без идән дә юабыз.
- Һәм керләр дә уабыз.
- Эре-эре заводлар
- Тиздән үсеп җитәрбез.
- Шунда эшкә китәрбез.

**VI. Яңа теманы камилләштерү**

1) Әйдәгез, бер уен уйнап алыйк. Сүзләр адашканнар, дөрес итеп җөмләләрне төзергә кирәк.

Мин тәлинкә булышалар.
Син тузан пешерә.
Ул аш сөртәсең.
Без савыт - саба чыгарасыз.
Сез чүпне юабыз.
Алар әнигә юам.

- Бу җөмләләр дөрес язылганмы?
- Юк, әйдәгез,аларны дөреслик .

2**) Диалог төзү.**

Укытучы: - Хәзер,укучылар,өйрәнгән сүзләрне кулланып диалогларны тулыландырыйк**. -** А теперь используя все фразы которые мы изучили на уроке предлагаю дополнить диалог

- ...?
- Әйе,мин идән юам.

- Ә чүп чыгарасыңмы?
- … .
- …?
- Мин ашарга әзерләмим.
-Ә кем ашарга әзерли?
- … .
- Оля,син өйдә нишлисең?
- … .
- Ә савыт-саба юасыңмы?
- …

**3) Әйдәгез, дустыгыздан сорагыз әле.**

Как скажешь о том, что:
- *сам моешь посуду;*
- *сам убираешь постель;*
- *сам помогаешь родителям .*
- Дәвам итәбез, дустыгыздан сорагыз әле, ә ул сезгә җавап бирсен.

Спросите у товарища:
- *помогает ли он маме;*
- *поливает ли он цветы;*
-*вытирает ли он пыль?*

Подтвердите, что:
- *варите суп;*
- *моете посуду;*
- *гладите рубашку.*

***4) Уен.***

Сезнең һәрберегезнең өстәлендә карточкалар, анда төрле хәрефләр бирелгән, ул **хәрефләр буталган,** алардан булышу темасына караган **сүзләр** төзергә кирәк.

**5) Тест** (дөрес тәрҗемәне сайлап ал)

| | | |
|---|---|---|
| *1. Сам(сама)* | *2. Заправляю постель* | *3. Могу умываться* |
| Р) мин | А) урын җыйган | С) ул юынган |
| П) сез | О) урын җыям | Т) сөйләшә ала |
| Н) без | У) хаталарны төзәтте | Л) юына алам |
| М) үзем | И) ул урын җыйды | К) юындык |
| *4.Ты помогай* | *5. Может бегать* | *6. Много помогает* |
| 0) син булыш | Г) йөгерә | Е) Күп булыша |
| Ө) булышты | Б) чаба | Ы) Күп булыша ала |
| Ә) булышмый | Д) чаба ала | Э) Күп ярдәм итә ала |
| Ү) ул булыша | З) йөгерде | Ш) Күп ярдәм итте |
| *7.Встаёшь рано* | | |
| Ф) иртә тормый | | |

| |
|---|
| Ц) иртә торасың |
| Х) начар уйный |
| Щ) иртә торган |

- Нинди сүз яшеренгән икән анда?

**VI. Йомгаклау.**

**1. Нәтиҗә ясау.**

Укытучы: Сез - әти-әниегезнең, безнең булышчыларыбыз. Әйдәгез, дәресебезгә йомгак ясыйк. Укучылар, без бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләштек?

*Көтелгән җаваплалар:*

- *Булышчы булырга, ярдәмчел булырга.*

Без кемнәргә булышабыз? Ничек булышабыз? Без аларга ничек булышабыз?

*Көтелгән җаваплалар:*

- *Без идән юабыз.*
- *Без савыт-саба юабыз.*
- *Без гөлләргә су сибәбез.*

Укытучы: Безнең әйләнә-тирәбездә кешеләр, кошлар, хайваннар бик күп. Аларга без булышырга тиеш. Без - булышчылар бит, әйдәгез бер - беребезгә булышыйк.

**2. Өйгә эш бирү.**

1. Тема буенча рәсем ясарга һәм сөйләргә**.**
2. Мәкаль, табышмаклар табып килергә.

**3. Рефлексия.**

- Сезнең алдыгызда карточкалар бар, Хәзер һәрберегез үзегезгә бәя бирегез әле. Сез бүгенге дәрестә ничек эшләдегез? Ничек катнаштыгыз? Үзегезгә нинди билге куяр идегез?

Бүген барыгыз да дәрестә бик яхшы катнашты. Дәресебез бетте! Сау булыгыз!

## II сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

***Шаймуллина Гөлнара Миннехан кызы,***
***Татарстан Республикасы Зеленодол муиципаль районы***
***Осиново бистәсе «В.В. Карпов исемендәге лицей» муниципаль бюджет***
***белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы:** «Билгеле үткән заман хикәя фигыль кушымчаларының ялгану тәртибе»

**Максат:**

1. *Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):* билгеле үткән заман хикәя фигыльнең ясалышы турында алган белемнәрне камилләштерү, билгеле үткән заман хикәя фигыльне сөйләмгә кертеп җибәрү.

2. *Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):* Укучыларның сөйләм байлыгын арттыру, фикерләү мәләтен үстерү. Үзара аралаша белү *мөмкинлекләрен* үстерү. Үз хезмәтеңне бәяли белергә өйрәтү.

3. *Тәрбияви максат (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):* Бер-береңә матур итеп эндәшә, матур сөйләшә белү күнекмәләрен үстерү, татар теленең байлыгын аңлау, сөйләмне камилләштерергә омтылу.

**Укытучының планлаштырылган нәтиҗәләре.**

**Шәхси УУГ:**

- укуга карата кызыксыну хисе;
- укучы ролен үзләштерү;
- нәтиҗәләргә анализ һәм үзконтроль;

**Метапредмет нәтиҗәләр.**

**Регулятив УУГ:**

- укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;
- укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү;

**Коммуникатив УУГ:**

- иптәшләренең сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- парларда эшли белү;
- үз фикерләрен тулы һәм төгәл итеп җиткерә белү

**Танып – белү УУГ:**

- укытучы биргән сорауларга дөрес һәм аңлаешлы җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү.
- аңлап уку осталыгын формалаштыру, логик фикерләү осталыгын үстерү.

**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, интерактив такта, презентация,биремле карточкалар (таратма материал).

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру**

**1) Балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру**.

- Исәнмесез укучылар!

- Кызлар утырыгыз! Малайлар утырыгыз!

- Сез татар теле дәресенә әзерме?

Бер – беребезгә елмаеп татар теле дәресен башлап җибәрик әле.

**2) Фонетик күнегүләр**

***Сорау-җавап әңгәмә кору**

- Хәлләр ничек.....?

- Хәерле көн.....?

- Сәлам.....?

- Исәнме....?

- Хәзер нинди ел фасылы?

- Хәзер көзнең кайсы ае?

- Бүген көн нинди?

- Урамда җил исәме?

- Урамда кар явамы?

- Урамда кояш кыздырамы?
- Урамда көн эссеме?

**ll. Белемнәрне актуальләштерү.**

Белем дәрәҗәсен, укучыларга авыр булган моментларны ачыклау.

**Өй эшен тикшерү.**

1) Ятлаган сүзләрне сорау.
2) Алар белән җөмләләр төзү

**lll. Уку мәсьәләсен кую**

*Слайд 1*

А) -Укучылар тактага карагыз,сүзләрне укыйбыз,күчереп язабыз.
- Дәфтәрләрне алыштырдык һәм бер-берегезнең хаталарын яшел паста белән тикшерегез.
- Кемнең хатасы юк басыгыз

Б) Нинди артык сүз бар.
- Ни өчен артык?
- Сорау куегыз әле.(нишләде)
- Димәк,без буген дәрестә нәрсә турынла сөйләшәбез?
- Аның кушымчалары дәрес ялгану тәртибе турында сөйләшербез.

2) 1нче һәм 2нче баганалардагы җөмләләрне укыгыз.

*Слайд 2*

Алар нәрсә белән аерылалар?

*Ренат укый. Ренат укыды.*
*Рәсим әйтә. Рәсим әйтте.*
*Алсу сикерә. Алсу сикерде.*
*Алия баса. Алия басты.*

Как эти изменения повлияли на смысл предложений?
(җөмләләрне русчага тәрҗемә итәргә тәкъдим ителә)

*Слайд 3*

Закончите предложение.
- Если действие происходит сейчас, то... (настоящее время глагола)
- Татарча ничек була
- Если действие произошло, то это... (прошедшее время глагола)
Татарча ничек була
- Какие аффиксы помогают сказать об известных действиях, которые уже произошло?
- По какому признаку присоединяются аффиксы к основе глагола?

Именно на эти вопросы мы должны ответить в течении урока, и научится использовать полученные знания в практике.

**lV. Уку мәсьәләсен чишү юллары. Яңа теманы өйрәнү.**

Проблеманы чишү юнәлешен күрсәтү.

*Слайд4*

1. Посмотрите на таблицу. Что можно сказать по данной таблице? Какое правило можно составить по таблице?

| | |
|---|---|
| *бар* | *барды* |
| *ал* | *алды* |
| *яз* | *язды* |

| | |
|---|---|
| *булыш* | *булышты* |
| *ярат* | *яратты* |
| *бас* | *басты* |

| | |
|---|---|
| *кил* | *килде* |
| *сикер* | *сикерде* |
| *йөз* | *йөзде* |

| | |
|---|---|
| *эч* | *эчте* |
| *кит* | *китте* |
| *сөрт* | *сөртте* |

**Ял минуты**

Туп белән уйнау.

Мин фигыль әйтәм. Сез фигыльгә үткән заман кушымчасы өстисез, түгәрәк буенча уен дәвам итә.

**3) Уен**

1) Укучылар карагыз әле, бу сүзләр өйләрен югалтканнар. Әйдәгез, булышыйк әле аларга үз өйләрен табарга *(экранда өйләр эчендә кушымчалар, балалар сүзләрне дәрес куярга тиеш)*

**4) Эш дәфтәрләрендә мөстәкыйль эшләү.**

1) Прочитать и обвести красным карандошом слова с твердым произношением, зелёным – слова с мягким произношением.

2) Дописать окончания данных слов.

**5) Телдән эшләү**

*Слайд 5*

1) Угадай что делал Гали?



*Укучылардан көтелгән җаваплар:*

Гали аш ашады.

Гали туп белән уйнады.

Гали китап укыды.

Гали алма ашады.

Гали чәй эчте.

Гали дәфтәрдә язды.

Гали машина белән уйнады.

2) Сүзнең кушымчасы ничек үзгәрә, әгәр ул эшләрне сез башкарсагыз? (Как изменились бы слова, если бы эти действия выполнял ты?


*Укучылардан көтелгән җаваплар:*

Мин аш ашадым.


Мин туп белән уйнадым.
Мин китап укыдым.
Мин алма ашадым.
Мин чәй эчтем.
Мин дәфтәрдә яздым.
Мин машина белән уйнадым.
**6) Карточкалар белән эш** *(Парларда эшләү)*
һәр парга карточка бирелә, карточкада 2 җөмлә.
- җөмләне укы
- тәрҗемә ит.
- нишләде соравына җавап булган сүзләргә сызарга.

**V. Рефлексия**.
**1) -**Дәрестә нәрсә өйрәндек?
- Нәрсә исегездә калды?
- Кайсы бирем күбрәк ошады?
- Кайсы биремнәрне эшләргә авыр булды?

(Максат һәм нәтиҗәләрдән чыгып, үз-үзләрен бәялиләр, нәрсә ошады, ошамады; аңлады, аңламады)
**2) Өй эше.**
1) Үткән заман фигыльне русчага тәрҗемә итегез.
*Бирде, укыды, яратты, язды, эчте, сикерде.*
2) Бирелгән сүзтезмәләрдән үткән замандагы фигыльләрнең, кушымчаларын билгеләргә:
*Мин яздым, син эчтең, ул барды, мин уйнадым, син бирдең, ул эшләде.*
3) Бирелгән сузләр белән җөмләләр төзергә.
*Эчте, чәй, ул. Бардың, мәктәпкә, син. Дәфтәргә, мин, яздым.*
**3) Үзбәя.**
**-** Ә хәзер без сезнең белән билгеләр иленә сәяхәткә китәбез.Тактада паровозиклар “5”ле, ”4”ле, ”3”ле билгеләре белән.
Сез үзегезне ничек,бәялисез,шул паровозга тоташтырасыз вагонны.



Укучыларда вагоннар, алар тактага чыгып вагоннарны тоташтыралар.



**4) Укучыларның эшчәнлеген бәяләү.**
Билгеләр кую. Саубуллашу.


## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ОСИНОВО БИСТӘСЕНЕҢ «В.В. КАРПОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ЛИЦЕЙ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ



**17 нче ноябрь, 2016 нчы ел**

**Татарстан Республикаы гомуми белем бирү оешмаларының туган тел укытучыларының белемен күтәрү курслары стажировкасы «Аттестация үтүче укытучының иҗади отчеты – укытучының профессиональ компитентлыгын үстерүнең һәм иҗади үсешенең бер формасы»**

**Стажировка учителей родных языков общеобразовательных организаций Республики Татарстан - слушателей курсов повышения квалификации «Творческий отчет учителя в рамках аттестации как одна из форм повышения профессиональной компетентности и стимулирования творческого роста»**







**VI сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле**

***Алкина Наилә Мәхмүт кызы,***
***Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы «В.В. Карпов исемендәге лицей» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Тема**: Әхмәт нигә елый?
**Максат:**
**Укытучы өчен:**
1. Белем бирү максаты(дәреснең предмет нәтиҗәсе):
- «Әхмәт» текстындагы яңа сүзләрне дөрес әйтергә, сөйләмдә кулланырга өйрәтү;
- текстны дөрес һәм сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү;
- шарт фигыльнең зат-сан белән төрләнешен кабатлау.
2. Үстерү максаты (дәреснең метапредмет нәтиҗәсе):
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- тиешле мәгълүматны табу өчен белешмә, сүзлектән куллану.
3. Тәрбияви максат (дәреснең шәхси нәтиҗәсе):
- хезмәткә карата уңай мөнәсәбәт тудыруга йогынты ясау.
**Укучыларга җиткерелә торган дәреснең белем бирү максаты** (дәреснең предмет нәтиҗәсе):
- «Әхмәт» текстындагы яңа сүзләрне дөрес әйтергә, сөйләмдә кулланырга өйрәнү;
- текстны дөрес һәм сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү;
- шарт фигыльнең зат-сан белән төрләнешен кабатлау.
**Дәрес тибы:** ЛГКФ
**Җиһазлау:** дәреслек (44-45 нче битләр), методик ярдәмлек, уку-язу әсбаплары, рәсемнәр, дәрескә әзерләнгән презентацион материаллар.

**Дәрес барышы:**
**I. Оештыру өлеше.**
**1. Кереш әңгәмә.**
- Исәнмесез,укучылар?
- Хәлләрегез ничек?
- Рәхмәт, минем дә хәлләрем бик яхшы. Дәресебезне башлыйбыз.
- Хәзер нинди ел фасылы?
- Бүген ничәнче число?
- Атнаның нинди көне?
- Бүген һава торышы нинди?
- Дәрестә барыбыз да бармы?
**2. Өй эшен тикшерү.**
1) Телдән тикшерү: – Сез өйдә нәрсәләр эшлисез? Үзара сөйләшегез.

2) 2 укучы тактада ЭШЛӘ фигылен шарт фигыльнең барлык һәм юклык формасында зат-сан белән төрләндерә.
Бергә тикшерү һәм бәяләү эше үткәрелә.

**3. Актуальләштерү**.

*1) Аудирование*

- Текстны укый башлаганчы татар теленә генә хас булган авазларны кабатлап китик (хор белән) : ә, ө, ү, һ, җ, ң.
- Прослушайте и укажите слова со звуком [ә]: Әхмәт, пешерә, җыештыра, әлбәттә, беркөнне, чишмә, урамдагы, үзем, елый, тәмле.
- Прослушайте и поставьте слова и словосочетания в условное наклонение:
Бара – барса, яши, эшли, юа, пешерә, җыештыра, алып кайта, ярата, булыша, авырый.

*2) Фигыль+беләм төзелмәсен кабатлау*

- Ә хәзер рус телендә үткән материалны искә төшерик әле.

| **Нишли?** | **Нишли алам?** |
|---|---|
| **(что делает?)** | **(что умею делать?)** |
| Эшли - ... | Эшли беләм- ... |
| Кер юа -... | Кер юа беләм -... |
| Аш пешерә - ... | Аш пешерә беләм- ... |
| Өй җыештыра-... | Өй җыештыра беләм-... |
| Су алып кайта- ... | Су алып кайта беләм- ... |
| Булыша- ... | Булыша беләм- ... |
| Елый - ... | Елый беләм - ... |

**II. Яңа теманы камилләштерү**

**1. Мәкаль.**

- Укучылар, әйтегез әле, бу мәкальне сез ничек аңлыйсыз?

**Яңгырдан соң кояш бар,**
**Алдаудан соң оят бар.**

- Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшербез укучылар? *(алдау турында )*
- Бүген без сезнең белән дәрестә “Әхмәт” хикәясен өйрәнә башлыйбыз.
Балалар, максатыбыз, “Әхмәт” әсәрен укып, сөйләшеп, яңа сүзләр белән танышып, күнегүләр эшләп, дөрес укырга өйрәнербез.

**2. Сүзлек эше**

Салкын чишмә суы эчсәм [салкъын чишмә суы эчсәм ] – если попью холодной родниковой воды
Сизмәс дип уйлады [сизмәс дип уйлады] – думал,что не почувствует
Терелермен кебек [тэрэлэрмэн кэбэк] – может, выздоровлю
Үзем авырыймдыр [үзэм аwырыймдыр] – наверное, сама болею
Әлбәттә [әлбәттә] - конечно
Кызганычка каршы [къызгъанычкъа къаршы] – к сожалению
Ерактагы чишмәдән [йыракътагъы чишмәдән] – с дальнего родника

-Тактада сүзләр язылган, укытучы укый, хор белән кабатлау, сүзлек дәфтәрләренә язу.
- Дөрес тәрҗемәне табыгыз.

**3. Текстны уку.Чылбырлап уку.**

**4. Физминутка.**

*«Матур утыр, ят, йокла, уян, юын, аша, бас, сикер, чүгәлә, бас, урында йөгер, тукта, тәрәзәгә кара, ишеккә кара, укытучыгы кара, матур утыр»* укучылар сүзлрен кулланып укытучы артыннар хәрәкәтләр ясыйлар.

**5. Ныгыту, ягъни текстның эчтәлеген аңлау, сөйләм үрнәкләрен аралашуда куллану.**

***1. Әсәрнең эчтәлеге буенча фикер алышу.***

- Хикәя сезгә ошадымы?

1. Әхмәт кем белән яши?
2. Алар кайда яшиләр?
3. Әнисе өйдә нинди эшләр эшли?
4. Әхмәт аңа булышамы?
5. Беркөнне кем авырды?
6. Әнисе аңа нәрсә диде?
7. Әхмәт суны кайдан алды?
8. Синеңчә,Әхмәт нинди малай?

***2. Әйдәгез, Әхмәткә характеристика бирик, укучылар.***

-Менә,безнең Әхмәт. Шушы сыйфатлар арасыннан аңа кайсы сыйфатлар туры килә икән?

(Эшчән, тырыш, ялкау, әдәпле, эш яратмый, уйнарга ярата, тәрбиясез, тыйнак, алдакчы, ихтирамлы,әнисенә булыша)

***3 . Рәсемнәргә карагыз. Рәсемнәрне текст эчтәлеге буенча урнаштырыгыз.***

8 рәсем бирелгән:

- Әхмәт әнисе белән яши.
- Әхмәтнең әнисе күп эшли.
- Әхмәтнең әнисе еректагы чишмәдән су алып кайта.
- Әхмәт көне буе урамда уйный.
- Беркөнне Әхмәтнең әнисе авырды
- Ул: “Улым,чишмәдән су алып кайт әле”,- диде.
- Әхмәт суны урамдагы коедан алып кайтты.
- Әнисе суны эчте дә: «Рәхмәт , улым. Ләкин бүген су нигәдер тәмле түгел»,-диде. Әхмәт елап җибәрде.

- Әйтегез әле,укучылар,ни өчен Әхмәт елады?
- Ул әнисен яратамы?ничек уйлыйсыз
- Болай булгач, Әхмәт тәрбияле малайга әйләнә алыр микән?

***4. Ситуатив күнегүләр***

- Әйдәгез,Әхмәткә киңәшләр бирик әле

1. Әхмәт нужно помогать маме;
2. Әхмәт нельзя врать .
3. Әхмәт нужно быть воспитанным мальчиком.

4. Әхмәт много не играй

- Бу киңәшләрне тотса, Әхмәт әйбәт малайга әйләнерме? Ул вакытта ул нинди малай булыр икән,тактагы эшне эшләп бетерик.

***5. Дәфтәрләрдә эш.***

а)Җөмләләрне язып бетер.

Әхмәт әнисенә булышса,..... .

Әхмәт алдашса,... .

..., Әхмәт чишмәдән су алып кайта.

..., әнисе рәхмәт әйтә.

б) Карточкалар белән эш

- Укучылар,сезнең алыдгызда карточкалар ята,төшеп калган кушымчаларны өстәп фигыльне хәзерге заманда төрләндерегез (перед вами лежат карточки,в предложения нужно добавить пропущенные окончания)

Мин елга... су алып кайт... .

Син кое... су алып кайт... .

Ул күл.. су алып кайт... .

Без колонка... су алып кайт... .

Сез чишмә... су алып кайт... .

Алар чишмә... су алып кайт... .

- Эшләп бетергәч,карточкаларны алмашабыз,һәм бер- беребезне тикшерәбез һәм билге куябыз.

**III. Йомгаклау**

**1. Нәтиҗә ясау**

- Әйдәгез, дәресебезгә йомгак ясыйк инде. Укучылар, без бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләштек?

-Әти –әниләргә,олыларга булышу турында,алдашырга ярамау турында сөйләштек. Әйдәгез,дәрес башында укыган мәкальне искә төшерик. Бу мәкаль безнең әсәргә туры киләме? Алдашу – начар гадәтме?Әниләргә булышырга кирәкме?

- Әниләргә булышырга кирәк

- Алдашырга ярамый.

-оят булмасын өчен алдашырга кирәкми

**2 . Өйгә эш бирү**

Көндәлекләребезне ачабыз, өйгә эшне язып куегыз.

* 1. Тема буенча рәсем ясарга һәм сөйләргә

* 2. Мәкаль,табышмаклар табып килергә

**3. Рефлексия.**

- Сезнең алдыгызда карточкалар бар,. Хәзер һәрберегез үзегезгә бәя бирегез әле. Сез бүгенге дәрестә ничек эшләдегез? Ничек катнаштыгыз? Үзегезгә ничәле куяр идегез?

## VI сыйныфта укучы рус балаларына - әдәбият теле

***Сафина Резида Габдельхак кызы,***
***Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы «В.В. Карпов исемендәге лицей » муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Тема:** Ә.Еникинең «Матурлык» әсәренә анализ.
**Максат:**
1. Әсәргә тулы анализ бирү бирү нигезендә автор фикеренең асылын ачыклау.
2. Төп фикерне һәм сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен таба белү күнекмәләрен, фикерләү сәләтләрен үстерү.
3. Әхлак сыйфатлары тәрбияләү, тирә-юньдәгеләрнең уй-хәрәкәтләренә бәя бирергә өйрәтү.
4.Үзенне карап үстергән әниеңә,башкалар өчен бик кадерле булган аналарга тирән хөрмәт һәм мәхәббәт ,үз әниең белән горурлану хисләре тәрбияләү.
**Җиһазлау:** автор портреты, комьютерда презентация, музей экспонатлары.

**Дәрес барышы.**
**I. Эшчәнлеккә юнәлеш бирү.**
*1. Уңай мохит тудыру.*
- Бүгенге дәресне шигырь юллары белән башлап җибәрәсем килә:

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул мәлдә –
Иң авыр минутында да
Тормышка гашыйк хәлдә;
Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул вакыт –
Иле өчен, халкы өчен
Яшәгәндә җан атып;
Замананың авырлыгын
Җилкәсенә алганда;
Олы данга ирешеп тә,
Кече булып калганда.

Бу юлларны, татар шагыйре язган. Ә матурлык дигәнне сез ничек аңлыйсыз? (Балаларның җаваплары тыңлана).
- Матурлыкны һәр җирдән табарга, һәр адымда тоярга була икән.

*2. Уку мәсьәләсен кую.*
Укучылар ничек уйлыйсызбез ***Ә.Еники без үткән дәрестә өйрәнгән хикәясен ни өчен “матурлык” дип исемләде икән?***
- *Балалар җаваплары.*
- Бу сорауга җавап бирү өчен дәрестә нәрсә эшләрбез?
(«Матурлык» әсәрен анализларбыз)

- Төп максатыбыз нәрсә булыр? Ни өчен кирәк булды безгә бу әсәрне уку?
(Без автор әйтергә теләгән төп фикерне табарга тиеш)
- Сөйләшүгә сез әзерме?
3. *Белемнәрне тигезләү*.
- Алай булгач, әйдәгез, дәресебезнең планын төзеп куйыйк. Әсәрне анализлау өчен без нинди адымнар ясарга тиеш.
1) Хикәяне өлешләргә бүлү
3) Каршылыкны табу
4) Геройларга характеристика
5) Авторның фикерен табу.
6) Нәтиҗә ясау.
Әсәрнең эчтәлеген аңлауларын тикшерү
- Хикәядәге катнашучы геройларны атагыз.
(Автор-шәкерт, Гыйлемдәр, Бәдертдин, аның әтисе, әнисе һәм без)
- Без әсәрдә ничек катнашабыз?(Автор белән сөйләшәбез

**II. Уку мәсьәләсен чишү.**
Хикәяне өлешләргә бүлү
1. Тургайлы юл.
2 . Бәдертдиннең әтисе.
3. Өй эче күренеше.
4. Чәй әзерләү.
5. Бәдертдиннең әнисе.
6. Скрипка көе.
7. Авторның кичерешләре.
Әсәрне күзаллау нигезендә югарыдагы бүленеш барлыкка килә.
- Автор ни өчен тургайларга игътибар итә? Тургай сайравының сихере нәрсәдә? (Уку җавап табу).
1) Барлык табигать тургай сайравын тын калып тыңлый.
2) Дөнья киңәеп, матураеп китә.)
- Менә авыл юлы (Слайд 5). Нәрсә күрәсез?
(Юл, ике якта чәчәкле болын. Юл уртасыннан атлы арба бара.)
Хикәягә туры киләме? (Әйе, шәкертләр укулар беткәч, өйләренә кайталар ).
- Хәзер һәркем үзен шушы атның арбасында бара итеп күз адына китерсен. Күренешне хәтердә калдырыгыз. Күзләрне йомдык.
(Тургай сайравын магниофон ярдәмендә тыңлау).
- Чыннан да матур итеп сайрыймы тургай?
- Экранга карагыз әле, нәрсә күрәсез? (Авыл күренә)
Авыл өйләре салам түбәле, өйлр кечкенә, киртә койма.
- Шәкертләрне кем каршы ала? (Бәдертдиннең әтисе)
- Бәдертдиннең әтисен нинди итеп күз алдына китерәсез? Портретын сүрәтләгез. (Уку)
- Матурмы Бәдертдиннең әтисе? (Юк)
- Ишек аллары нинди? (Уку)

-  Өй эчендә нинди җиһазлар бар?
Зур сәке. Анда йоклаганнар да, ашаганнар да. Шәкертләргә чәй табыны әзерлиләр.
- Нинди ризыклар куелган була анда? Чәй табынына карап нәрсә әйтә алыр идегез? (Бәдертдиннәр бик ярлы яшәгәннәр)
- Бу слайдта кем турында язылган? (Җавап).
- Матурмы аның әнисе?
- Матур сүзен әйттекме әле? (Юк.)
- Ни өчен әйтмәдек? (Ярлылык, ямьсезлек кенә күрдек?)
- Бу ямьсезлек турында безгә кемнәр әйтте? (Автор )
Төп геройлар  әнигә карап ниниди хисләр кичерә?
Автор:
Чиркану
Кызгану
Аптырау.
- Иң өстен хис кайсы?
Аптырау: Бәдертдин бу ямьсез әнине ничек кешегә күрсәтә?
- Чәй эчкәннән соң, Бәдертдин иптәшләренә нәрсә күрсәтте?
(Скрипка. Ул скрипкада уйный)
- Скрипкада Бәдертдин искиткеч матур итеп уйныймы? Иптәшләре сокланып тыңлыймы? Автор бу турыда безгә нәрсә әйтә?
(Скрипкада матур уйнау турында әйтелми.)
- Автор нәрсәгә игьтибар итә? (Укытучы укуы)
(Бәдертдиннең әнисе өчен уйнавына)
- Бәдертдиндә нинди хисләр чагыла?
Аз гына кызгану, Өзелеп ярату, Беткәнче аңлау, Кадерләү, Юату
- Иң өстен хис кайсы? (Өзелеп ярату)
- Укучылар тиздән әниләр бәйрәме җитә.Ә сез бу бәйрәмдә әниләрегезне ничек сөендерерсез?
**Әниләргә әзерләнгән бүләкләр**
- Автор куйган сорауга җавап бирә алабызмы? Ни өчен Бәдертдин ямьсез әнисен безгә күрсәтте икән? (Ул аның ямьсезлеген күрми, чөнки безнең кебек үк  өзелеп ярата)
Авторның соңгы кичерешләре нинди?
(Уку: Ямьсез түгел бит ул, матур бит ул, матур, матур Бәдертдиннең әнисе!)
- Кем үзгәртте авторның фикерен? (Бәдертдин)
- Бәдертдингә нинди характеристика бирәбез?
Оста куллы – үзе скрипка ясаган
Белемгә омтыла
Моңлы – тургай кебек
Әнисен олылый.
- Әнинең матурлыгы кайда күренә? Бу турыда язылганмы? (Юк)
- Ә каян беләбез бу турыда?

- Автор безгә шулай әйтергә тели,  үзләре тапсыннар, ди.  (Әнинең күңеле матур: Акыллы. Игелекле малай үстергән)

**III. Рефлексия.**
Без авторның” Ямьсез түгел бит ул, матур, матур Бәдертдиннең әнисе! “-дигән фикеренә кушылдык.Дәрес башында куйган сорауга җавап таптык.
**- Кешенең эчке дөньясы матур булырга тиеш.**
- Бәдертдиннең әтисе-әнисе үзләрен чын күңелдән яраткан бала үстергәннәр. Ә хәзер кулларыбызны күтәреп,  күкрәгебез алдына куябыз. Сул кулыбыздагы бармакларыбыз эчке матурлыкны күрсәтә, ә уң кулыбыздагы бармакларыбызны тышкы матурлык дип уйлыйк. Бу матурлыклар менә шулай кушылып, бербөтен булып, бездә яшәргә тиеш *(бармакларыбызны “йозак ” итеп берләштерәбез).* Тормыш юлыгызда, ялгышмыйча, МАТУР кешеләр белән генә аралашып яшәргә язсын. Мин сезнең дөньяда МАТУР кеше булып яшәвегезне телим һәм шулай булыр дип ышанам да.
IV. Үзбәя, билгеләр кую.
V.  Өй эше:
1. «Иң  кадерле, газиз кешем! » темасына хикәя язарга.
2. Хикәянең эчтәлеген сөйләргә.

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**С.К. ГЫЙМАТДИНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ**
**ОСИНОВО ГИМНАЗИЯСЕ» МУНИЦИПАЛЬ**
**БЮДЖЕТ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

---

**25 нче ноябрь, 2016 нчы ел**

Зеленодолмуниципаль районы гомуми белем бирү учрежделәренең
татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен муниципаль семинар
**«Татар мәктәпләрендә ФДББС тормышкаашырушартларында**
**татар теле һәмәдәбиятыукытучыларыныңтьюторлыкэшчәнлеге»**

Муниципальный обучающий семинар для учителей общеобразовательных
организаций Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан
**«Тьюторское сопровождение учителей татарского языка и литературы**
**на этапе введения и реализации УМК по татарскому языку**
**для школ с родным (татарским) языком обучения»**









***Корманова Гөлгенә Хәйдәр кызы,***
***ФДББС тормышка ашыруда Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының татар теле һәм әдәбияты буенча тьюторы,***
***С.К.Гыйматдинов исемендәге Осиново гимназиясенең I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Тема: Федераль дәүләт белем бирү стандартлары шартларында заманча дәрескә таләпләр**

Бүгенге көндә **федераль белем бирү стандартлары** гамәлгә керде һәм ул безнең алга җитди бурычлар куйды. Ул бездән, моңа кадәр яшәп килгән гадәти дәресләр, тәрбия чаралары белән генә чикләнеп калмыйча, яңача эш итүне таләп итә.

**Безнең төп максат** - укучыларга белем бирү генә түгел, ә аларны белем алырга, алган белемнәрен тормышта кулланырга өйрәтү. Бу исә бездән яңа алымнар һәм методлар кулланып эш итүне, бүгенге көн таләпләренә җавап биргән заманча дәрес оештыруны таләп итә.

Мирза Исмәгыйль улы  Мәхмүтов дәрескә түбәндәге аңлатманы бирә: “**Дәрес** – белем, тәрбия бирү, үстерү бурычларын хәл итеп, укытучы һәм укучылар катнашында, системалы һәм билгеле бер вакыт аралыгында кулланыла торган укучы эшчәнлеген оештыру формасы”.

Заманча дәреснинди булырга тиеш? **Заманча дәрес** нәтиҗәле, гамәли; бала, ата-ана, җәмгыять, дәүләт кызыксынуы белән турыдан-туры бәйләнештә булырга тиеш. Биредә  беренче урында – кабул ителгән дәрес структурасы(өй эшен тикшерү, яңа теманы аңлату, ныгыту, кабатлау, билгеләр кую, өй эше бирү, дәрескә йомгак ясау)буенча дәрес алып бару түгел, ә баланың мөстәкыйль эшчәнлеген оештыру бурычы тора.

**Бүгенге дәрескә нинди таләпләр куела соң?** Иң беренче чиратта, ул барлык шартлары булган, заманча җиһазландырылган кабинетта  узарга тиеш. Икенчедән, укытучы дәреснең максат һәм бурычларын дөрес билгеләргә, эш төрләрен һәм укучы эшчәнлеген планлаштырырга тиеш. Өченчедән, дәрес проблемалы һәм укучының үсешенә хезмәт итәргә, үзара хезмәттәшлеккә этәрергә тиеш. Дүртенчедән, укытучы укучыларны эзләнергә, актив эшләргә, фикерләргә өйрәтергә тиеш. Менә болар барысы да укучыларны үзләре нәтиҗә чыгара белергә, иҗадилыкка ирешергә, аларның сәламәтлеген саклауга,мөмкинлекләрен истә тотып, нәтиҗәлелеккә ирешүгә шарт тудыра.

| **Дәрескә таләпләр** | **Традицион дәрес** | **Заманча дәрес** |
|---|---|---|
| **Дәреснең темасы** | Укытучы дәрес башында теманы хәбәр итә | Укучылар, укытучы куйган проблеманы чишеп, теманы формалаштыралар |
| **Максат һәм бурычларны билгеләү** | Укытучы, темадан чыгып, максатны әйтә | Укучылар, проблеманы чишүдә барлыкка килгән авырлыкларны истә тотып, дәреснең максатын |

| | | |
|---|---|---|
| | | формалаштыралар |
| **Планлаштыру** | Укытучы максатка ирешү юлында нинди эшләр белән шөгыльләнәчәкләре турында игълан итә | Укучылар, максатка ирешү өчен, эшчәнлекләрен оештыралар |
| **Укучыларның гамәли эшчәнлекләре** | Укытучы җитәкчелегендә укучылар биремнәр башкаралар (еш кына фронталь тикшерү методы кулланыла) | Укучылар алдан килешенгән план буенча уку эшчәнлеген оештыралар (төркемдә, парлап, индивидуаль эшләү формалары кулланыла) |
| **Контрольне тормышка ашыру** | Укытучы  укучыларның эшчәнлекләрен тикшерә | Укучылар үзконтроль булдыралар(үзтикшерү, берсен-берсе тикшерү формалары кулланыла) |
| **Коррекция үткәрү** | Укытучы, укучыларның эшләрен тикшереп, хаталарны төзәтә | Укучылар, укытучы биргән кретийларга нигезләнеп, үз хаталарын үзләре төзәтәләр |
| **Укучылар эшчәнлеген бәяләү** | Укытучы укучылар эшчәнлеген бәяли | Укучылар үз эшчәнлегенең нәтиҗәсе буенча үзләрен(бер-берсен) бәялиләр |
| **Өйгә эш** | Укытучы өйгә эш бирә | Укучылар, индивидуаль мөмкинлекләреннән чыгып, укытучы тәкъдим иткән берничә бирем арасыннан үзләренә ошаганнарын сайлап алалар |

**Ә бүгенге көн татар теле дәресе нинди булырга тиеш соң?** Укучылар үз фикерләрен җиткерергә кыенсыналар, сүз байлыгы бик ярлы булганга, алар аралаша алмый. Укучыларда туган телгә мәхәббәт һәм кызыксынуны ничек уятырга соң? Дәрес укучы өчен артык катлаулы булмаска, аны эзләнүгә этәрергә тиеш.

Безнең алда  бик тә җаваплы һәм әһәмиятле **бурыч** тора. Беренчедән, телебезне саклап калу бурычы булса, икенчедән, укучыларда телне өйрәнүгә кызыксынуны бетермәү, киресенчә, бу кызыксынуны үстерү бурычы. Бу укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм, заман таләп иткәнчә, югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булуын таләп итә.

Фәнгә, телгә мәхәббәт уяту өчен,**яңа методик алымнар** эзләргә туры килә. Дәреслек нинди генә булмасын, зурмы ул, әллә кечкенәме, рәсемлеме, рәсемсезме, авторы кем, теге, я бу галимме, барыбер көткән нәтиҗәләргә ирешеп булмаячак. Индивидуаль якын килеп эшләгәндә генә, укытучы укучыларында үз фәненә карата мәхәббәт уята, тормышка яраклы шәхесләр тәрбияли ала. Баланың берсе укытучы әйткән сүзне шул мизгелдә үк “эләктереп” алса, икенчесенә берничә тапкыр кабатларга кирәк, ә өченчесе исә,

күнегүләр эшләү, проблемалы биремнәрне чишеп кенә теманы аңлауга ирешә. Шуның өчентөрле алымнар кулланырга кирәк.

Креатив укытучы дәресне иҗади оештырырга ярдәм итүче **алдынгы педагогик технологияләр** куллануны алгы планга куя. Шуларның берсе – **креатив фикерләү үстерү алымы**.

Бу технология укучыга иҗади яктан үсәргә шартлар тудыра. Бала һәр дәрескә теләк белән килсен өчен, аңарда канәгатьләнү тойгылары уятырга, аны максатка юнәлешле эшчәнлеккә сиздерми җәлеп итәрлек эш формалары тәкъдим итәргә кирәк. Креатив фикерләү үстерү алымының төрле ысуллары бар: “кәрзин” ысулы, синквейн, дидактик уен, төркемнәрдә эш оештыру, терәк конспект һ.б. Балалар үз фикерләрен расларга тырышалар, хаталар төзәтелә, төп нәтиҗәне ясыйлар.

Дәресләр укытучы һәм укучы арасында үзара хезмәттәшлеккә нигезләнә. Укучыларны кызыксындыру максатыннан, эш күбрәк төркемнәрдә оештырыла. Төркемдәге һәр бала үз фикерен әйтә, башкалар фикерен ишетә ала. Дәрес вакытында ялкаурак булган укучы да фикер туплап калырга мәҗбүр була.

Шулай булгач, төркемнәрдә эш укучыларны сөйләргә, аралашуга өйрәтүдә бер уңышлы юнәлеш булып тора. Балага үзен шәхес итеп тойдыру, ул эшләрдәй эшләрне, беркем дә аннан яхшырак эшли алмаячагына төшендерү- төп педагогик бурычыбыз булырга тиеш.

**Яңа белемнәрне үзләштерү дәресенең структурасы.**

1) Оештыру этабы. Укучыларны актив эшчәнлеккә җәлеп итү, уку материалын үзләштерүгә кызыксыну уяту, сыйныфта уңай эмоциональ атмосфера булдыру.

2) Белемнәрне актуальләштерү. Бүгенге темага нигез булырлык үткән материалны кабатлау, укучыларга авыр тоелган урыннарны ачыклау, өй эшләренә анализ ясау.

3) Яңа белемнәрне беренчел үзләштерү. Уку мәсьәләсен кую буенча проблеманы ачыклау, дәреснең темасын билгеләү,максат һәм бурычларын кую, төркемләп, парлап эшләү.

4) Яңа белемнәрне үзләштерүне тикшерү. Укучыларның критерийлар (өлге) буенча үзләрен тикшереп барлавы.

5) Яңа белемнәрне ныгыту. Бергәләп, чиратлап, яңа белемне кабатлау, терәк сигнал формасында теркәү.

6) Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү.

Өйгә эш өч дәрәҗәдә тәкъдим ителә:

1. Сыйныфта үзләштергән белем һәм күнекмәләр таләп ителгән эш.
2. Ярымиҗади, ягъни белем һәм күнекмәләрне яңа шартка күчерүне таләп иткән эш.
3. Иҗади, ягъни белем һәм күнекмәләрне яңа җирлеккә кую

8) Рефлексия (дәрескә йомгак ясау). укучыларның үз уку эшчәнлеген, сәләтләрен дөрес бәяләү, башкаларның эшчәнлеген күрә һәм дөрес анализлый белүе.Нинди максатлар куйган идек? Максатларга ирештекме? Ничек?

Нәтиҗәләр нинди? Бүгенге белемне тормышта кайда һәм ничек кулланырга мөмкин? Синең бигрәк тә кайсы эшең уңышлы килеп чыкты?

Яңалыкны кабул итү, аны тормышка ашыру бервакытта да җиңел генә бармый, әлбәттә. ФДББС укытучыдан төрле яктан җентекле әзерлек таләп итә. Һәр укытучы туктаусыз эзләнергә тиеш. Үз-үзенә таләпчән, эзләнүчән, үз һөнәрен яратып башкаручы укытучылар дәресләрен заманга туры китерелек итеп әзерләр дигән фикердә калам.

## IV сыйныфта укучы татар балаларына - татар теле

***Гатауллина Гөлгенә Равил кызы,***
***Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы С.К.Гыйматдинов исемендәге Осиново гимназиясенең югары квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы***

**Дәреснең темасы**: Фигыльнең мәгьнәсе һәм сораулары.

**Максат:**

Фигыль турында белемнәрне барлау, системалаштыру. Фигыльнең мәгьнәсен ачыклау, сорау кую үзенчәлекләрен өйрәнү.

**Бурычлар:**

- алган белемнәрне биремнәр эшләүдә куллана белергә күнектерү;
- иҗади фикерләү сәләтләрен, игътибарлылыкны үстерү өстендә эшне дәвам итү;
- теманы тирәнтен өйрәнүгә ихтыяҗ тудыру, телгә карата кызыксыну тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

***шәхескә кагылышлы***: үз белемеңне күтәрү өстендә һәрвакыт эшләү теләге үстерү, үзмаксат куя белү;

***метапредмет***: ысул чыгару күнекмәсе булдыру;

***предмет***: фигыльләрне танып, сорауларны дөрес куеп, биремнәр эшләү

**Дәрес тибы**: яңа белемнәр үзләштерү.

**Чыганаклар:**

1. Татар теле. И. Х. Мияссарова, И. Ф. Фәйзрахманова.Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 4нче сыйныфы өчен дәреслек, 2 кисәктә, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2013, 1 нче кисәк.

2. Җамалетдинова З. И. Татар теле дәресләре. 4 нче с-ф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары укытучылары өчен метод. кулланма/З.И. Җамалетдинова. – Казан: Татар кит. нәшр., 2014

**Шартлы тамгалар:**

ШУУГ –шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре;

РУУГ- регулятив универсаль уку гамәлләре;

ТБУУГ- танып - белү универсаль уку гамәлләре;
КУУГ-коммуникативуниверсальукугамәлләре
**Җиһазлау:** 1. Интерактив такта өчен презентация (elite panaboard book), компьютер, карточкалар.

| Дәрес этаплары | Дәрес этабының максаты | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсальук угамәлләре (УУГ) |
|---|---|---|---|---|
| **Оештыру. Эшчәнлекк әмотив лаштыру** | Психологи куңайжирл ектудыру. | **Исәнләшү, утыру.** Балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү теләге булдыру. | | КУУГ: сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү. ШУУГ: үзмаксат кую |
| **Белемһәм күнекмәләр не тигезләү** | Исем турында үзләштергән белемнәрне мөстәкыйль рәвештә искә төшерү мөмкинлеге булдыру | **Өй эшен тикшерү** - ..., өй эшләрен барлык укучылар да эшләгәнме? - Кем җавап бирә? | Өй эшләренең башкарылуын тикшерү өчен билгеләнгән укучы җавабы. *Укучылар җавабы*. 1) “Әни” темасына 10 сүз язарга; 2) “Әни” темасына 5 җөмлә төзергә; 3) “Әни” темасына хикәя язарга. Исемнәрне билгеләргә Үзбәя | ТБУУГ: исем турында мәгълүматны файдалана белү. КУУГ: диалог төзүһәм коллектив фикералышуда катнашу |
| **Дәреснең темасын һәм максатын ачыклау** | Фигыльне таба, дәреснең темасын ачыклый, максат куя | **- Мин хәзер бер шигырь укыйм. Бу шигырь турында нәрсә әйтә** | Җаваплар: - Әни турында; - *Әни – кадерле кеше.* - *Бу якшәмбедә әниләр көне* | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белү. | **аласыз?**<br>*Юа, җыя, агарта,*<br>*Кисә, турый, чистарта.*<br>*Пешерә, тиз өлгертә,*<br>*Шатландыра, көлдертә,*<br>*Елаганда – юата,*<br>*Җырлый – җырлый йоклата,*<br>*Ул бит безне ярата!*<br>**- Фигыль нәрсә соң ул?**<br><br>(Балаларның җаваплары тактага язып барыла)<br><br>**- Ничек уйлыйсыз, фигыль турында бөтен нәрсәне дә белеп бетердекме?**<br><br>**- Дәфтәрләрдә число язабыз.**<br><br>**-Тактадагы сүзләрне күчереп язабыз.** | *була һ.б.*<br>*- Шигырь нишли? сорауларын җавап бирүче сүзләрдән тора*<br>*-Шигырьдә фигыльләр генә һ.б.*<br><br>- сүз төркеме;<br>- нишли? соравына җавап бирә;<br>- зат – сан белән төрләнә;<br>- барлык – юклык формасы бар;<br>- заманнары бар һ. б.<br><br>Җаваплар<br><br>Число, сыйныф эше.<br><br>**Күчереп язу (баганалап):**<br>Сикерә, елады, язар, йоклый, йөгерде, шатлана, юар.<br><br>*(Җаваплар)*<br>Слайд2 | ТБУУГ: танып - белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклау һәм максат кую |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Сүзләрне анализлыйбыз.**<br>- бу нинди сүзләр?<br>- алар нәрсәне белдерәләр?<br>- алар нинди сорауга җавап бирәләр?<br><br>- Димәк, бүгенге тема: “... “ <u>Фигыльнең мәгънәсе һәм сораулары”.</u> Дәфтәрләргә язабыз.<br>**- Ничек уйлыйсыз, без бүген дәрестә нәрсә эшләргә тиеш?**<br>**- Ничек уйлыйсыз, без ни өчен бу теманы өйрәнәбез?** | Дәрескә максат кую.<br><br>(Җаваплар) | |
| **Уку мәсьәләсен чишү** | Кагыйдә чыгару. | **- Тактадагы биремгә кире кайтыйк. Сорауларын, нәрсә белдергәнен языйк.**<br><u>Сикерә</u> хәрәкәт (нишли?)<br><u>елады</u> хәл | Дәфтәрләрдә язма эш, берничә укучы тактада эшли | ТБУУГ: күзәтү, нәтиҗә ясау<br><br>РУУГ: кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу<br><br>КУУГ: |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | (нишләде?)<br>язар эш<br>(нишләр?)<br>йоклый хәл<br>(нишли?)<br>йөгерде<br>(нишләде?)<br>хәрәкәт<br>шатлана хәл<br>(нишли?),<br>юар эш<br>(нишләр?)<br><br>- Төркемнәрдә киңәшләшеп, бу сүзләрнең нәрсәне белдерүен, мәгънәсен ачыклагыз.<br><br>- Ни өчен аларга төрле сораулар куйдыгыз?<br><br>- Үткән, хәзерге, киләчәк заман нәрсәне белдерә? | **1 нче нәтиҗә:**Фигыль предметның эшен, хәрәкәтен, хәлен белдерә.<br>Слайд 2<br><br>(Җаваплар)<br><br>(Җаваплар)<br><br>**2 нче нәтиҗә:** Фигыльнең 3 заманы бар.<br><br>Слайд2<br><br>Үзбәя | төркемнәрдә фикерләшеп эшли белү |
| | Ысул чыгару. | **- Укучылар, фигыльне тану өчен нишлибез?** | (Җаваплар)<br>**Ысул:**<br>- сүзләрнең мәгънәсен ачыклыйбыз; - сорау куябыз<br>- нәтиҗә ясыйбыз.<br><br>Мәсәлән, “бара” сүзе | РУУГ: ысул чыгару күнекмәсе булдыру |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | хәрәкәтне белдерә, нишли? соравына җавап бирә, хәрәкәт хәзерге вакытта – шуңа ул хәзерге заман хикәя фигыль. | |
| | Фигыльнең заманнарын аера белү. | **Физкультминут:** - мин сүзләр әйтәм, ул сүз үткән заманда булса, 1 рәттәге, хәзерге заман булса, 2 рәттәге, киләчәк заман булса, 3 рәттәге укучылар басарга тиеш. *Килде, җыя, курыкты, басар, алыр, килми, бармый, уйлады, шүрли, кызара, көтәр, бии, кермәде* | Физкультминут | ШУГГ: үз мөмкинлекләреңне бәяләү<br><br>ТБУУГ: фикерләүдә логик чылбыр төзү |
| | Өйрәнгән белемнәрне практикада куллана белү. | **- дәфтәрләрдә 112 нче күнегүне эшлибез** | Өзекне укыйлар (әкият әнисен тыңлаган бала турында икәнлегенә игътибар иттерелә), калын | РУУГ: кагыйдә буенча гамәлләр кылу<br><br>КУУГ: коллектив фикер алышуда |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | хәрефләр белән бирелгән фигыльләрне, заманнарын билгеләп, күчереп язу.<br>Үзбәя<br>Слайд | катнашу<br><br>КУУГ: күршең белән хезмәттәшлек итү.<br><br>ШУУГ: үз белемеңне күтәрү өстендә һәрвакыт эшләү теләге үстерү |
| | | - Хәзерге замандагы фигыльләр уйлау;<br>- Үткән замандагы фигыльләр кергән җөмләләр уйлау.<br>- Киләчәк заман фигыльләр кергән 2-3 җөмләдән торган кечкенә текстлар уйлау. | Телдән эш<br><br>Үзбәя | |
| | | - **карточкалар да биремнәр:** бирелгән фигыльләрне киләчәк (1вариант) һәм үткән (2вариант) заман формаларына куеп язарга: *Уйлый, чаба, сулый, уйный, чишә, сөйли, ашый* | Парларда эшләү.<br><br>Слайд .<br>Тикшерү. | |
| **Укуэшчәнле** | Дәрестәге | -Укучылар, | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **генйомгаклау. Рефлексия.** | эшчәнлекне анализлау, белемнәрне бәяләү <u>Укучылар өчен максат</u>: үз фикереңне дәлилләү, дәрестә алган белемнәрнең әһәмиятен аңлау, аларны киләчәктә куллана белү | без нинди теманы өйрәндек?<br>- Нәрсә белдек?<br>-Ничек белдек?<br>- Авырлыклар булдымы? | *Җаваплар*<br><br><u>Үзбәя</u> | РУУГ: эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү<br><br>ШУУГ: үз уңышларың һәм уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү |
| | Алдагы дәрескә проблема кую | -Ничек уйлыйсыз, киләсе дәрестә нәрсәне өйрәнербез? | *(Фикерләр: фигыль турында өйрәнүне дәвам итәрбез)* | ТБУУГ: фигыльләрне табу, билгеләү ысулын тормышта куллану |
| | Өй эшен хәбәр итү, аны башкару ысулын аңлату | 1) 113 нче күнегү, калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә сораулар куеп, аларны күчереп язарга.<br>2) үткән, хәзерге, киләчәк заман хикәя фигыльләргә 5 әр мисал уйлап язарга.<br>2) Әдәбият | Саубуллашу | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | дәреслегендәге Г. Рәхимнең “Көзге урман” шигыреннән фигыльләрне табып язарга, мәгънәсен билгеләргә. -Дәресебез тәмам. | | |

**III сыйныфта укучы татар балаларына - татар теле**

***Миңнуллина Гөлфия Рифкать кызы,***
***Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы С.К.Гыйматдинов исемендәге Осиново гимназиясенең югары квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы***

**Дәреснең темасы: Берлек һәм күплек сандагы исемнәр**
**Максат.** Укучыларны исемнәргә күплек сан кушымчаларын дөрес ялгап әйтергә һәм шул кушымчаларны дөрес язарга өйрәтү, орфографик сизгерлекне, грамоталылыкны үстерү, каллиграфик дөрес язуны камилләштерү, бәйләнешле сөйләм күнекмәсен арттыру. Хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү.
**Дәреслек.** Татар теле: 3 нче сыйныфы өчен дәреслек / И.Х.Мияссарова, К.Ф.Фәйрахманова - Казан: Мәгариф -Вакыт., 2013.
**Җиһазлау.** Тема буенча презентация, компьютер, экран, карточкалар, татар теленнән кулланма.
**Дәрес тибы:** яңа материалны аңлату.
Дәрес барышы:

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Һәр этапның өйрәтү һәм үстерү биремнәре** |
|---|---|---|---|
| **I. Оештыру.** | | | |
| 1.Уңай психологик халәт булдыру. <u>*Максат:*</u>Балаларны активлаштыру, белем алырга | Дәрескә оештырып алып кереп китү. | Балалар,каршыдагы иптәшләре белән сәламләшәләр һәм урыннарына утыралар. | - Хәерле көн укучылар!<br>- Хәерле көн!<br>Укучылар, бүген нинди матур кышкы көн. Бер-беребезгә матур итеп елмаеп карыйк, иптәшебезгә уңышлар телик һәм |

| | | | |
|---|---|---|---|
| теләк, әзерлек алып бару. | | | урыннарыбызга утырыйк. |
| **II. Белемнәр-не актуаль-ләштерү.**<br>*Максат:*<br>Алдагы дәрестә алган белемнәрне искә төшерү. | **Дәреснең темасын билгеләү** | Л, л хәрефләрен дөрес тоташтырып язуны ныгыту. Күплек сандагы исемнәрне таптыру, кушымчаларын билгеләтү. | Матур язу күнегүе.<br>***Лл Лл Лл Лл***<br>***Җылы якка очучы кошлар-Сандугачлар,тургайлар, Карлыгачлар,аккошлар.***<br><br>Өзектән исемнәрне таптыру, күплек сан кушымчаларын билгеләргә күнектерү. |
| Яңа материални өйрәнүгә кереш.<br>*Максат:*<br>Предметларның бер һәм берничә булуын ачыклау. | Берничә предметның берничә рәсеме күрсәтелә. Һәр рәсемне санату, сораулар куярга өйрәтү **(нәрсә?-нәрсәләр? кем?-кемнәр?**<br>**Күплек сан кушымчалары белән таныштыру.** | Һәр предметның берәр булуын билгеләтү<br><br>Бердән артык икәнлеген билгеләргә күнектерү.<br><br>Исемнәр уйлату, исемнәрне күплек санга куеп әйтү күнегүләре үтәү. | Берлек санда гына була торган исемнәр юкмы? Соравына җавап бирәләр |
| **III. Яңа белем һәм күнекмәләр формалаштыру.** | | | |
| 1. Яңа теманы аңлату.<br>*Максат:*<br>Уку күнекмәләрен үстерү өстендә эшләүне формалаштыру. | **Дәрескә максат кую** | | Дәреслек белән эш. 111 нче күнегү Бирелгән сүзләрне игътибар белән кара һәм ике баганага ае-рырга.(Парларда эш)<br><br>**Соңыннан нинди баганаларга аеру турында сөйләшәләр**<br>**Нәтиҗә:** исемнәр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | берлек һәм күплек саннарда килә. Күплек санда **калын** сүзгә **-лар,нечкә** сүзгә **-ләр** кушымчасы ялгана, **м, н, ң тартык аваз хәрефләренә** беткән сүзләргә **-нар**, **- нәр** кушымчалары ялгана. |
| 2. Белемнәрне беренчел ныгыту. | Рәсемнәр күрсәтә.<br><br>Борын юкә<br>Каен агач<br>Имән китап<br>Тиен дару<br>Болын кыр | Төрле предмет исемнәрен (рәсемнәр буенча) берлек һәм күплек санда әйтәләр, тактада язалар. | **“Исемнәрне берлек һәм күплек санда әйт!”**<br>Төрле предмет исемнәрен (рәсемнәр буенча) күплек санда әйттерү күнегүләре |
| 3. Ял минуты. | Физминутка | | |
| **IY. Алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту.** | | | |
| Берлек һәм күплек сандагы исемнәрне ныгытуга күнегүләр үтәү<br>Максат:<br>Укучылар-ның игъти-барлыгын тикшерү. | Ничек уйлыйсыз нинди сүзләргә -лар, -ләр; Ниндиләренә –нар, -нәр кушымчасы ялгана икән? | Сүз..., кош..., мәктәп..., кыз..., өстәл..., идән..., таң..., имән..., болын..., миң... .<br><br>Укучылар бирелгән сүзләрдән җөмләләр уйлыйлар, бер-берсенә укыйлар.<br><br>Җөмләләрне тактага яздыру, тикшерү. (Берничә укучының эше тикшерелә. Нинди сүзләр кулланганлыгын әйттерү.) | Бирелгән сүзләрдәге күпнокталар урынына тиешле күплек сан кушымчаларын куеп язарга.<br><br>Бирелгән сүзләрдән 3 җөмлә төзергә кирәк булачак. Җөмлә төзегәндә бирелгән сүзләрне баганалап, яки юллап, яки диоганаль буенча бирелгән сүзләрне кулланырга тиеш булачак.<br>бакча кабак түтәл<br>кәбестә суган кишер<br>шалкан бәрәңге кыяр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Дәреслек белән эш. | Дәреслектәге күнегү буенча фронталь эш оештыру.114 нче күнегү | Икенче җөмләнең күплек сандагы исемнәрен берлек санга куеп язу. Предмет исемнәрен күплек санда дөрес әйтү һәм дөрес ку-шымчалар ялгап язу күнекмәсен ныгыту. | 3. **Дәреслек белән эш. 114 нче күнегүне үтәү (63 нче бит).** Калын әйтелешле сүзләргә 1 вариант, нечкә әйтелешле сүзләргә 2 вариант күплек сан кушым-часы ялгый. |
| Белемнәрне тикшерү. <u>*Максат*</u>: Тест эшләү | Тест эшләтү. | Тест эшлиләр<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Тест җаваплары белән тикшерелә, билгеләр куела | **4.Тест**<br>*1. Исемгә туры килгән билгеләмәне күрсәт.*<br>*А. Предметның билгесен белдерә*<br>*Б. Предметны белдерә*<br>*В. Эшне, хәрәкәтне белдерә*<br>*2. Исем нинди сорауларга җавап бирә?*<br>*А. Нишли? Нишләде? Нишләгән?*<br>*Б. Нинди? Кайсы?*<br>*В. Кем? Нәрсә?*<br>*3. Очучы сүзенә сорау куй.*<br>*А. Нәрсә?*<br>*Б. Кем?*<br>*4. Төлке сүзенә сорау куй.*<br>*А. Кем?*<br>*Б. Нәрсә?*<br>*5. Сыерчык сүзенә кайсы күплек кушымчасын ялгарга?*<br>*А.-нар*<br>*Б.-нәр*<br>*В.-лар*<br>*Г.-ләр*<br>*6. Күл сүзенә кайсы күплек кушымчасын* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | *ялгарга?*<br>*А.-нар*<br>*Б.-нәр*<br>*В.-лар*<br>*Г.-ләр*<br>*7. Болын сүзенә кайсы күплек кушымчасын ялгарга?*<br>*А.-нар*<br>*Б.-нәр*<br>*В.-лар*<br>*Г.-ләр*<br>*8. Тиен сүзенә кайсы күплек кушымчасын ялгарга?*<br>*А.-нар*<br>*Б.-нәр*<br>*В.-лар*<br>*Г.-ләр* |
| **V. Рефлек сия.** | *Максат:* Дәрес материалын нәтиҗәле өйрәнүгә анализ ясау.<br><br>*Регулятив универсаль уку гамәлләрен формалаштыру.* | Укучылар җавабы. | Бүген дәрестә нәрсәләр өйрәндек? Нинди яңа белем алдыгыз? Тормышта кирәк булырмы икән бу күплек кушымчалары? Нәрсә өчен кирәк булыр? Билгеләр куела. |
| **VI. Өй эше.** | Өйгә эш.<br>*Максат*: Өй эшен дөрес эшләү өчен информация бирү | Өй эшен көндә-леккә язу. | 1. 112нче күнегү, 63 бит күплек кушымчасы куеп яз. 1 вариант өчен<br>2. 113нче күнегү 2 вариант өчен.<br>3. Күплек сандагы исемнәр кертеп,<br>4. ” Минем әнием” темасына кечкенә хикәя язарга.<br>Барыгызга да рәхмәт. Дәрес тәмам. |

## «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ 10 НЧЫ ГИМНАЗИЯСЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ



**14 нче декабрь, 2016 нчы ел**

Россия Федерациясе регионнары гомуми белем бирү учреждениеләренең гуманитар фәннәр укытучылары өчен регионара семинар
**«Дәресләрдә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә укучыларның коммуникатив компетенициясен үстерүдә инновацион методикалар һәм технологияләр»**

**Межрегиональный семинар учителей гуманитарного цикла общеобразовательных учреждений регионов Российской Федерации «Инновационные методики и технологии развития коммуникативных компетенций обучающихся на уроках и во внеурочной деятельности»**





## V сыйныфта укучы рус теле балаларга – татар теле

***Хәйруллина Гөлнара Абдул кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 10 нчы гимназиясенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәрес темасы:** Бәйләнешле сөйләм үстерү. Ю.И.Ермолаевның "Ике пирожный" хикәясе буенча.
**Дәреслек:** 5 нче класс татар теле / Р.З.Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова. - Казан: "Татармультфильм" нәшрияты, 2014.
**Максатлар**:
1. Ю. Ермолаевның “Ике пирожный” әсәрендәге лексик-грамматик күнекмәләрне ныгыту, балаларны татарча үз фикерләрен әйтә белергә, геройларга характеристика бирергә өйрәтү.
2. Укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну тудыру; тормышта рус телле балаларның татарча сөйләшә белүенә ирешү; укучыларның логик фикерләү сәләтен үстерү өчен шартлар тудыру, кызыксынучанлык, коллективта эшли белергә өйрәтү. Балаларга мөстәкыйль рәвештә максат куеп, нәтиҗәгә килергә ярдәм итү.
3. Укучыларны яшәргә өйрәтү, әти-әнигә булышырга, аларны хөрмәт итергә; укучылар арасында үзара ярдәмчел мөнәсәбәт тәрбияләү.
**Бурыч:** Укучыларның иҗади фикерләү сәләтен, аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыруга йогынты ясау.
**УУГ**
**Регулятив:**
- укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү;
- кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;

**Танып белү:**
- тиешле мәгълүматны табу, билгеләү;
- үз фикерләрен дәлилли белү;
- нәтиҗә ясау;

**Коммуникатив:**
- хезмәттәшлектә башкаларның фикерләрен исәптә тоту һәм карашыңны яклый белү;
- бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү;

**Шәхси:**
- үзара аралашу культурасы тәрбияләү;
- үз фикерләрен дәлилли белергә өйрәтү.

**Җиһазлау**: ноутбук, экран, проектор, карточкалар, презентация, колонкалар.
**Материаллар:**
5 нчесыйныфөчен татар теледәреслеге(Р.З.Хайдарова)
**Методлар:** белемнәрне системалаштыру, анализ, проблемалы укыту.

**Алымнар:** карточка белән эшләү, дәрес картасы белән эшләү, дәреслек белән эшләү, укытучы сөйләме, сорау-җавап әңгәмәсе, рефлексия, критик фикер йөртү, презентация белән эш.
**Форма:** группаларда эш, парларда эш.
**Дәрес тибы:** белемнәрне системалаштыру

**Дәрес барышы.**
**I. Оештыру өлеше**
**Исәнләшү** *(слайд)*
- Исәнмесез, укучылар.
- Кәефләрегез ничек?
- Утырыгыз.
- Дежур укучы белән әңгәмә

**II. Актуальләштерү**
- Балалар, һәр биремнән соң мин сезгә шушы эмблемаларны өләшермен, дәрес ахырында без аларны санарбыз һәм үзебезгә билге куярбыз. Менә бу тактада ничә эмблема өчен нинди билге куелачагын күрә аласыз.
- Балалар, мин сезгә хәзер бер җыр куям, ә сез әйтегез әле, нәрсә турында бу җыр? (әниләр турында, әниләргә булышу турында җыр яңгырый)
- Әйе, дөрес, бу җыр әниләр турында, әниләргә булышу турында.
- Балалар, ә сез  әниләргә булышасызмы?
Диалоглар төзибез :
- Син әнигә булышасыңмы?
- Әйе, мин әнигә булышам.
- Син әнигә ничек булышасың?
- Мин савыт-саба юам,..... *(слайд)*

**III. Яңа белем һәм күнекмәләр бирү.**
**Проблема кую.Без бүген нинди темага сөйләшербез икән?**
**Әйе , дөрес , әниләргә булышу турында сөйләшәбез**
61 нче битне ачыгыз.Без үткән дәресләрдә. Ю. Ермолаевның нинди әсәрен укыдык?
**Тема. “Ике пирожный”** *(слайд)*
**1.** - Әйдәгез, шул әсәрне искә төшереп без сорауларга җавап бирәбез.
Сорауларга җавап бирү (63 нче бит, 10нчы күнегү) *(слайд)*
*(Дөрес җаваплар өчен эмблемалар өләшү)*
**2.** - Балалар , әйдәгез, хикәягә план төзибез. Экранга карагыз әле. Бу план дөресме?
- Планны дөрес итеп төзибез *(Дөрес җаваплар өчен эмблемалар өләшү)*
**3.** Күнегүдәге сүзләрне кулланып, күп нокталар урынына сүзләр куеп укырга кирәк.
Һәр төркемнән беренче номерлы укучылар, басып, җөмләләрне чираттан укыйлар.
- ... бүлмәгә керде.
- Олы кызы Наташа ... укый.

- Оля рәсем ... .
- Оля ... юды.
- Африкада ... итәм.
- Мин ике пирожный ... .
- Оля барлыксавыт-сабаны ... .
- Бергенә бит укыйм да ... .
- Берсен үзем өчен, икенчесе ... .
- Африка бик ерак бит, шуңа күрә кремлы пирожный ... .

**Сүзләр:** юды, әниләре, китап, синең өчен, ясый, савыт–саба, булышам, сәяхәт, бозыла, ашадым.

**Тикшерү. Экранда җаваплар.**

- *Әниләре бүлмәгә керде.*
- *Олы кызы Наташа китап укый.*
- *Оля рәсем ясый .*
- *Оля савыт-саба юды.*
- *Африкада сәяхәт итәм.*
- *Мин ике пирожный ашадым .*
- *Оля барлык савыт-сабаны ... .*
- *Бер генә бит укыйм да булышам .*
- *Берсен үзем өчен, икенчесе синең өчен.*
- *Африка бик ерак бит, шуңа күрә кремлы пирожный бозыла.*

*(Дөрес җаваплар өчен эмблемалар өләшү)*

**4.** - Ә хәзер, балалар, экранга карыйк әле. Ике кыз рәсеме бирелгән (берсе китап укый, икенчесе пальмалар астында ята)

1 нче рәсемдә кем ясалган? (Оля ясалган рәсем)

2 нче рәсемдә кем ясалган? (Наташа ясалган)

Кызларга характеристика бирегез әле. Тактага карагыз. Бу сүзләр арасынннан кирәкле сүзне сайлап, тактага ябыштырасыз.

(Һәр укучы берәр сүз сайлый.)

Эшчән, ялкау, ярдәмчел, тырыш, әнигә булыша, рәсем ясый, китап укый, савыт-саба юа, Африкада сәяфәт итә, уңган, акыллы, тәрбияле, әнигә булышмый.

**5. Язма эш**

- Балалар, сезнең алдыгызда карточкалар ята. Анда җөмләләр бирелгән. Әйдәгез, дөрес җөмләләр төзибез. Кем тизрәк төзеп бетерер икән?

1) *бүлмәгә, керде, дә, Әниләре, кызларны, үзенә, ярдәм итәргә, чакырды.*

Әниләре бүлмәгә керде дә кызларны үзенә ярдәм итәргә чакырды.

*2) китап, Олы кызы, иде, укый.*

Олы кызы китап укый иде.

*3) Оля, кече, кызы, ясый иде, рәсем.*

Кече кызы Оля рәсем ясый иде.

*(Дөрес җаваплар өчен эмблемалар өләшү)*

**Физкультминут (***видеоязма буенча күнегүләр ясау)*

**IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту**

**1. -**Без сезнең белән 9нчы сыйныфта бердәм дәүләт тестларын бирәчәкбез. Шуңа әзерлек буларак берничә бирем эшләп карыйк әле. Экранга карагыз. Ике раслауның кайсысы дөрес?
1. Наташа китап укый.
Оля китап укый.
2 .Әниләре кызлардан ярдәм сорады.
Әниләре малайлардан ярдәм сорады.
3. Наташа ике пирожный ашады.
Оля ике пирожный ашады.
4. Наташа савыт-саба юа.
Оля савыт-саба юа.
*(Дөрес җаваплар өчен эмблемалар өләшү)*
**2. Бирем.** Карточкаларда эшләү.
**Определите, какие утверждения соответствуют содержанию текста**
( А - дөрес), какие не соответствуют (Б – дөрес түгел)
1. Әниләре ярдәм итәргә чакырды.
А) Текстка туры килә. Б) Текстка туры килми.
2. Оля китап укый.
А) Текстка туры килә. Б) Текстка туры килми.
3. Наташа пирожный ашады.
А) Текстка туры килә. Б) Текстка туры килми.
4. Оля әнисенә булышырга уйлады.
А) Текстка туры килә. Б) Текстка туры килми.
5. Наташа барлык савыт – сабаны юды.
А) Текстка туры килә. Б) Текстка туры килми.
6. Әниләре ике пирожный ашады
А) Текстка туры килә. Б) Текстка туры килми.
7. Әниләре малайлардан ярдәм сорады.
А) Текстка туры килә. Б) Текстка туры килми.
8. Оля әнисенә булышмады.
А) Текстка туры килә. Б) Текстка туры килми.
9. Наташа савыт-саба юды.
А) Текстка туры килә. Б) Текстка туры килми.
10. Оля кызыклы китап укый.
А) Текстка туры килә. Б)Текстка туры килми.
11. Наташа бер пирожный ашады.
А) Текстка туры килә. Б) Текстка туры килми.
12. “Африка бик ерак бит” – диде әни.
А) Текстка туры килә. Б)Текстка туры килми.
*(Дөрес җаваплар өчен эмблемалар өләшү)*
**3. Ситуатив күнегүләр**
*Как ты скажешь о том, что:*
- мама вошла в комнату;
- Оля рисует;

- Наташа читает книгу;
- Я ем пирожное;
- Я помогаю маме;
- Я путешествую в Африке.

*(Дөрес җаваплар өчен эмблемалар өләшү)*

**4. Бирем:**

1 нче рәт: *составьте диалог между мамой и Олей, когда мама попросила о помощи.*

2 нче рәт: *составьте диалог между мамой и Наташей, когда мама просила о помощи.*

3 нче рәт: *составьте диалог между Олей и Наташей, когда Наташа «вернулась» из Африки*

*(Дөрес җаваплар өчен эмблемалар өләшү)*

**V. Йомгаклау, нәтиҗә**

- Балалар, без бүген нәрсә эшләдек?
- Дәрес башында үзебезгә нинди максат һәм бурычлар куйган идек?
- Нинди нәтиҗә ясыйбыз?
- Кем әнигә булышты?
- Әти-әниләргә булышырга кирәк. Ярдәм итегез!
- Кем эшләми, шул ашамый.
- Эш беткәч, уйнарга ярый.
- Максатка ирештекме? Нәрсә белдек?

**VI. Өй эше**

1.Наташага киңәшләрегезне языгыз.
2.Эш турында мәкальләр табып килергә.
3.Өйдә әти-әниләрегезгә ничек булышасыз? 6-7 җөмлә язып килегез.

**VII. Билгеләр кую.**

- Ә хәзер, укучылар, эмблемаларыгызны санагыз әле. Кемнең ничә эмблема җыелган? Бугенге дәрес өчен нинди билгеләр аласыз? (балалар дәрестәге эшчәнлекләренә үзләре бәя бирәләр).
- Укучылар, бүгенге дәрескә һәм миңа да бәя куегыз әле. Биредә өч төрле смайликлар бар. Дәрес ошаса, яшелне, бераз аңлашылмаса, сарыны, ошамаса, кызыл смайликны тактага ябыштырып чыгыгыз.
- Дәрес өчен рәхмәт! Сау булыгыз, уңышлар сезгә!

**Презентация воскресной марийской школы**
**Расширенное заседание кружка**
**«История и культура Марийского края»**

**Орехова Лидия Петровна,**
***учитель начальных классов I квалификационной категории гимназии №10 города Зеленодольска Республики Татарстан***

**Тема: Дружбой народов мы сильны.**

Цели:

- познакомить учащихся с республикой Марий Эл, его основными достопримечательностями, культурой;
- установить связь трёх республик : Марий Эл, Татарстан, Чувашия;
- воспитывать в детях чувство толерантности, взаимно уважение кдруг другу.

Оборудование:

- иллюстративный материал о Марий Эл;
- детские журналы, газеты на марийском языке;
- марийская национальная одежда;
- марийские национальные полотенца;
- мультимедийное сопровождение.

*1 слайд*

- В нашем городе есть красивый фонтан «Дружба народов».
- Почему он находится в нашем городе? (В нашем городе проживают люди разных национальностей, наш город расположен на стыке трёх республик:Татарстан, Марий Эл, Чувашия)
- Здесь собрались дети разных национальностей: русские, мари, татары, чуваши.
- Представителей народа мари можно встретить по всему земному шару. Моя сестра живёт, работает учителем в Израиле, её сын живёт в США, мари есть и на Дальнем Востоке, и в Сибири, на Урале, у нас в республике Татарстан. В 2008 году я представляла город Зеленодольск на всемирном Съезде народа мари в городе Йошкар-Ола.
- Сейчас ребята марийского кружка расскажут вам о родной республике.

Дети-мари:

- Салам лийжепагалыме, йолташ-влак!
- Пагалыме, уна-влак, метендамчыладам мари кружокыниксзанятийышкыжепагаленужына
- Тачеметендам Мари Эл нергенкутырымашкеужына

2. Музыка «Кусле» - это звучит национальный музыкальный инструмент – гусли ( кусле)

Стих «Шочмо вер»:

Шочмо вер -тор олык, Шочмо вер эн шерге Шочмо вер - сайкумыл
Шочмо вер-садер, Шочмо вер-ава Шочмо вер-куан
Ужаран ал солык, тудындеччевер жепорсынденкуалме
Кайыканкуэр Мо уло, ала? Чонжокалыклан
3. Рассказ детей о республике Марий Эл:
*2 слайд*
- Тиде Марий Элынкартше.
- Мари Элыште 14 латнып район
- Перевод: в республике Марий Эл 14 районов
- Мари Элынпрезидентше Леонид Игоревич Маркелов
- Мари Элыште ныл ола: ( Перевод: 4 города) Йошкар-Ола, Козьмодемьянск, Звенигово, Волжск
3 слайд - Тиде Марий Элынгербше, флагше
*4 - 10 слайды*
- Мари Элын рудо олаже – Йошкар-Ола. Йошкар–Оланшочмоийжым 1584 (тужемвичшудокандашлунылымше) ийшолалтеш.
Й-Олаштетурлонациональностянкалыкилат.
- Перевод: Столица –г. Йошкар-Ола, основан в 1954г, его прежние названия Царевококшайск, Краснококшайск. Йошкар-красный, ола – город. Здесь живут люди разных национальностей
- Тидеола пеш мотор, кумдауремлашамыч мотор деч мотор пеледышденелеведалтыныт. Тачысе кече мартеат Й-Олаште кугу стройка-влаккаят.
- Перевод: Йошкар- Ола – красивый город, много зелени, цветов, красивых зданий. Стоит город на реке Кокшага , кок – это 2, небольшая река в 2 шага. Постарайтесь вместе с родителями посетить этот город, он расположен недалеко от нас.
Стих (учитель) : Много есть на Земле городов
Но навеки ты сердцу мила,
Разодетая в зелень садов
Дорогая Йошкар - Ола
*11-12 слайды*
- Эн тоштоолалан Мари Элыште Козьмодемьянск олашотлалтеш.
- Перевод: старинный город Козьмодемьянск был основан при царе Иване Грозном. Он был вторым городом после Архангельска по лесоторговле, марийская земля богата лесами. Здесь находится музей под открытым небом, творения деревянного зодчества сохранились до сих пор.
13-14 слайды - Звенигово – эн самырыкола. Тушто судоремонтный завод уло.
- Перевод: - Звенигово – молодой город.
15-17 слайды - Волжск – ола мари кагаз комбинат денечаплана. Тудыныштымекагаз же чылатунямучко кая.
- Перевод: Волжск славится заводами ,фабриками. Марийский бумажный комбинат посылает бумагу по всему миру.
18-23 слайды - Марий Элын эн кугу поянлыкше-чодра.

- Перевод: главное богатство марийкой земли – лес.
- Санденечодрамаралымашик эн тун задачыланшотлалтеш.
- Тидым «Марий Чодра» национальный паркышмимекешижашлиеш.
- Перевод : Национальный парк «Марий чодра» ставит своей задачей-сохранение леса
- ТидепаркыштеВаштар-курык, Элнет, Кичиер, Яльчик ер, Морской глаз верланеныт.
- Перевод: Здесь расположены памятники природы – Кленовая гора, ( тут находится Дуб Пугачёва), река Илеть, красивые озёра Кичиер, Яльчик, Морской глаз

*24 - 28 слайды*

- В национальном парке оберегаются такие животные, как медведь, рысь, киче – лось, росомаха, здесь растёт красивый редкий цветок- северная орхидея – венерин башмачок.

4. Песня «Тугемо?». В ней говорится о том, что надо дружить, весело дружно жить.Исполняют дети-мари.
5. Игра «Переводчики»

Сегодня вы услышали много марийских слов. Теперь перед вами стоит задача перевести с татарского языка на марийский. Страшно? Не бойтесь, слушайте секрет. Народы мари, татары много веков живут рядом, общаются. Их культура, языки перекликаются, поэтому много созвучных слов. Попробуем:

***Ава - әнитурло - төрле***
***Ачи - әтипаренге - бәрәңге***
***Салам лийже - сәламкияр - кыяр***
***Йолташ - юлдашкешыр - кишер***
***Устел - өстелкагаз - кәгазь***

- К слову, наша ученица, Зайнетдинова Аня, она мари, победитель школьного тура олимпиады по татарскому языку, неплохо показала себя и в городской олимпиаде.
- 10 декабря в Марий Эл отмечается праздник “Тиште карече” - День марийской письменности 10 декабря 1775года вышла в свет первая марийская грамматика

6. Игра –песня “Шыргыжалынколтена”.

*Слайд 23*

Эту песню написал мой земляк, односельчанин Вячеслав Осипов. В детстве мы вместе играли, ходили за ягодами, купались, жили весело , дружно. В песне говорится о том, что мы любим природу, бережём её, помогаем родителям, встанем в хоровод, за руки возьмёмся, друг другу улыбнёмся, весело станцуем и споём.

7. Обобщение. –Мы много говорили о республике Марий Эл. Повторить нам поможет кроссворд

К Я - На какой реке стоит г. Йошкар- Ола? (Кокшага)
о ч л - по-марийски “ лес” - ..... (чодра)
к о ь В - любимое место отдыха, зеленодольцев тоже .... ( Яльчик)

ш д ч о - столица республики Марий Эл (Йошкар–Ола)
М а р и Й Э л - по-марийски река Илеть -...... (Элнет)
г а к о л ж - город в Марий Эл – наш сосед (Волжск)
Йа ш к ар-Ола

8. Подведём итоги Народ мари - красивый, трудолюбивый, дружелюбный народ. Надо жить дружно, весело, знать и уважать культуру других народов. Марийская пословица говорит: “Поснавоштырымтодылашкуштылго, пидмевыньыкымтодылашйосо” – По одному прутику можно сломать весь веник, целый связанный веник – не сломить. Только в дружбе народов сила нашей страны России.

Марийская народная песня "Тугемо?"
1. Айста, удыр-эрге-вылак, муралтенкушталтена!
Айста, удыр-эрге-вылак, муралтенкушталтена!
Муралтена, кушталтена, семжедентавалтена.
Муралтена, кушталтена, семжедентавалтена.
Тугемо? Садыгешол! Семжедентавалтена.
2. Тынгеткаяшпуш кулеш, тунгеткаяшпуш кулеш.
Тынгеткаяшпуш кулеш, тунгеткаяшпуш кулеш.
Ырвезеумырэртарашчонгаейолташ кулеш.
Ырвезеумырэртарашчонгаейолташ кулеш.
Тугемо? Садыгешол! Чонгаейолташ кулеш.
Эш, ну, Калтаса,
Семже мом гынкаласа,
Мураш-кушташвелеогыл,
Пырляилашкаласа.
3. Айста, удыр-эрге-вылак, муралтенкушталтена!
Айста, удыр-эрге-вылак, муралтенкушталтена!
Муралтена, кушталтена, семжедентавалтена.
Муралтена, кушталтена, семжедентавалтена.
Тугемо? Садыгешол! Семжедентавалтена.






***Гости семинара – учителя из Марий Эл***

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
1 НЧЕ ЛИЦЕЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ
БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

---

**2 нче февраль, 2017 нче ел**

Зеленодолмуниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең тат
теле һәм әдәбияты укытучылары өчен республика семинары
**«IX сыйныф укучыларын бердәм республика тестларына һәм татар телennән төп дәүләт имтиханнарына әзерләү үзенчәлекләре»**

Республиканский обучающий семинар
для учителей татарского языка и литературы общеобразовательных организаций Зеленодольского муниципального района
**«Особенности подготовки обучающихся IX классов к единому республиканскому тестированию и ОГЭ по татарскому языку в 2017 году»**









## IX сыйныфта укучы татар балаларына – татар теле

***Сабирова Зөлфия Сәлимҗан кызы,***
***«Татарстан Республикасы Зеленодол муиципаль районының 1 нче лицее» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Тема**: Табигатьнең кадерле бүләге
**Максат:** 1) табигатьнең кадерле бүләге темасына сочинение-фикерләмә язу;
2) табигатькә, сулыкларга сакчыл караш тәрбияләү;
3) укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү
**Җиһазлау:** сочинение язуга әзерлек папкасы, компьютер, интерактив такта, презентация.
**Материал:** Җыйнакландырылган изложениене һәм сочинение-фикерләмәне ничек язарга? / Э.Н.Денмөхәммәтова һ.б. – Казан: Гыйлем, 2014.

**Дәрес барышы.**

1. **Белем алуга омтылыш тәрбияләү.**

Балаларга хәерле көн теләү, укучыларның алдагы эшләренә бәя бирү.

**Дәреснең темасын һәм максатын билгеләү**

2016 нчы ел Татарстан президенты тарафыннан Су зоналарын саклау елы дип игълан ителде. Чыннан да, экология проблемасы хәзерге көндә актуалъ булып тора. Бүгенге темабыз да табигатьне саклау белән бәйләнгән.

**Табигатьнең кадерле бүләге** дигән темага сочинение- фикерләмә язу

*Слайд 1*

2. **Актуальләштерү.**

**Сочинение нинди өлешләрдән торырга тиеш?**

- кереш
- төп өлеш
- йомгак- нәтиҗә

*Слайд 2*

Сочинине язу алгоритмын да искә төшерик.
Кереш- төп фикерне билгелибез.
Төп өлеш- текстның идеясен билгеләргә, ике дәлил табарга, һәр дәлилне берәр мисал белән расларга.
Йомгакта - автор әйтергә теләгән фикергә нәтиҗә ясыйбыз.

*Слайд 3*

3. **Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру.**

**«Табигатьнең кадерле бүләге»**

(текстны уку, эчтән уку)
- Текст белән эш.
- Текст нәрсә турында?
- Автор нәрсә әйтергә тели?
- Суларны, чишмәләрне, табигатьне саклау турында язылган.

**Кереш - тезис өлешен билгеләдек**.

- Сулыкларны,чишмә, елга-күлләрне саклау турында язылган.
*Слайд 4*
**- Чишмәләр турында нинди фикер әйтелгән?**
**- Халык ни өчен чишмәләрне кадерләп саклый?**
- кунакларны сыйлый
- матур исемнәр куша
- чөнки чишмә сулары кешеләрне дәвалый
*1 нче дәлилне табабыз.*
**Чишмә сулары - иң кадерле, файдалы, шифалы, тәмле сулар дип әйтә алабыз. Табигатьнең кадерле бүләге- чишмә сулары.**
*Слайд 5*
**Кеше сусыз тора аламы?**
**- Автор нәрсә турында уйлана? Нәрсә өчен борчыла? Нинди фикер әйтә?**
- эчә торган сулар аз кала
- табигатькә зыян килә
- кешелек юкка чыгарга мөмкин.
*2 нче дәлил.*
**Җир йөзендә эчәргә яраклы сулар кими бара, бу - зур проблема. Автор суның кадерен белү кирәклеге турында уйлана.**
*Слайд 6*
2 дәлилне таптык, ләкин сезгә тексттагы җөмләләр белән расларга кирәк.
**Йомгак. Димәк, кешелек дөньясы чишмә - күлләрне, елгаларны, сулыкларны саклау турында уйланырга тиеш. Автор безгә шуны искәртә.**
**Төркемнәрдә эш**
***Дәфтәрләрдә сочинение язу.***
- кереш өлешен укыту ( 1 төркем)
- төп өлешне укыту ( 2 нче төркем)
- йомгак өлешен укыту( 3 нче төркем)
- балалардан тулы сочинениене укыту.
**4. Сочинение**.
**Табигатьне саклау – һәркемнең бурычы, без моны истән чыгармаска тиеш.**

Табигатьнең кадерле бүләге.

Минемчә, бирелгән бу өлештә текстның төп мәгънәсе чагылган. Ул табигатьнең кешелек өчен иң кадерле бүләге булган суны пычратмаска, кадерләргә кирәк икәнен аңлата.
Чыннан да, су - яшәү өчен иң кирәкле матдә. Кеше сусыз бер көн дә тора алмый. Нәтиҗәләремне раслау өчен, укылган тексттагы 15, 16 нчы җөмләләрне китерәм. Кызганычка каршы, без бу тылсымлы суның кадерен белмибез. Чишмәләрне сакламыйбыз, елгаларны пычратабыз.
Тексттагы «Эчә торган төче су планетадагы барлык суларның нибары ике генә процентын тәшкил итә» дигән җөмлә минем алда әйтелгән фикеремә дәлил булып тора. Бу фактлар сагаерга мәҗбүр итә. Чиста суларның шулай кимүе

кеше организмына, яшәешенә зур зыян сала дигән сүз. Пычрату процессы һаман бу тизлектә барса, тирә-юнебездәге тереклек тә юкка чыгарга мөмкин.
Димәк, текст авторы Г.Бәширов табигать биргән бу бүләктән дөрес файдаланырга, аны кадерләргә чакыра. Шулай булганда гына изге чишмәләребезне , чиста сулы елга - күлләребезне саклап кала алырбыз.

**5. Йомгаклау**

Укучылар эшенә нәтиҗә ясау, билгеләр кую.

## IX сыйныфта укучы татар балаларына – татар теле

***Гәйнетдинова Рима Абдулловна,***
***«Татарстан Республикасы Зеленодол муиципаль районының 1 нче лицее» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Тема**. Туган йортта әнкәң көтә сине.
**Максатлар**. Текстны анализлау күнекмәләрен ныгыту, тезиста чагылган фикернең дөреслеген дәлилләү, тексттан 2 мисал таба белү күнекмәләрен камилләштерү, сочинениенең кереш өлешне язырга өйрәтү, укучыларның сөйләм телен үстерү, текстка нигезләнеп эшләргә өйрәтү. Укучыларда аналарның эшләгән яхшылыкларын аңлап, алар каршында булган бурычыбызны үтәргә теләү хисе уяту.
**Дәрес төре**. Яңа материалны аңлату дәресе.
**Җиһазлау.** Интерактив такта, презентация, шаблоннар, ак кәгазь битләре.
**Материал**. Дания Гайнетдинова «Туган йортта әнкәң көтә сине» тексты.
**Дәрес барышы**.

**1. Оештыру өлеше.**

Сыйныфта уңай психологик халәт тудыру.

**2. Алган белемнәрне актуальләштерү.**

Сочинение язу тәртибе турында фикер алышу.

**3**. **Яңа материалны өйрәнү.**

- Бүген без сезнең белән әниләр турында сөйләшәчәкбез. Мин сезнең белән бергәләп, Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасыннан алынган канатлы сүзләрне искә төшерәсем килә.

*Слайд 1*

Ана - Бөек исем,
Нәрсә җитә ана булуга;
Хатыннарның бөтен матурлыгы,
Бөтен күрке ана булуда...

-Укучылар, балалар һәм аналар арасындагы мөнәсәбәт бүгенге көндә актуаль проблема булып тора. Димәк, без сезнең белән бүгенге дәрестә бик җитди мәсьәлә турында сөйләшәчәкбез. Ә хәзер, әйдәгез, экранга күз салыйк. Экрандагы ана бәхетлеме? Ни өчен бәхетле?
- *Әйе, бәхетле, чөнки аның баласы бар.*

- Ә сезнең әниегез бәхетлеме? Ни өчен?
- *Әйе бәхетле, чөнки без бар.*
- Әниләр тагын нинди булалар?
- *Рәхимле, игелекле, ярдәмчел, гадел.*
- Ә нигә алар игелекле?
- ..........
- Әйе, балалар, мин сезнең белән килешәм. Сез монда матур итеп, исән-сау килеп утыргансыз икән, бу бит сезнең әниләрегезнең тырышлыгы нәтиҗәсе. Әниләрегез сезгә бар күңел җылысын биреп тәрбияли. Төн йокыларын йокламыйча, үзләрендә булган бар изгелелекләрне сезгә бирергә тырыша.
- Ә хәзер, әйдәгез, «Туган йортта әнкәң көтә сине» текстына күз салыйк, игътибар белән укып чыгабыз. Текстта кемнәр турында сүз бара икән? Шул сорауга да җавап бирергә әзерләнәбез.
- *Текстта ана һәм аның уллары турында сүз бара.*
- Дөрес, балалар, менә инде без сезнең белән бөтенне өлешләргә бүлдек. Ике дәлилне дә таптык. Шулаймы?
- *Әйе.*
- Беренче дәлилебез кем турында булыр?
- *Ана турында.*
- Нинди ана?
- *Ялгыз ана.*
- Ана нишли?
- *Балаларын көтә.*
*Слайд 2*
- Ничә бала үстергән?
- *Биш бала үстергән.*
- Ә ничек көтә?
- *Йокламыйча, бик күп төннәрен уздырып, таңнар аттырып, берәрсе кайтмасмы дип көтә.*
- Әйе, биш бала үстереп, берсе дә аналары янына кайтмый. Ялгыз ананың нинди хисләр кичергәнен, аның нинди уйлар уйлаганын тагын да аңлаешлырак булсын өчен, минем сезгә менә шундый шигырь юлларын укып китәсем килә.

Елатмагыз әниләрегезне,
Төнге тәрәзәләргә каратып.
Догаларын, изге теләкләрен
Биргән алар сезне яратып.
Елатмагыз әниләрегезне,
Күз төбәтеп юллар чатына:
Онытмагыз – сезне төп нигездә
Әнкәгезнең йорты чакыра!

- Ә хәзер,әйдәгез, текстыбызга килик.
- Текстның төп мәгънәсе кайсы җөмләләрдә чагыла?
- 2, 5, 18 нче җөмләләр. Сочинениебезнең кереш өлешен һәм беренче дәлилебез турында язып карыйк әле.

( Кереш һәм төп өлешнең беренче дәлилен укучылардан укытыла)
- Икенче дәлилебез кемнәр турында?
- Аның  биш улы турында.
- Аның уллары әниләренә карата нинди?
- Рәхимсез, игелексез, мәрхәмәтсез.
- Ни өчен?
- Чөнки алар әниләрен, туган йортларын онытканнар, аны рәнҗеткәннәр.
- Бала вакытта, сабый чакларында әниләре аларга кирәк булганмы? Нинди җөмләләрдә күренә?
- 9, 10, 11нче җөмләләрдә. Кечкенә вакытта алар аның итәгенә ябышып йөргәннәр, әниләре эштән кайтып керүгә, алар аның муенына сарылганнар.
- Әйе, балалар, бала үскәндә , әнисез бер көн дә тора алмый.
- Ә үсеп җиткәч, әниләренә булган мәхәббәт каядыр китеп югала. Биш баланың берсе генә дә туган йортларына, әниләре янына кайтмый.
-Татар халкында шундый мәкаль бар:  «Ана күңеле баладa, бала күңеле далада». Мәкальнең беренче өлеше баласы утыз, алтмыш яшьтә булуына карамастан, бер көнен дә аларны  уйламыйча үткәрми торган ана турында булса, ә инде икенче өлеше дала кебек буш күңелле, таш йөрәкле балалар турында.  Димәк, мәкалебез бу текстыбызга тулысы белән туры килә.
*Слайд 4*
- Балалар, инде нинди нәтиҗә чыгарабыз, автор нәрсә әйтергә теләгән? Текстта автор позициясенинди? Ул әһәмиятлеме? Сез аның белән килешәсезме?
- Әйе, мин аның белән килешәм, автор әһәмиятле проблема күтәрә: әти-әниләргә үзләре исән чагында ук хөрмәт күрсәтергә, аларны кадерләргә, рәнҗетмәскә кирәклекне ассызыклый.
- Әниләрнең хәлләрен исән чагында белергә кирәк, аларны онытырга, рәнҗетергә ярамый. Аларга карата рәхимле, игелекле, кайгыртучан булыйк.
*Слайд 5*
- Аналарын оныткан, рәнҗеткән кеше бервакытта бәхетле була алмый. Әниләребез дә, үзебез дә бәхетле булыйк. Оҗмах - әти – әниләр аягы очында дигән мәкалебез бар безнең. Әниләребезне хөрмәт итик, аларны ташламыйк, рәнҗетмик.  Аларны да, үзебезне дә бәхетсез итмик.
*Слайд 6*
4. **Рефлекция**
- Нәрсә эшләргә тиеш идек?
- Сочинение- фикерләмәнең төп һәм йомгаклау өлешен язырга , автор фикеренә туры килгән мисалларны табарга, автор позициясен ачыкларга өйрәнергә тиеш идек
- Ничек эшләдек?
- автор фикеренә туры килгән мисалларны таптык, автор позициясен ачыкладык, сочинение - фикерләмәнең төп һәм йомгаклау өлешен язырга өйрәндек.
**Укучыларга билгеләр кую.**

## «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЙШӘ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ



**28 нче февраль, 2017 нче ел**

Зеленодол муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен республика семинары


**«Заманча татар теле һәм әдәбияты дәресләренең сыйфатын үстерү нигезе буларак яңа педагогик һәм мәгълүмати технологияләр»**

Республиканский обучающий семинар для учителей татарского языка и литературы общеобразовательных организаций Зеленодольского муниципального района

**«Новые педагогические и информационные технологии как основа повышения качества современного урока татарского языка и литературы»**







## VI сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

***Хәмәтҗанова Гөлинә Илдар кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Әйшә урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы:** Татарстанда яшәүче милләтләр (рәвеш темасын кабатлау).
**Максат:**
4. *Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):* Өйрәнелгән лексик-грамматик конструкцияләрне, рәвеш сүз төркемен кабатлау
5. *Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):* Укучыларның сөйләм байлыгын арттыру, фикерләү мәләтен үстерү. Үзара аралаша белү *мөмкинлекләрен* үстерү. Үз хезмәтеңне бәяли белергә өйрәтү.
6. *Тәрбияви максат (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):* Татарстанда яшәүче милләтләр турында мәгълүмат бирү, дус-тату мөнәсәбәттә яшәү серләрен ачу.

**Укытучының планлаштырылган нәтиҗәләре.**
**Шәхси УУГ:**
- укуга карата кызыксыну хисе;
- укучы ролен үзләштерү;
- нәтиҗәләргә анализ һәм үзконтроль;

**Метапредмет нәтиҗәләр.**
**Регулятив УУГ:**
- укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;
- укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү;

**Коммуникатив УУГ**
- иптәшләренең сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- парларда эшли белү;

**Танып – белү УУГ:**
- укытучы биргән сорауларга дөрес һәм аңлаешлы җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү.

**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, интерактив такта, презентация, сүзлекләр, биремле карточкалар.

**Дәрес барышы**
**IV. Мотивлаштыру.**
***3. Дәресне оештыру (исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу)***
-Исәнмесез, укучылар!
- .......
- Хәлләрегез ничек?
-........
- Рәхмәт, минем дә хәлләрем бик яхшы. Дәресебезне башлыйбыз.
***4. Өй эшен тикшерү***

- Укучылар, әйдәгез, өй эшен тикшереп үтик әле. “Минем якын дустым” темасына хикәя язып килергә тиеш идегез! (Берничә укучы хикәясен укый, дәрестә үткән рәвешләрне табып әйтә)
- Даша, ә синең дустың татарча сөйләшә беләме? (....)
- Ә сез бергә кайларга йөрисез? (.....)
- Сез кайчан таныштыгыз? (...)
-Рәхмәт, әйе, дусларың күп булу, ул бик яхшы. Дуслар белән аралашу, күңел ачу үзе ни тора. 100 сум акчаң булганчы 100 дустың булсын ди халык.

***5. Уку мәсьәләсен кую.***

-Укучылар, ә хәзер игътибар экранга. (Экранда хаттан өзек бирелә, укучылар шушы өзекне укый, рәвешләрне табып әйтәләр)

*Исәнме, дустым Алсу! Сиңа сәлам белән дустың Артем сагынып хат яза. Әти-әниеңә, дусларыңа, Сашага миннән сәлам әйт.*

*Алсу, мин синең хатыңны алдым, бик зур рәхмәт. Хатың бик кызыклы, мин аны рәхәтләнеп укыдым.*

*Алсу, син миннән “Синең башка шәһәрдә дустың бармы?” – дип сорагансың. Әйе, минем Мәскәү шәһәрендә дустым Лилия яши. Ул музыка, бию белән яратып шөгыльләнә. Аның иң зур теләге, үскәч, биюче булу. Алсу, синең хәлләрең ничек? Авырмыйсыңмы? Әти-әниең исән-саумы? Нинди яңалыкларың бар? Ничек укыйсың? Шулар турында хат яз, түземсезлек белән көтәм.*

*Сәлам белән, дустың Артем.*
*28 нче февраль, 2017 нче ел.*

- Рәхмәт, укучылар, өй эшен җиренә җиткереп эшләгәнсез! Калган укучыларның эшләрен, дәфтәрләрне тикшергәндә бәяләнәчәк.
- Димәк, бүген без сезнең белән нинди теманы кабатлыйбыз, искә төшерәбез? (...)
- укучылар, бергәләп искә төшерик, нәрсә соң ул рәвеш? (эш-хәлнең билгесен белдерә торган сүз төркеме рәвеш дип атала)
- Рәвеш сүз төркеме нинди сорауларга җавап бирә? (ничек? Кайчан?соравына җавап бирә)
- Әйе, бик дөрес. Рәвеш сүз төркеме ул башкалары кебек үк җөмләне, сөйләмебезне тулыландыру, матурлату өчен кулланыла. Алга таба китәбез.

**V. Уку мәсьәләсен чишү.**

-Укучылар, әйтегез әле, сезнең башка шәһәрдә, чит илдә яшәүче дустыгыз бармы?
У: Әйе, безнең башка шәһәрләрдә яшәүче дусларыбыз бар.
- Ә сез алар белән ничек аралашасыз?
У: без алар белән телефон, интернет аша аралашабыз.
- Ә сезнең хат алып караганыгыз бармы?
У: юк
- Ә хатларны ничек язалар?

У: кәгазьдә, интернет аша.
- Без сезнең белән кире текстка әйләнеп кайтабыз. Игътибар белән карагыз әле, бу гади текст кынамы?
У: юк, бу хат
- Әйе, бу хат формасында язылган. Ә безнең хат нинди өлешләрдән тора?
У: 3 өлештән тора.
- Ә хатны ничә кеше язырга мөмкин?
У: электрон, почта аша
- Игътибар экранга (экранда "Простоквашина" мультфильмыннан өзек күрсәтелә)
- Укучылар, әлеге хатны язуда ничә кеше катнаша?
У: 1 кеше һәм 2 йорт хайваны
- Ә хатны алай язып буламы?
У: юк
- Әйе, укучылар, хатны бер генә кеше язырга тиеш. Бер кеше яза һәм бер генә кеше укый. Билгеле, гаилә белән дә укып була, тик язганда бер генә кеше язырга тиеш.
- Укучылар,минем сезгә шундый сорау бирәсем килә, ә без нинди районда яшибез?
У: Яшел Үзән районында
- ә сез беләсезме, безнең районыбызда 2017 нче ел нинди вакыйга белән истә калачак?
У: 85 яшь
- Әйе, районыбызга 85 яшь. Димәк, ничәнче елда нигез салынган?
У: 1932 нче елда
- Бик яхшы, укучылар! Яшел Үзән районы нинди республика белән янәшә яши?
У: Мари Эл республикасы
- Әйе, безнең районыбыз Мари Эл республикасы белән янәшә яши.Укучылар, менә безгә 1 хат килгән. Тик хатыбыз ерактан килгән. Чувашия республикасы Комсомольск шәһәрендә укучы укучылар язган. Әйдәгез, тыңлап китик әле. (укучылар җавабы)
- Афәрин, укучылар! Дашаның нәсел җебе чуваш халкына барып тоташа. Безнең республикабыз үзенең дус, мәрхәмәтле, киң күңелле халкы белән танылган. Без һәр милләт халкы белән дус-тату яшибез. Укучылар, ә сез нинди милләт халыкларын беләсез? Безнең мәктәбебездә генә дә?
У: татар, рус, чуваш, әзербәйҗан, үзбәк, мари.
-Әйе, безнең мәктәбебездә дә татар, рус, мари, чуваш, әзербәйджан, үзбәк, чегән милләте укучылары укый. Һәм без барыбыз да бик дус! Әгәр хәтерләсәгез, безнең мәктәбебездә Украинадан килгән Артем белән Аня укыдылар. Алар бездә 2 генә ел укысалар да, татар телен өйрәнеп, сөйләшә белеп киттеләр. Алар әле дә сезне искә алалар һәм сәламнәр җибәреп торалар. Яхшы, укучылар! Ә хәзер әйдәгез тиз генә бер эш эшләп алабыз. Димәк, без сезнең белән әйттек, хат өч өлештән тора дидек. Башлам өлеше, төп өлеш һәм йомгак өлеше. Беренче рәттә утырган укучылар башлам өлешен искә төшерә, икенче рәттә

утырган укучылар төп өлешне искә төшерә, ә өченче рәт йомгаклый. Тиз генә искә төшердек. Без сезнең белән беләбез, төп өлештә ситуатив сорауларга җавап бирергә кирәк. Ә сораулар болай яңгырый:
1. Сезнең башка шәһәрдә яшәгән дустыгыз бармы?
2. Сез аның белән ничек аралашасыз?
3. Ул нинди дус?
- Укучылар, тиз генә диалогларда эшләп алабыз. Сезнең өстәлләрегездә карточкалар бар. Кемдәдер җаваплар, ә кемдәдер сораулар. Әгәр сездә сорау икән, җавап әзерлисез, җавап икән сорау бирәсез.
- Димәк, укучылар, төп өлешкә сезнең сорауларыгыз бар. Сезгә бары тик хатны дөрес итеп язырга кирәк була. Карыйбыз...
- Ә хәзер сезгә бер күчтәнәч! Игътибар экранга. (экранда КФУ студентларының укучыларга булган сәлам җибәрүләре)

**VI. Рефлексия**

- Әйдәгез, дәресебезгә йомгак ясыйк. Укучылар без бүгенге дәресебездә нәрсә турында сөйләштек?

Без хатны кемгә язабыз? Ничек язабыз? (укучылар җавап бирәләр)

**Өй эше.**

**4. “Безнең дусларыбызга хат” темасына хат язып килергә.**

**5. Тема буенча диалог төзергә.**

**6. Мәкаль табып килергә.**

- Сезнең алдыгызда карточкалар бар, үзегезгә бәя бирегез әле. Сез бүгенге дәрестә ничек эшләдегез? Ничек катнаштыгыз?

## III нче сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле

*Минһаҗева Гөлшат Искәндәр кызы,*
*Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Әйшә гомуми урта белем бирү мәктәбенең I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Дәреснең темасы: “Шәһәрдә һәм авылда” темасы буенча лексик-грамматик материал.**

**Максат:**

1.Белем бирү максаты: шәһәрдә һәм авылда темасы буенча лексик берәмлекләрнең мәгънәләрен аңлап куллану; аларны сөйләмдә дөрес куллана белү;диалог һәм монолог төзи белү.

2.Үстерү максаты:

Танып-белү УУГ: дәреслек материалында кирәкле информацияне табу;нәтиҗәләр чыгару.

Коммуникатив УУГ: сораулар бирә,җавап бирә белү;парларда бергәләп эшәү;үз фикереңне әйтә һәм дәлилли белү.

Регулятив УУГ: план буенча эшләү,үзрегуляция;үз вакытыңны планлаштыра һәм контрольдә тоту.
3. Тәрбияви максат: шәһәрдә һәм авылда темасы буенча сүзләрне дөрес итеп әйтә белү;уку эшчәнлегенең максаты һәм нәтиҗәсе арасында бәйләнешне билгеләү.

**Укытучының планлаштырылган нәтиҗәләре:**

Шәхси УУГ:

- укуга карата кызыксыну хисе;
- укучы ролен үзләштерү;
- нәтиҗәләргә анализ һәм үзконтроль;

Метапредмет нәтиҗәләр.

Регулятив УУГ:

- укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;
- укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү;

Коммуникатив УУГ

- иптәшләренең сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- парларда эшли белү;

Танып – белү УУГ:

- укытучы биргән сорауларга дөрес һәм аңлаешлы җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү.

**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер,проектор, презентация, сүзлекләр, биремле карточкалар.

**Дәрес барышы:**

**1. Мотивлаштыру.**


Уңай психологик халәт яки эш атмосферасы тудыра. (“Шәһәрдә һәм авылда” темасына кроссворд бирә.)

-Исәнмесез, балалар!

- Балалар,бүген бездә кунаклар бар,әйдәгез,алар белән дә исәнләшик.
- Утырыгыз,балалар!

-Хәерле иртә, балалар!Хәлләрегез ничек?

- Балалар,сез бүген ике командага бүленеп эшләячәксез.Мин сезгә ике кроссворд тәкъдим итәм.Сүзләрне белгәч,сез команда исемнәрен укырсыз.




**2. Өй эшен тикшерү.**
-Сезнең өй эшегез дә кроссворд төзү яки рәсем ясап килү иде.(эшләр тактага эленә)
(Балалар өй эшләрен тапшыралар,кроссвордлардагы сүзләрне укыйлар)

**3. Уку мәсьәләсен кую һәм чишү.**
Укытучы: Димәк,без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшәбез инде?
Укучылар : Авыл турында,шәһәр турында.

**4. Фонетик зарядка.**
Авыл төркеме калын,ШәҺәр төркеме йомшак әйтелешле сүзләргә кул чабабыз.(Сүзләрне укый)
Шәһәр
Авыл
Урам
Кат
Өй
Күрше
Халык
Милләт
Башкала
Кеше
Урман
Күл

**5.Белемнәрне актуальләштерү.**
Укытучы: Мин сезгә каточкалар таратам,сез сүзләрнең дөрес тәрҗемәсен табып,кул күтәреп җавап бирерсез.

| | |
|---|---|
| Шәһәр | этаж |
| Авыл | улица |
| Урам | город |
| Кат | дом |
| Йорт | деревня |

(Укучылар сүзләрнең дөрес тәрҗемәсен табып,кул күтәреп җавап бирәләр.)

**6. Ял минуты.**

Укытучы: Балалар,арыгансыздыр,әйдәгез уен уйнап алабыз. (”Түбәтәй” уены уйнау.)




**7. Диалогик сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.**

Укытучы: Балалар,яңа бирем карточкаларда.Сез дустыгызны урамга чакырырга,аның кайда яшәгәнен сорарга,һәм үзегезнең кайда яшәгәнегезне әйтергә тиеш буласыз. Әзер төркем кул күтәреп җавап бирә,җавапларны тыңлагыз һәм хаталары булса төзәтегез.

- Пригласи друга на улицу;
- Спроси где он живёт;
- Ответь где ты живёшь.

Укучылар диалог төзиләр (парларда эшлиләр).Җавапларны тыңлыйлар,бер-берсенең хаталарын төзәтәләр һәм бәялиләр.

-Дустым,әйдә урамга чыгабыз.

-Әйдә чыгабыз.

-Дустым,син кайда яшисең?

-Мин авылда яшим.

**8. Лексик-грамматик күнекмәләрне камилләштерү.**

1. Дәреслекнең электрон кушымтасы ярдәмендә лексик материалны кабатлату.

2.Текст белән эшләү.Биремнәр башкару.




3.Карточкалар белән грамматик күнегү башкару.

(Укучылар сүзләрне кабатлыйлар,тәрҗемә итәләр.


Текстларны уку. Текст эчендә **кем?** Һәм **нинди?** сорауларына җавап булган сүзләрне аерып уку.

(Җөмләләрдәге хаталарны табып төзәтәләр.)

**9. Монологик сөйләмне камилләштерү.**

Рәсем буенча, бирелгән сүзләрне кулланып, авыл һәм шәһәр турында җөмләләр( хикәя) төзетү.

Җөмләләр ( хикәя) төзиләр, берничә укучы җөмләләрне ( хикәяне) укы




1)Бу - авыл.Авыл матур,зур, чиста.Авылда рәхәт,саф һава. Авылда мәктәп,кибетләр,клуб, мунча,мәчет,йортлар бар.
2)Бу – шәһәр. Шәһәр зур,матур, чиста.Шәһәрдә күңелле,йортлар биек,зур урамнар,кибетләр, музейлар, театрлар,цирк, аквапарк, зоопарк бар.
10. Рефлексия.
Укытучы дәрестә туган авырлыклар турында сорый, дәрескә нәтиҗә ясый, укучыларның эшенә бәя бирә.
- Балалар,бүген дәрестә без нәрсәләр өйрәндек? (авыл һәм шәһәр турында)
-Ничек уйлыйсыз,кайсы команда җиңде?Кайсы команда яхшырак эшләде?(Ике команда да!)
-Ни өчен алай уйлыйсыз?
-Сезгә бик кыен булмадымы?
(Балаларның җаваплары)
**10. Өй эше:**
1)Авыл яки шәһәр турында сөйләргә өйрәнергә(3-4 җөмлә);
2) Авыл яки шәһәр рәсемен ясарга;
3) Авыл һәм шәһәр турында сүзләрне кабатларга.

Дәрес тәмам,сау булыгыз балалар!

## V – X сыйныфларда укучы татар балаларына - сыйныфтан тыш чара

***Бачкова Эльвира Василий кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы***

***Әйшә урта гомуми белем бирү мәктәбенең***
***югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

Тема: **Журналист булу җиңелме?**
Максат: 1) Укучыларны журналист һөнәре, аның җәмгыятьтә тоткан роле, үзенчәлекле һәм кызыклы яклары белән таныштыру, татар журналистикасы тарихы турында мәгълүмат бирү;
2) укучыларның иҗат активлыкларын үстерү, газета-журналларга мәкаләләр язу алымнарын ныгыту;
3) төрле һөнәр ияләренә тирән хөрмәт, туган телебезгә карата мәхәббәт тәрбияләү.
Җиһазлау: республикада чыга торган газета-журналларга күргәзмә, укучыларның мәкаләләре басылып чыккан газета-журналлар саны, “Яшь каләмдәш” презентациясе.

**Пресс – конференция барышы**

Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар, хәерле көн, кадерле укучылар!

Журналист булу җиңелме?

Без бу чараны журналистика өлкәсенә багышларга булдык. 2005 нче елдан алып мәктәбебездә “Яшь каләмдәш” клубы эшләп килә. Ул 5-11нче сыйныф укучыларын берләштерә. Клубның максаты - укучыларны газета-журналларга мәкаләләр язарга өйрәтү. Аларның язмалары район газетасы “Яшел Үзән”дә һәм республикада нәшер ителә торган “Көмеш кыңгырау” газетасы, шулай ук “Сабантуй”, “Ялкын” журналларында басылып тора. Иң актив хәбәрчеләребез – Вәлиева Гүзәл, Гафиятуллина Зәринә, 8 нче сыйныф укучылары; Юзеев Владислав 9 нчы сыйныф, 10 нчы сыйныф укучысы Сабиров Әлфир. Бүгенге чарада сез дә аларның иҗат җимешләре белән танышырсыз. Ә бүген бездә кунаклар да бар. Алар - Казан шәһәрендә балалар һәм яшүсмерләр өчен чыгып килә торган “Ялкын“ журналы хезмәткәрләре

- Абдрахманова Айгөл Айрат кызы “Ялкын” журналының җаваплы сәркатибе;
- Гыймадиев Айдар Марс улы “Ялкын” журналы филиалы җитәкчесенең урынбасары;
- Шакирова Эльвира Радик кызы “Ялкын” журналының бүлек редакторы.

Бу очрашуга әзерләнгәндә безне кызыксындырган сораулар күп булды:
- Газета ничек туа?
- Аңа материаллар ничек әзерләнә?
- Журналистлар һәрбер яңалыкны вакытында җиткерергә ничек өлгерә?
- Татар матбугаты ни хәлдә?

Ә профессиональ журналистлар безнең фикерләребез белән килешерме?

Безнең бүгенге кичә **III турдан** тора. Беренче тур “Көчле кеше берне, белемле кеше меңне егар” мәкале астында үтә. Белемнәребезне тикшереп карау йөзеннән татар матбугаты тарихына күзәтү ясап китәрбез. Ул сорау-

җавап формасында узачак. Сораулар укучыларга өй эше итеп бирелгән иде, әзерләнеп килгәннәрдер дип ышанып калам.

1. Газета ни өчен кирәк?

(Газета – ул мәгълүмат чыганагы. Үзебезгә кирәкле киңәшләрне дә, яңалыкларны да, районда һәм республикада барган үзгәрешләрне дә газетадан укып беләбез).

2.Беренче татар газетасының исемен әйтегез һәм ул ничәнче елда, кайда дөнья күрә?

(Беренче татар газетасы «Нур» дип аталган. Ул 1905 нче елның 2 нче сентябрендә Санкт-Петербургта дөньяга килә).

3.Татар газеталары Казан шәһәрендә генә чыгарылганмы?

(Татар газеталары Казаннан кала, Мәскәүдә, Уфада, Оренбургта, Астраханьда, Сембердә, Чиләбедә, Саратовта, Уральскида, Троицкида, Томскида һәм Ташкентта басылып киләләр).

4. Казанда балалар өчен атап ике журнал чыгарылган, алар ничәнче елларда дөнья күрә, нинди исем астында бастырыла?

(Балалар өчен атап чыгарылган иң беренче журнал «Балалар тәрбиясе» дип атала. Ул 1907нче елда ук дөньяга килә, ә икенче журнал — «Ак юл» исемле була. Ул 1913 нче елдан башлап 1916 нчы елга кадәр ике атнага бер тапкыр Казан шәһәрендә чыгып килә).

5. 1917нче елгы Октябрь революциясенә кадәр Россиядә күпме газета һәм журнал чыккан?

(1917 нче елгы Октябрь революциясенә кадәр Россиядә 58 исемдәге газета һәм 37 журнал чыккан).

6.1917-1918нче елларда Казан шәһәрендә нинди балалар журналы чыга? Ул кем җитәкчелегендә дөнья күрә?

(1917—1918 нче елларда Казанда Якуп Хәлими җитәкчелегендә «Балалар дөньясы» исемле журнал чыга).

7. Бүгенге “Ялкын” һәм “Сабантуй” журналларына ничәнче елда нигез салына?

( Бүгенге «Ялкын» һәм «Сабантуй» журналларына 1924 нче елда ук нигез салына. Төрле елларда төрле исемнәр белән чыгып килсәләр дә, бу ике басма һәрвакыт балаларның иң якын сердәше һәм киңәшчесе булып калды. Шуңа да карамастан, һаман да яшьләр кебек фикерли, алар белән бергә атлый).

8. Бүгенге газета-журналлар башлангычларын кайдан алганнар?

(Аралашу, үзара информация алмашу — кешелек яшәешенең иң мөһим шартларыннан берсе. Шуңа күрә дә журналистика иң борынгы һөнәрләрдән санала. Инде безнең эрага кадәр үк борынгы римлылар төрле хәбәрләр җыелмасыннан торган «актлар» язып халыкка тарата торган булганнар. Бу бүгенге матбугатның башлангычы дип тарихка кереп калган).

9. Иң беренче календарьларны кем төзегән?

(Иң беренче календарьларны якташыбыз мәгърифәтче Каюм Насыйри төзегән).

10. Бүгенге көндә Татарстанда балалар өчен чыга торган газета-журналларның исемнәрен атагыз.
(Татарстанда балалар өчен “Сабантуй”, “Көмеш кыңгырау” газеталары, “Ялкын”, “Салават күпере”, “Сабыйга” журналлары чыга).

11. Укытучы. Һәрберебезнең өенә килә торган газета-журналларны кемнәр чыгара? Билгеле инде, журналистлар. Аларга нинди сыйфатлар хас? Хәбәрче нинди булырга тиеш?

1. Беренчедән, кызыксынучанлык. Миңа калса, хәбәрче өчен иң кирәкле сыйфатларның берсе бу.

2. Икенчедән, тормышта яки җәмгыятьтә теге яки бу әйберне, вакыйганы үз күзең белән күрү кирәк. “Йөз кат ишеткәнче, бер кат күр”, ди бит халык та. Димәк, газета-журнал язмасы иҗат итүчеләр өчен кирәкле мөһим сыйфатларның тагын берсе – күзәтүчәнлек. Яңалыкны иң беренче булып күрә белергә, башка кешенең игътибары җитмәгән күренешләрне дә ачып бирә белсәң, уңышка тизрәк ирешәсең.

3. Минемчә, күзәтә белү һәм күзәткәннәренә дөрес бәя бирү өчен хәбәрче гаять белемле дә булырга тиеш.

4. Билгеле инде, исем-фамилияләрне, саннарны кәгазь битенә язганда төгәллек кирәк. Минемчә, төгәллек, документальлек – хәбәрче кеше өчен мөһим булган сыйфатларның тагын берсе. Газета язмасы матур әдәбият әсәре түгел. Анда бернинди вакыйгалар, фактлар, персонажлар да уйлап чыгарыла алмый.

5. Минем фикеремчә, кәгазь һәм каләм белән генә эш итсә дә, хәбәрче кыю һәм батыр булырга тиеш. Җәмгыятьнең кайсы өлкәсендә нинди тискәре күренеш бар – иң беренче булып аны хәбәрче һәм журналистлар күреп тәнкыйть итә.

6. Журналистлар төрле һөнәр ияләре, төрле яшьтәге һәм төрле холыклы кешеләр белән аралаша. Үз язмасы өчен мәгълүмат туплаган вакытта аңа күпләр белән очрашып сөйләшергә туры килә. Димәк, ул аралашу осталыгына ия булырга, татар телен камил белергә тиеш.

7. Минем уйлавымча, укучыны кызыксындыра алырлык тема таба белү дә мөһим.

**НӘТИҖӘ:** Димәк, шушы сыйфатларны үзеңдә булдыра алсаң, син чын журналист була алачаксың.
Хөрмәтле кунаклар, Сез укучыларның фикерләре белән килешәсезме?

“Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи” дигән мәкаль **II тур**ыбызның девизы булып тора. Хәзер без укучыларыбызның язган мәкаләләренә күзәтү ясарбыз. Алар район газетасы “Яшел Үзән”, Яр Чаллы шәһәрендә чыгып килүче балалар газетасы “Көмеш кыңгырау” һәм башкалабызда нәшер ителүче “Ялкын”, “Сабантуй” журналлары белән ныклап дуслашты. Укучыларның мәкаләләре һәрдаим басылып тора. Менә алар:
1. Вәлиева Гүзәл, “Театрда булу – күптәнге хыялым”, “Көмеш кыңгырау”, №40, 2015

2. Вәлиева Гүзәл, “Театр – яктылыкка, нурга илтә...”, “Яшел Үзән”, №93, 2015
3. Вәлиева Гүзәл, “Кытайга барып булса да ...”, “Көмеш кыңгырау”, №2, 2016
4. Гафиятуллина Зәринә, “ Үкенмәссез!”, “Ялкын!” №3, 2016
5. Сабирова Илюзә “Табигатьне сакларга кирәк”, “Яшел Үзән”, №22, 2017
6. Сабиров Әлфир “Сокландык”, “Сабантуй”, №4, 2017

Мәкаләләр бик күп, барысын да бүген укып бетерү мөмкин түгел. Калганнары белән дәрестә яки “Яшь каләмдәш” клубы утырышында танышуны дәвам итәрбез. Ә хәзер иң актив хәбәрчеләребезгә сүзне бирәбез.

- Сабирова Илүзә “Табигатьне сакларга кирәк”
- Гафиятуллина Зәринә “Үкенмәссез!”
- Сабиров Әлфир “Сокландык”
- Вәлиева Гүзәл “Кытайга барып булса да...”

**НӘТИҖӘ:** Бу турга нәтиҗә ясап, шуны әйтәсем килә: иҗат эшләре җиңел генә бирелми. Аларны язар өчен шактый вакыт сарыф ителә. Әмма халык та “Сабыр төбе-сары алтын”,- ди. Сабырлык белән эшләсәң, эшеңнең дә нәтиҗәсе булыр.

**<u>III тур</u>** Менә журналист абый һәм апаларыбыз белән дә якыннанрак танышырга вакыт җитте. Мәктәбебезгә журналистлар киләсе билгеле булгач, укучыларыбыз күп итеп сораулар да әзерләп килделәр.

- Журналист буларак беренче эш көнегезне хәтерлисезме, һәм ул ничек үтте?
- Сезнең беренче мәкаләгез кайсы газетада басылып чыкты, Сез аның эчтәлеген хәтерлисезме?
- Студент вакытындагы бер кызыклы вакыйганы сөйләп бирегез әле.
- Журналист булырга Сезне нәрсә этәрде, әллә аның берәр сәбәбе булдымы?
- Туган тел мәсьәләсенә Сезнең карашыгыз ничек?
- Журналист булу җиңелме?

Укытучы. Әйтегез әле, безнең кулыбызга килеп эләккәнче журнал нинди юллар үтә?

**Йомгаклау.** Журналистика өлкәсенә багышланган очрашуыбыз әкренләп тәмамланып килә. Каләм тибрәтүче яшь дусларыбыз үзләрен борчыган сорауларга җаваплар тапканнардыр дип уйлыйм. Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә: укучыларыбызның иҗат чишмәләре саекмасын, алар һәрвакыт челтерәп агып торсын иде. Укучыларыбыз белән очрашуга килгәнегез өчен сезгә зур рәхмәт, хөрмәтле журналистлар. Киләсе очрашуларга кадәр сау булыгыз!

**Ата-аналар белән эш:** Әби, онык, туган тел.
(Түгәрәк өстәл)

***Мусина Гөлназ Шәриф кызы,***

***Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы***
***Әйшә урта гомуми белем бирү мәктәбенең***
***югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

***Максат:***1.Укучыларның әбиләре белән якыннан танышу.
2.Әбиләргә телебезне саклауның мөһимлеген аңлату.
3.Гаиләдә әби-бабай тәрбиясен көчәйтү.
4.Балаларда әби-бабаларга карата ихтирам тәрбияләү.
***Җиһазлау:*** компьютер,проектор, презентация, китаплар, биремнәр.

**Чараның барышы.**

***Укытучы.***Елдан ел татар гаиләләрендә туган телен белми торган балалар күбрәк тәрбияләнә. Моңа катнаш гаиләләрдәге татарча сөйләшми торган балаларны да кушсаң, бик зур сан килеп чыга. Ә инде балалар телне белмәсә, татар милләтенә дә игътибарлары кими яисә бөтенләй бетә.

Менә бүген без шул турыда сөйләшергә җыелдык. Мәктәпнең әбиләр советы утырышын башлыйбыз.

**Беренче кисәк.**

Ә хәзер кадерле әбиләребезне, дәү әниләребезне балалар сәламлиләр.

**1.Дәү әнием**
Әминә Бикчәнтәева

Әниемнең әнисе
Әбием була минем.
Әби генә түгел әле,
Ул минем дәү әнием.
Ак ефәктәй чәчләрен
Ул тарап куя үреп.
Чисталыкка өйрәнәм
Мин дә аңардан күреп.
Күзлексез күрмәсә дә,
Таяксыз йөрмәсә дә,
Җитмеш яше тулса да,
Бик картайган булса да,
Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөлләр үстерә;
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул.

**2**. “Дәү әнигә бүләккә” җыр.

**3.**Дәү әнидә кунакта (Ж.Тәрҗеманов)
Җәй көне булдым авылда,
Дәү әнидә кунакта.

Татарча сөйли белергә
Өйрәндем мин шул чакта.

Өйрәнмичә булмый анда,
Русча берни белмиләр.
Әллә уйнап, әллә чынлап:
"По-русски не знай", – диләр.

Тавыклар да, үрдәкләр дә
"Куш-шай" – дисәң, качалар.
"Аша", – дисәң, авызларын
Бик зур итеп ачалар.

Сөтләре дә, каймагы да
Бөтенләй башка анда;
Авылда дәү әниләрдә
Торсаң иде һаман да.

Киләсе җәйдә әни дә,
Әти дә барыр әле,
Һәм татарча сөйләшергә
Өйрәнеп кайтыр әле.

4. "Дәү әнием" җыр.

**Икенче кисәк.**


***Укытучы.***Соңгы елларда татар гаиләләрендә тәрбияләнгән балаларның милләтебезгә битарафлылыгы күбрәк күренә башлады. Бу бик аяныч хәл .
Бүген без сезнең белән шушы проблеманың сәбәпләре һәм бу ситуациядән чыгу юллары турында сөйләшербез.
*Балаларның татарча сөйләшмәүләренең сәбәбе нәрсәдә соң?
(Гаиләдә сөйләшмиләр, кирәк түгел , диләр.)
*Бала тәрбияләгәндә иң зур рольне кем уйный?
(Ата-ана, бала белән кем күбрәк аралаша-шул.)

*Бала тәрбияләгәндә әби, дәү әниләрнең роле нинди?
(Әбиләрнең оныклары белән аралашырга вакыты күбрәк. Ләкин кемдер бөтен күңелен бирә,кемдер иренә,кемдер битараф.)

*Балалар өчен әби, дәү әни кем соң ул?"Минем дәү әнием" исемле видеоролик карап үтик.

*Роликтан күренгәнчә, без оныкларыбызны ашатабыз, эчертәбез, хәвеф-хәтәрдән саклыйбыз. Ә менә милләткә ихтирам хисләрен тәрбиялибезме соң?

* Сез ничек уйлыйсыз: гаиләдә милләтебезгә ихтирам, милләтебезне ярату хисләрен ничек тәрбияләп була?Фикер тупларга җиңелрәк булсын өчен, төркемнәрдә эшләргә тәкъдим итәм.
(Төркемнәрнең җаваплары.)
*Яхшы. Минемчә, сез куелган мәсьәләне дөрес чиштегез, булдырдыгыз. Без сөйләгәннәрне менә мондый схема белән күрсәтеп булыр иде.




Хә... нәрдә тә... анын карап алыйк.
*Хөрм... м, тагын бер ка... рагыз әле: сез әйткән чараларның кайсысы мөһимрәк? Әгәр мөһимлелек ягыннан тезсәк, иң беренче итеп кайсын куяр идек?
(Татарча сөйләшү.)
*Алар барысы бергә булганда гына, чын татар рухлы кеше тәрбияләп була. Тагын шуны да онытмаска кирәк: бала кечкенәдән ата –анасын , әби-бабасын үзенең иң якын, иң ышанычлы кешеләре итеп тоярга тиеш. Моңа ирешү өчен, билгеле, балага карата битараф булырга ярамый, аның белән гел аралашып торырга кирәк, телевизор, санак алдына утыртып куярга ярамый.

**Карар чыгару.**

1.Өйдә оныклар белән татарча сөйләшергә.Милләткә ихтирам тәрбияләргә.

**Өченче кисәк.**

***Укытучы.***Өйдә балалар белән,гаилә белән уйнап була торган кайбер уеннарны, аралашу мисалларын карап үтик.

**1нче уен.** Ребус чишү.




***Укытучы.***Без сезнең белән балаларга китаплар укуның әһәмияте турында әйтеп үттек. Китаплар кебек үк безнең якын дусларыбыз - ул газета – журналлар, вакытлы матбугат. Мин сезне “Салават күпере”, “Сабантуй”, “Ялкын” кебек журналлар белән тагын бер кат таныштырып үтәсем килә. Аларда кызыклы мәкаләләр, төрле киңәшләр, ребуслар, башваткычлар. балалар иҗаты үрнәкләре таба алабыз. Бу журналлар белән хезмәттәшлек итеп тә була .

**2нче уен.** “Дәү әни-и-и, бу нәрсә?” дип атала. Балалар экранда күрсәтелгән агачларның, кошларның исемнәрен атарга тиеш. Белмәсәләр, дәү әниләргә мөрәҗәгать итәләр.

**3нче уен.**Бирелгән шаблоннар ярдәмендә татар кулъяулыгы ясагыз.

***Укытучы.***Уенның нәтиҗәсе шундый: балалар телне начар белә. Күпме яңа сүзләр өйрәнәсе бар әле безнең оныклар белән! Шушы зур эшне башкарырга булышу өчен, минем сезгә китаплар бүләк итәсем килә.

**Укучы:**

Туган телем
Ленар Шәех

Туган телем дәү әнинең
Әкиятендә калган.
Дәү әтинең догасында
уй-ниятендә калган.
Туган телем әниемнең
 бишек җырына күчкән
Әтиемнең тире тамган
Бодай кырына күччкән...
Туган телем килеп җиткән
Миңа әнием аша.
Аның тамыры бабама,
Әбиемә тоташа.
Туган телдә сөйләшәм мин,

Җыр җырлыйм, дога кылам.
Сезне дә ана телендә
Сөйләшергә чакырам.

***Укытучы.***Телебезне сугарып торучы саф чишмә – балаларда. Ә аларны өйрәтүчеләр - өлкән буын. Өлкән буын белән балалар арасында бәйләнеш өзелсә, телебез әкрен – әкрен бетәчәк.Әйдәгез, моңа чик куйыйк.

## 2нче һәм 7нче сыйныфларда укучы рус балаларына - татар теле

***Зыятдинова Гөлнур Рәис кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы***
***Әйшә урта гомуми белем бирү мәктәбенең***
***югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***
***Ахметшина Ирина Николай кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы***
***Әйшә урта гомуми белем бирү мәктәбенең***
***югары квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы***

**Дәреснең темасы:** Кышкы табигатьне саклау.
**Максат:**
**1**. *Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):* Өйрәнелгән лексик-грамматик конструкцияләрне, фигыль формаларын сөйләмдә куллана белүне камилләштерү.

**2.** *Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):* Укучыларның сөйләм байлыгын арттыру, фикерләү сәләтен үстерү. Үзара аралаша белү мөмкинлекләрен үстерү. Үз хезмәтеңне бәяли белергә өйрәтү.
**3.** *Тәрбияви максат (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):* табигатькә карата мәхәббәт, ихтирамлылык, игътибарлылык тәрбияләү

**Укытучының планлаштырылган нәтиҗәләре.**

**Шәхси УУГ:**

- укуга карата кызыксыну хисе;
- укучы ролен үзләштерү;
- нәтиҗәләргә анализ һәм үзконтроль;

**Метапредмет нәтиҗәләр.**

**Регулятив УУГ:**

- укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;
- укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү;

**Коммуникатив УУГ**

- иптәшләренең сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- төркемдә эшли белү;

**Танып – белү УУГ:**

- укытучы биргән сорауларга дөрес һәм аңлаешлы җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү.

**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, интерактив такта, презентация, рәсемнәр, биремле карточкалар.

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру.**

***Дәресне оештыру (исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу)***

***1нче укучы***

Добрый день ! Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар, кадерле балалар! Бүген без табигатьне саклау комитетының утырышына чакырылганбыз.

Дәреснең темасы: «Кышкы табигатьне саклау»

***1 укучы (приветствие на татарском языке)***

Исәнмесез диеп башлыйм әле,
Очрашу бит шулай башлана.
Сезнең белән очрашканга,
Күңелебез шундый шатлана.

А чтобы узнать где будет проходить заседание, я предлагаю вам послушать музыку. (Самир курайда уйный).
-Какая звучала мелодия? Татар көе яңгырады.
Действительно, заседание будет проходить на нашей родине в Республики Татарстан на территории Волжско -Камского биосферного заповедника.
***-стих 7б (на татарском языке)***

Вы видели природу Татарстана?

Прекрасные холмы, озёра и леса...
Мне кажется, там происходят чудеса!
Они так живописны, так красивы!
Всю эту красоту нужно беречь,
Беречь её так гордо, как родную речь!

Нигә бу көй чиртә икән
Күңелнең кылларына?
Кемнәр генә гашыйк түгел
Туган як моңнарына.

Туган җирем –Яшел Үзән,
Раифа, Әйшә, Ключәләр.
Табигатькә гашыйклар яши,
Горурлык белән дәшәм!

**II. Уку мәсьәләсен чишү.**

Без бүген туган ягыбыз Яшел Үзән һәм аның бай табигате турында сөйләшербез. Комитетта эшләү өчен төркемнәргә бүленик.

***Беренче төркем*** "Үсемлекләр дөньясы".
Тыюлыкта үсемлекләрнең төре бик күп, әмма урман төп өлешне алып тора.
Табышмак әйтелә. Язын киенә, көзен чишенә, нәрсә бу? Агач.
- Ә хәзер тыюлыкның иң карт агачы имән турында бер укучы сөйли.
***Икенче төркем*** "Хайваннар дөньясы".
Идел-Кама тыюлыгында хайваннар дөньясы бик бай. Кызганычка каршы, аларның күбесе Кызыл китапка кертелгән. Тыюлыктагы иң зур җәнлек – поши.
Табышмак. Урманда эчендә йөри, зур мөгезле, ул нәрсә?(поши).

Укучылар, эшебезне дәвам итәр өчен хәзер күзләребезне йомабыз, матур көй тыңлап алабыз. (Кошлар сайравын тыңлыйлар).
- Балалар, нәрсә тавышы бу?
- Әйе, дөрес, кошлар сайравы.

**Өченче төркем** "Кошлар".
Һәр кошның үз җыры, сайравы - аларның аралашу чарасы. Сайрау ярдәмендә алар бер - берсен тиз табалар. Тыюлыктагы иң зур кош турында тыңлап карыйк әле.
Табышмак. Яктылыктан курка, төнлә оча тычкан сагалый. Ыргак томшык, сизгер колак, мәче башлы ... (ябалак).

Шулай итеп, һәр оешманың мәгълүматын тыңлап узгач, без тыюлыкның нинди бай булуын аңладык.
- Укучылар, ни өчен тыюлыкларны булдыралар?
- Табигатьне кем сакларга тиеш?

- Без табигатьне сакларга тиешме?
Әлбәттә, кеше табигатьне саклап, аның байлыгын киләчәк буыннар өчен калдырырга тиеш. Татарстан Республикасы илебезнең үзәгендә урнашкан, шуңа күрә елның дүрт фасылы да безгә ачык сизелә.
- Сезнеңчә, елның кайсы фасылы табигать өчен иң авыры?
Дөрес, кышын җәнлекләргә, кошларга аеруча кыен.
Хәзер, комитет утырышының нәтиҗәсе итеп, табигатьне саклау турында плакат ясап алыйк.

**III. Рефлексия**

- Әйдәгез, дәресебезгә йомгак ясыйк. Укучылар без бүгенге дәресебездә нәрсә турында сөйләштек?
Без кемнәргә булышабыз? Ничек булышабыз? (укучылар җавап бирәләр)
Өстәлләрдә конвертларга әзерләп куелган сүзләрдән җөмлә төзеп, рәсем белән тәңгәлләштереп плакат ясыйбыз.
- Агачларны кисмәгез!
- Кышын җәнлекләрне ашатыгыз.
- Кышын кошларны ашатыгыз.
- Табигатьне бергә саклыйк!

**IV. Өй эше.**

**1.“Туган ягым табигате ” темасына хикәя язып килергә.**
**2. Тема буенча диалог төзергә.**
**3.Табышмаклар табып килергә.**

- Сезнең алдыгызда карточкалар бар, үзегезгә бәя бирегез әле. Сез бүгенге дәрестә ничек эшләдегез? Ничек катнаштыгыз?

**5. Өй эше:** Текстка тулы сочинение - фикерләү язып килергә.



**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ 3 НЧЕ НОМЕРЛЫ ГИМНАЗИЯСЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**




**15 нче март, 2017 нче ел**

Зеленодолмуниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен семинары – практикум
**«IX сыйныф укучыларын бердәм республика тестларына һәм татар теленнән төп дәүләт имтиханнарына әзерләү үзенчәлекләре»**

Семинар - практикум для учителей татарского языка и литературы общеобразовательных организаций Зеленодольского муниципального района
**«Особенности подготовки обучающихся IX классов к единому республиканскому тестированию и ОГЭ по татарскому языку в 2017 году»**









**7.**

## VI сыйныфта укучы рус балаларына -татар теле

***Халитова Ләйсән Хәмит кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 3 нче гимназиясенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы:** Мин өйдә – булышчы.
**Максат:**
1. *Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):* Өйрәнелгән лексик-грамматик конструкцияләрне, фигыль формаларын сөйләмдә куллана белүне камилләштерү.
*2. Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):* Укучыларның сөйләм байлыгын арттыру, фикерләү мәләтен үстерү. Үзара аралаша белү *мөмкинлекләрен* үстерү. Үз хезмәтеңне бәяли белергә өйрәтү.
3. *Тәрбияви максат (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):* Эшчән, ярдәмчел булырга, әти-әниләргә, өлкәннәргә булышырга теләк уяту. Бер-береңә матур итеп эндәшә, матур сөйләшә белү күнекмәләрен үстерү.
**Укытучының планлаштырылган нәтиҗәләре.**
**Шәхси УУГ:**
- укуга карата кызыксыну хисе;
- укучы ролен үзләштерү;
- нәтиҗәләргә анализ һәм үзконтроль;
**Метапредмет нәтиҗәләр.**
**Регулятив УУГ:**
- укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;
- укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү;
**Коммуникатив УУГ**
- иптәшләренең сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- парларда эшли белү;
**Танып – белү УУГ:**
- укытучы биргән сорауларга дөрес һәм аңлаешлы җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү.
**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, интерактив такта, презентация, сүзлекләр, биремле карточкалар.
**Дәрес барышы**
**VII. Мотивлаштыру.**
***6. Дәресне оештыру (исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу)***
-Исәнмесез, укучылар!
- .......
- Хәлләрегез ничек?
-........
- Рәхмәт, минем дә хәлләрем бик яхшы. Дәресебезне башлыйбыз.
***7. Өй эшен тикшерү***
- Укучылар, сез бирелгән шарт фигыльләр белән җөмләләр төзергә тиеш идегез. *(җырласаң, биемәсә, көлсәк, бармасаң, яумаса, китсәгез, кайтмасам).* Әйдәгез, өй эшләрегезне тыңлап үтик.
***8. Уку мәсьәләсен кую.***
- Экрандагы шигырьләрне игътибар белән укыгыз. Бу шигырь нәрсә турында? *(Слайд 1)*

| | |
|---|---|
| Әни утыртты гөлләр<br>Алар үсә зур булып,<br>Утыралар ямь биреп,<br>Бөтен өебез тулып<br>Мин аларга су сибәм<br>Яки иртән. Я кичен,<br>Әниемә булышам<br>Эш аз булсын өчен. | Әни пәрәмәч пешерә<br>Вак итеп тәмле итеп<br>Без табында чөй эчәбез<br>Бергәләп, тәмле итеп<br>Мин дә булыштым әнигә<br>Пәрәмәчләр ясарга<br>Үзең эшләгәч тәмле ул<br>Кирәк эшләп ашарга |

Укытучы: - Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшүне дәвам итәбез.
- *Әнигә булышу турында.*
- Әйе, укучылар, без бүгенге дәрестә әнигә булышу турында сөйләшербез.

**VIII. Уку мәсьәләсен чишү.**
- Укучылар, сез эти-әниегезгә ничек булышасыз? (үз җавапларын бирәләр)
- Ә хәзер тактага карагыз әле. Бу рәсемнәрдә малай нишли? *(Слайд 2)*



***Укучылардан көтелгән җаваплар:***
- *Малай идән суырта.*
- *Малай тузан сөртә.*
- *Малай кер үтүкли.*
- *Малай чүп чыгара.*
- *Малай идән себерә.*
- *Малай ашарга пешерә.*
- *Малай урынын җыя.*
- *Малай идән юа.*
- *Малай сеңлесенә булыша.*

**Укытучы: -** Укучылар, бу җөмләләрне ничәнче затта кулландык? Ә хәзер беренче затта кулланып карыйк әле. Җөмләләр үзгәрерме?
***Укучылардан көтелгән җаваплар:***
*Мин идән суыртам. (бу формада җавапларын дәвам итәләр)*
**Укытучы: -** Укучылар, дустыгыздан сорагыз әле, ә ул сезгә җавап бирсен. *(Слайд 3)*
***Спросите у товарища, помогает ли он маме:***
- *что он делает?*
- *поливает ли он цветы?*
-*вытирает ли он пыль?*

- *подметает ли пол?*
- *заправляет ли постель?*
- Укучылар, тактага карагыз әле. Диалогларга кирәкле репликаларны өстәп, үзара сөйләшегез. ( бу эш төре группаларда эшләнә, барлыгы 3 группа) *(Слайд 4)*

**1.** - Коля, син өйдә булышасыңмы?
- ........ .
- Нәрсә эшлисең?
- ...... .
- Син тагын кемгә булышасың?
- ......... .

**2.** - Ләйлә, син аш пешерә беләсеңме?
- ....... .
- Тагын нәрсә пешерә беләсең?
- ...... .
- Син торт пешерә беләсеңме?
- .....

**3.** – Азат, син дәү-әниеңә ничек булышасың?
- ..... .
- Чәкләргә су сибәсеңме?
- ..... .
- Сиңа дәү-әниеңә булышырга ошыймы?
- ...... .

**Укытучы:** - Бик әйбәт җавап бирдегез. Әйдәгез бер уен уйнап алыйк. Сүзләр адашканнар, дөрес итеп җөмләләрне төзергә кирәк. *(Слайд 5)*

*Мин тәлинкә ашыйм.- мин тәлинкә юам*
*Син идән пешерәсең.- син идән себерәсең*
*Син аш юам.-син аш пешерәсең*
*Син китап себерәсең. –син китап укыйсың*
(укучылар җөмләләрнең дөрес формасын әйтәләр)
- Дәресебезне дәвам итәбез. Аерым сүзләрдән җөмләләр төзегез. (*Слайд 6)*
*Без, эшчән, түгел, балалар, ялкау, без.*
*Кунаклар, килә, җыештырабыз, шуңа күрә, өй , бүген, безгә.*
*Мин, булышам, әнигә.*
*Барлык, тырыш, эшчән, балалар, сыйныфта, һәм, безнең.*
- Дәвам итәбез. Бирелгән җөмләләрне дәвам итегез. *(Слайд 7)*
*Мин бүген булыша алмый, чөнки ...*
*Мин савыт-саба юа алмыйм, чөнки ...*
*Мин тырыш кыз, чөнки ....*
*Мин әнигә булышам, чөнки ......*
*Әнинең өйдә эше күп, шуңа күрә ...*
- Ә хәзер укучылар тәрҗемә итеп алыйк әле. (*Слайд 8)*

***Как скажете о том, что:***
- *дома очень много работы;*

- *вы  помогаете маме;*
- *вы умеете варить суп;*
***Как попросите сестренку:***
- *быстрее одеться;*
- *подмести пол;*
- *отвести братика в детский сад;*
- *поставить чайник;*
- Сезнең  өстәлегездә карточкалар, анда төрле хәрефләр бирелгән, ул хәрефләр буталган **буталган,** алардан  булышу темасына караган **сүзләр** төзергә кирәк.

Слайд 9
и,ә,д, н, с, р,е,е, б, ә- идән себерә
к,е,р,а,ю- кер юа
с,с,а,а,ю,в,ы,т,б- савыт-саба юа
ү,т,к,ү,и,л,р,е,к- кер үтүкли
ч,р,т,а,и,т,с,а,р,б,г,ң,е,ә,ә,р- бәрәңге читарта
ш,е,п,а,ш,р,е,ә- аш пешерә
с,с,у,и,б,ә- су сибә
с,т,у,з,ө,р,т,а,н,ә - тузан сөртә
б,з,е,б,л,ы,ч,л,р,а,ы,ш,у,- без булышчылар
- Укучылар, бик дөрес җавап бирдегез.

**IX. Рефлексия**

Әйдәгез, дәресебезгә йомгак ясыйк. Укучылар без бүгенге дәресебездә нәрсә турында сөйләштек? Без кемнәргә булышабыз?  Ничек булышабыз? (укучылар җавап бирәләр)

**Өй эше.**

**8. “Мин өйдә зур булышчы” темасына хикәя язып килергә.**
**9. Тема буенча диалог төзергә.**
**10. Мәкаль табып килергә.**

## VIII сыйныфта укучы рустеллебалаларга -татар теле

***Караметдиноаа Гөлсинә Госман кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 3 нче гимназиясенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы:** Табигать һәм кеше.

**Дәрес барышы**

**Максат:**

Ясалма сыйфатларны сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллана белү күнекмәсен формалаштыру.

Туган якны яратырга, “табигатьне ничек сакларга?”- дигән сорауга фикер йөртеп җавап бирергә өйрәнү.

**Дәрес төре**: гамәли дәрес

**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, интерактив такта, презентация

**Дәрес барышы:**

**I. Оештыру** (психологик уңай халәт тудыру ).

**II. Тыңлаган текстның төп эчтәлеген аңлау этабы.**

Без “Табигать темасына караган 5 кыска текст тыңлыйбыз, алар НӘРСӘ ТУРЫНДА?

8 сыйныф өчен татар теле дәреслеге.Р.З. Хайдарова, Р.Л.Малафеева (60, 66,70,71,72 битләр.)

**II. Укылган текстның төп эчтәлеген аңлау этабы.**

Өйдә “”Урман” исемле текстны укыдык.Укылган текстның төп эчтәлеген аңладыкмы? Хәзер тикшереп карыйбыз ( презентация)

*а) туры килә б) туры килми.*

1.Кешеләр урманны яраталар.
2.Урман табигатьне бизи.
3. Урман- нефть һәм газ дөньясы.
4.Урман йорт хайваннарына һәм һәм кошларга яшәү урыны һәм азык бирә.
5.Урман сәламәтлек өчен файдалы.
6.Урманда велосипедта йөрү бик рәхәт.
7.Урманны саклау- һәркемнең изге бурычы.
8. Уңыш үстерүдә урманның әһәмияте бик зур.

**III. Телдән җавап бирү өлеше.**

Балалар, сез ЭКОЛОГИЯ КОНФЕРЕНЦИЯСЕНДӘ, сезгә табигать темасына сораулар бирәләр; Сорауларны игътибар белән тыңлыйбыз һәм тулы җаваплар бирәбез.(парларда эш)

*Җаваплар тыңланыла. Нәтиҗә ясала.*



7. Как вы скажете о том, что:
— нельзя разводить костёр в лесу в ветреный день;
— после отдыха в лесу нельзя оставлять мусор;
— нельзя ломать деревья;
— нельзя загрязнять воду разными ядовитыми веществами?

8. Рәсемнәрне чагыштырыгыз. Табигатькә ике төрле караш рәсемнәрдә ничек бирелгән?

Беренче рәсемгә карагыз.
1)Рәсемдә нинди ел фасылы?
2)Балалар кайда ял иттеләр?
3)Алар хәзер нишлиләр?
4)Синеңчә, бу балалар нинди?
5)Алар туган якның табигатен саклыйлармы?
Беренче рәсем буенча кыскача сөйлибез, нәтиҗә ясыйбыз

Ә хәзер, **икенче** рәсемгә карыйк:
1) Рәсемдә нинди ел фасылы?
2) Елга буенда нинди кешеләр ял иткәннәр?
3) Ни өчен син шулай уйлыйсың? ( Алар чүпне җыймаганнар, учакны сүндермәгәннәр)
4) Алар туган якның табигатен яраталармы? саклыйлармы?
Икенче рәсем бунча кыскача сөйлибез, нәтиҗә ясыйбыз.

**IV. Сөйләм ситуациясенә караган репликаларны язу.**

(Дәреслек буенча эш, 66 нчы бит, №7).
- Җилле көнне урманда учак яндырырга ярамый
- Ял иткәннән соң урманда чүпне калдырырга ярамый
- Агачларны сындырырга ярамый
- Суны агулы матдәләр белән пычратырга ярамый

**V. Лексик-грамматик күнекмәләр**

Бүген текстларда бик күп сыйфатлар очраттык, хәзер сыйфатларның ясалышын искә тешерәбез: (презентация)

**Сыйфатларның ясалышы. (Образование имён прилагательных.)**

| | |
|---|---|
| **1.** Тамыр сыйфатлар (корневые прилагат.) | яшел (зелёный), матур (красивый) |
| **2.** Ясалма сыйфатлар (производные прилагательные) | **-лы/-ле**: яңгыр**лы** (дождливый), бәхет**ле** (счастливый)<br>**-гы/-ге**: борын**гы** (древний), көз**ге** (осенний)<br>**-кы/-ке**: кыш**кы** (зимний), кич**ке** (вечерний)<br>**-сыз/-сез**: болыт**сыз** (безоблачный), тәм**сез** (невкусный)<br>**-чан/-чән**: уй**чан** (задумчивый), эш**чән** (трудолюбивый)<br>**-и/-ви**: тарих**и** (исторический), тәрбия**ви** (воспитательный)<br>**-чыл/-чел**: сак**чыл** (бережливый), ярдәм**чел** (отзывчивый)<br>**-дагы/-дәге**: урман**дагы** йорт (дом, находящийся в лесу)<br>**-тагы/-тәге**: мәктәп**тәге** хәлләр (школьные события) |
| **3.** Парлы сыйфатлар (парные прилагат.) | аллы-гөлле (разноцветный)<br>осчыз-кырыйсыз (бескрайний) |
| **4.** Кушма сыйфатлар (сложные прилагат.) | үзсүзле (упрямый)<br>халыкара (международный) |
| **5.** Тезмә сыйфатлар (составные прилагат.) | киң күңелле (добродушный) |

Сүзләрдә сызыклар урынына тиешле кушымчаларны ялгап языгыз..

1. Кешеләр (борын)________________заманнардан ук табигать серләренә төшенергә тырышканнар.

2..Безнең бабаларыбыз укый-яза белмәгәннәр, ләкин бик (эш)__________________ булганнар , табигать телен бик яхшы аңлаганнар.

3. Табигатьне өйрәнә торган (тәр)_______________________ фәннәр барлыкка килгән.

4. Тирә-ягыбызда бик күп (файда) _________________________ үсемлекләр бар.

5. (Урман )_____________________ һәр үсемлек, җәнлек, кош табигатькә ямь бирә.

6. Их, яратам да соң (кыш)____________________урманны!

7. Кыш ябалак-ябалак булып яуган карлары, дуамал бураннары, ( кар)___________________ рәсемнәре белән матур.

8. Табигатьне пычратучылар белән көрәшик, мәктәпләрдә (тәрбия)________________________ эш алып барыйк.

**VI. Проблема буенча яза белү күнекмәләре. Хат язу.**

Без дәрестә “Табигать» темасына сөйләштек, дустыгызга сораулар буенча хат язырга өйрәнәбез.

*Ә син яшәгән якның табигате нинди?*

*Сездә нинди табигый байлыклар бар?*

*Синеңчә, туган якның табигатен саклау өчен, нәрсәләр эшләргә кирәк?*

**VII.Рефлексөия**

**VIII.Өйгә эш:**

1.5 репликаны ятларга,

2.«Табигать” темасына хат язарга.

**VIII сыйныфта укучы рустелле балаларга - татар теле**

***Миниәхмәтова Альбина Равил кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 3 нче гимназиясенең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы:** Табигатьне саклау-һәр кешенең изге бурычы.

**Максат:**

1) Сүз байлыгын арттыру, сөйләм телен үстерү;

2) Логик фикерләү, иҗади эшләү сәләтен үстерү;

3) Табигатькә мәхәббәт һәм сак караш тәрбияләү, аның матурлыгын, байлыгын

күрә, аңлый белергә өйрәтү

**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, интерактив такта, презентация, сүзлекләр, биремле карточкалар.

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру**(уңай психологик халәт тудыру).

-Исәнмесез,укучылар! Кәефләрегез ничек? Елмаеп карагыз әле бер-берегезгә, барыгыз да нинди матур,күркәм. Бер-берегезгә карап,хәерле эш көннәре телик.

**II. Актуальләштерү**

-Укучылар,бүгенге дәресне минем матур шигырь юллары белән башлап җибәрәсе килә.

**Слайд№1.**

(табигать турында шигырь).

Таш, су, һава, урманнарны
Табигать дип атыйбыз.
Табигатьсез яшәп булмый,
Нигә соң сакламыйбыз?
Елгаларны пычратабыз,
Урманнарны кисәбез..
Чишмәләрне чистартмыйбыз,
Матурлыкны бозабыз.
“Табигатьне саклагыз!”-дип язган,
Лозунглар язып эләбез.
Ә үзебез шул язу янында,
Ашап-эчеп, чүпләп китәбез.
(автор Низамиева Л.К.).

-Бу шигырьдә нәрсә турында сүз бара?(шигырьдә табигать,табигатьнең күренешләре,табигатьне саклау турында сүз бара).

**III. Уку мәсъәләсен кую**

-Әйе,дөрес.Димәк,без бүген сезнең белән табигать турында, табигатьнең байлыклары турында,табигатьтән ничек файдалану турында сөйләшербез.

**Уку мәсъәләсен өлешләп чишү**

**1 нче бирем.**

-Ә хәзер төркемнәрдә эшләп алырбыз.Сезгә табигатьне саклау турында интервью бирергә кирәк.

**Слайд№2.(үрнәк сораулар)**

1.Нәрсә ул табигать?
2.Кеше табигатьтән нәрсәләр ала ?

3.Җир шарында  кешеләр нинди максат белән яшиләр?
4.Кешелек нинди куркыныч алдында тора?
5.Ни өчен табигатьне сакларга кирәк?

**Слайд№3.(көтелгән җавап)**

1)Табигать –ул безнең әйләнә-тирә.
2)Кеше үзенә кирәк –әйберләрне табигатьтән ала.
3)Җир шарында кешеләр табигатьне саклау максаты белән яшиләр.
4)Чөнки табигать төрле радиоактив матдәләр белән агулана,суларыбыз пычрана,үсемлекләр,җәнлекләр кимегәннән кими.
5)Кешеләр киләчәк турында,алдагы буыннар турында кайгыртырга тиеш.
(укытучы берничә парның җавапларын тыңлый).

**2 нче бирем.**

Дәреслектәге текст өстендә эш.

-Укучылар,дәреслекләрне ачабыз.Табигать турында текстны үзлектән укыйбыз.Бу текст сезгә өйгә бирелгән иде.Без тексттагы сүзләр белән танышып,аның эчтәлеге өстендә эшләдек.

**Слайд№4.(дәреслектәге текст).**

Син-табигать баласы. Табигать-синең әйләнә-тирәңул.Кояш,болыт,су,ком,таш,хайваннар һәм үсемлекләр-барысы бергә табигать дип атала.Кеше үзенә кирәк әйберне табигатьтән ала.Иген,яшелчә һәм җиләк-җимешләр үстерә,терлек үрчетә.

Җир астыннан казылма байлыклар чыгаралар.Елга һәм күлләрдән балык тоталар.Урман-кырлардан гөмбә һәм җиләк җыялар.

Табигать бай,ләкин аны сакларга кирәк.Кешеләр киләчәк турында кайгыртырга тиешләр.Җир шарында барлык кешеләр дә гасырлар буе уртак бер максат белән яшиләр:ул-табигатьне саклау!

Кызганычка каршы,бүген кешелек зур куркыныч астында тора.Табигать төрле зарарлы радиоактив матдәләр белән агулана,суларыбыз пычрана,үсемлекләр,җәнлекләр саны кими.Табигатьне пычрату-гасыр чире ул.Табигатьне пычратучыларга каршы көрәшү-һәркемнең изге бурычы.

**Слайд№5.(туры килә-туры килми)**

Текстка туры килгәнен сайлыйбыз..

**А1.Без урман-кырлардан гөмбә һәм җиләк җыябыз.**

*1) Туры килә.* *2)Туры килми.*

**А2.Бәйрәмне үткәрү өчен сайланган урын мәйдан дип атала.**

*1) Туры килә.* *2)Туры килми.*

**А3.Безнең максатыбыз –табигатьне саклау!**

*1) Туры килә.* *2)Туры килми.*

**А4.Кешеләр табигатьне саклау максаты белән яшәмиләр.**

*1) Туры килә.* *2)Туры килми.*

**А5.Табигать  безне туендыра, киендерә.**

*1) Туры килә.* *2)Туры килми.*

**А6.Безнең табигатебез бик ярлы.**

*1) Туры килә.* *2)Туры килми.*

**А7.Табигатьне пычратучыларга каршы көрәшергә кирәк.**

*1) Туры килә.* *2)Туры килми.*

**А8.Җир астындагы казылма байлыклар чыгаруны туктаттылар.**

*1) Туры килә.* *2)Туры килми.*

**А9.Бу үсемлекләр һәм җәнлекләр Кызыл китапка кертелгән.**

*1) Туры килә.* *2)Туры килми.*

**А10.Без табигатьтән ничек телибез,шулай файдалана алабыз.**

*1) Туры килә.* *2)Туры килми.*

**А11.Урмандагы чүп-чарлардан янгын чыгарга мөмкин.**

*1) Туры килә.* *2)Туры килми.*

(җөмләләрне укучылар укыйлар,текстка туры килүе,килмәве турында әйтәләр).

**3 нче бирем**.Дәреслек белән эш.

(Бирелгән сүзләр һәм сүзтезмәләр белән җөмләләр төзибез.

**Слайд№6.(сүзләр һәм сүзтезмәләр)**

*Кеше балык тоталар.*

*Җир астыннан үзенә кирәк әйберләрне табигатьтән ала.*

*Елгалардан казылма байлыклар чыгаралар.*

*Кешелек изге бурыч.*

*Табигатьне саклау агарлы матдәләр белән агулана.*

*Табигать зур куркыныч алдында тора.*

***4нче бирем.***Ситуатив күнегүләр өстендә эш.

-Укучылар,сезгә ситуатив репликалар бирелә, җавапларын дәфтәрләрегезгә язабыз.

***Слайд№7.*(ситуатив күнегүләр)**

-*Спросите у друга (подруги)есть ли у него (у нее) книга о природе.*

-*Предложи другу (подруге) пойти в субботу в лес.*

-*Поинтересуйся у старшего брата, какие полезные ископаемые он находил в экспедиции.*

-*Подтвердите, что природу нужно беречь.*

-*Посоветуйте другу (подруге) не загрязнять природу.*

**Слайд№8.(көтелгән җавап)**

-Дустым,синең табигать турында китабың бармы?

-Дустым,әйдә, шимбә көнне урманга барабыз.

-Абыем,син экспедициядә нинди файдалы казылмалар таптың?

-Табигатьне сакларга кирәк.

-Дустым,табигатьне пычратма!

**Рефлексия**

-Ә хәзер дәресебезне йомгаклыйбыз.Димәк,без бүген сезнең белән нәрсәләр турында сөйләштек?

Көтелгән җавап: табигатьне саклау турында,табигатьтән дөрес файдалану турында,кешеләрнең изге бурычы турында сөйләштек.

-Дөрес,укучылар.Табигать –безнең йортыбыз!Табигатебезне кыерсытмагыз.Табигатьне саклау-һәр кешенең изге бурычы.

**Билгеләр кую**

**Өй эше**

*1)"Табигатьне саклау" темасына монолог төзергә.*

*2)Хат язарга.*

Сез татар дустыгыздан хат алдыгыз.Сорауларына җавап биреп,аңа хат языгыз.Язма эшегез 80 сүздән торырга тиеш.

*...Һәр кеше туган ягының табигатенә гашыйк була.Мин дә туган ягымның урманнарына,күлләренә,чишмәләренә сокланам.Җәйләрен без табигать кочагында ял итәргә яратабыз.*

*...Ә син яшәгән якның табигате нинди ?Сездә нинди табигый байлыклар бар?Синеңчә,туган якның табигатен саклау өчен,нәрсәләр эшләргә кирәк? (укытучы үрнәк хат укып күрсәтә).*

***Слайд№9* (Үрнәк хат укыла.)**

***Бирем.Сез татар дустыгыздан хат алдыгыз.Шушы сорауларга җавап биреп,аңа хат языгыз. Язма эшегез 70-80 сүздән торырга тиеш.***

*Җәй көне без гаиләбез белән диңгездә ял итәргә яратабыз.Анда су коенабыз,кояшта кызынабыз,экскурсияләргә йөрибез.*

*Җәйге каникулны ничек уздырасың?Гаиләгез белән кайда ял итәсез?Җәен нишләргә яратасың?*

*Исәнме,дустым__________________!Сиңа күп сәламнәр белән дустың __________ хат яза.*

*Әти-әниеңә, дусларыңа миннән сәлам әйт.Дустым,мин синең хатыңны алдым,бик зур рәхмәт сиңа!*

*Без җәй көне гаиләбез белән авылда ял итәбез .Анда табигать шундый матур:урман да,елга да бар.Мин дуслар белән балык тотарга яратам.Көн саен дуслар белән су коенабыз ,кояшта кызынабыз,футбол,бадминтон уйныйбыз.*

*Җәен көннәр бик эссе була.Без бабай белән урманга йөрибез.Анда салкынча.Без җир җиләге ,шомырт,гөмбәләр җыябыз.Мин әбиемә бакчада эшләргә булышам:су сибәм,яшелчәләр җыям.*

*Августта мин лагерьда булдым .Анда яңа дуслар белән аралаштым,кичәләрдә катнаштым,экскурсияләргә йөрдем.Җәй-минем яраткан ел фасылым.*

*Дустым_____________үзеңнең хәлләрең ничек?Мәктәптә нинди яңалыклар бар?*

*Барысы турында да яз,мин синнән хат көтәм.*

*Сагынып,дустың_________________ .*

*25 нче май, 2016 нчы ел.*

# IX сыйныфта укучы рустелле балаларга - татар теле

***Халитова Ләйсән Хәмит кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 3 нче гимназиясенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы:** Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый (хат язу)
**Максат:** Хат язуның төрләрен, аның кагыйдәләрен үзләштерү өчен шартлар булдыру. Фикерләү, хәтер сәлатләрен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Хат язу культурасын тәрбияләү.
**Җиһазлау**. Компьютер, проектор , хат үрнәкләре.

**Дәрес барышы.**
**I. Мотивлаштыру**
А) дәресне оештыру
Б) уку мәсьәләсен кую
*Саф мәхәббәт белән язган хатның*
*Йөрәкләргә дәрт һәм көч бирә.*
*Дошманнарга каршы ут ачырга*
*Җитмәс иде безнең көч кенә.* Р.Мифтахов
*Укытучы* .Укучылар, бу шигырь нәрсә турында (җавап бирәләр)
- Димәк, бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез? (җавап)
**II. Уку мәсьәләсен этаплап чишү**
*Укытучы* .Бөек ватан сугышы беркемне дә , бернәрсәне дә читләтеп узмады. Якыннарын сугышка озаткан әбиләр, әниләр, апалар фронттан хәбәр көткәннәр. Безнең туганнарыбыз да сугышта катнашкан.
*Укытучы* .Сугышта катнашкан туганнарыгыз турында нәрсә беләсез?
(укучылар җавап бирәләр)
*Укытучы* .Әйтегез әле, фронттагы солдатлар, туганнары белән ничек аралашканнар? (җавап)
*Укытучы* .Сез ничек уйлыйсыз? Нәрсә соң ул хат?
**Слайд1.** *Көтелгән җавап:* хат тормышта бик еш очрый торган эш кәгазьләренең берсе. Ул учреждениеләр, оешмалар, аерым шәхесләр арасында аралашу чарасы һәм мәгълүмат алмашуның киң таралган юлы. Ул текстны тапшыру ысулы белән аерылып тора, ягъни почта аша җибәрелә.
**Сораулар**
1. Хат ни өчен кирәк?
2. Сез үзегез хатлар язасызмы?
3. Хатны кемнәргә язып була?
4. Хатлар кемнән килә?
5. Ни өчен без хатларны сирәк язабыз? (Төрле фикерләр әйтелә.)

*Укытучы* .Хат язарга вакытым юк, дигән сүзләр бер дә дөрес түгел. Телевизор карау вакытын киметеп, кулыңа ак бит алып, якын кешеләргә хат язарга була. Хат туганнарга гына язылмый. Хатның берничә төрен алырга була.

**Слайд 2. Хат төрләре:**

1. Шәхси хатлар.
2. Мәхәббәт хатлары
3. Эш хаты
4. Тәкъдим хаты
5. Җавап хаты
6. Кайгы уртаклашу хаты
7. Котлау хаты.
8. Фронт хатлары

*Укытучы. Сез* ничек уйлыйсыз,фронттагы солдатлар хатларында нәрсә турында язганнар? (җавап)

*Укытучы*.Ә хәзер үрнәк итеп бабамның әбиемә язган хатын укыйсым килә.

“ *Исәнмесез, минем кадерлеләрем! Барыгызга да миннән сагынып сәлам. Бу минутта исән-сау. Өскә минут саен бомба, снаряд явып тора. Ашарыгызга бармы? Икмәк бирәләрме? Балаларны ач тотма, ачлыктан да начар нәрсә юк. Мичкә ягарга утын әзерли алдыгызмы? Балаларны һәм үзеңне сакла. Күп яза алмыйм, вакыт тар, сугышка керәбез. Сезне сагынып әтиегез.”*

*Укытучы*. Фронттан килгән хатлар кыска эчтәлекле булган. Бу хатларда үзләренең исәнлекләрен генә белдергәннәркыска хәбәрләр генә язганнар.

*Укытучы*.Әйдәгез әле, хат язу формасын искә төшерик.

**Слайд 3.**



*Укытучы.*Шуны истә тотарга кирәк, хатның эчтәлегендә нинди вакыйгалар, яңалыклар турында сүз барса да, логик эзлеклелек булырга тиеш.
- Ә хәзер без сезнең белән кечкенә генә хат язып карыйк. Дустыгызга сугышта катнашкан туганыгыз турында языгыз. (укучыларның җаваплары)

**Слайд 4. Хат язуга кайбер киңәшләр**

*1. Язуыгыз ачык, аңлаешлы, пөхтә булырга тиеш. "Ашыгып язам, шуңа күрә язуым ямьсез" дигән сүзләр килешле булмас.*

*2. Орфографик хаталар белән язылган хатны җибәрү бер дә матур булмас. Шуңа күрә, сүзлек белән эш итәргә кирәк.*

*3. Кәефегез начар булса, хат язудан тыелып торыгыз.*

*Әгәр шәхси хат компьютерда бастырылган булса да, имзаны үз кулың белән куярга кирәк.*

**III. Рефлексия**

*Укытучы*. хат язу бердә җиңел эш түгел. Без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләштек?

**IV.Өй эше:Хат язарга**

*... Мин әдәбият белән тарихтан имтиханга әзерләнәм... Имтиханнарны яхшы тапшыру өчен, күп белергә кирәк.*

*Син кайсы фәннәрдән имтихан бирәчәксең? Сиңа телдән имтихан тапшыру ошыймы яки язмачамы? Син имтиханнарга ничек әзерләнәсең?*

**V. Актив эшләгән укучыларга билге куела**

## IX сыйныфта укучы рустелле балаларга - татар теле

***Якупова Римма Мансур кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 3 нче гимназиясенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы:**Сәламәтлек- зур байлык.

**Укытучының планлаштырылган нәтиҗәләре:**

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр**:

- Сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш тәрбияләү.

**Метапредмет нәтиҗәләр**:

***Регулятив УУГ***

- Ихтыяр көче, максатсатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру.
- Укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү.
- Эш сыйфатына бәя бирә белү.
- Нәтиҗә ясый алу.
- Билгеле күрсәтмә нигезендә эшли белү, нәтиҗә ясый алу

***Танып белү УУГ***

- Аңлап уку, тиешле мәгълүматны сайлап алу
- Текста әйтелә торган төп фикерне таба белү
- Объектларны чагыштыру.
- Фикерне логик чылбырга салу.

***Коммуникатив УУГ***

- Диалог төзүдә катнашу.
- Фикерне дәлилли итеп җиткерә белү
- Мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару

**Предмет нәтиҗәләре:** "Сәламәтлек" темасы буенча яңа сүзләр белән таныштырып, укучыларның сүз байлыгын арттыру. Өйрәнелгән лексиканы, грамматик конструкцияләрне кулланышка кертеп, җөмлә төзү үзенчәлекләрен үзләштерүне дәвам итү. Коммуникатив биремнәр эшләү, сорауларга җавап бирү өстендә эшләү. Диалогик, монологик сөйләм булдыру. Имтиханга әзерләү

**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, интерактив такта, презентация, сүзлекләр, биремле карточкалар.

**Дәрес барышы.**

**1.Оештыру этабы** (психологик уңай халәт тудыру ).Исәнләшү.

*Укытучы.*Укучылар, кәефегез ничек? Бүген көн нинди? Сезгә ошыймы? Мин сезгә дәрестә уңышлар телим.

**2. Белемнәрне актуальләштерү. (Укучыларның терәк белемнәрен яңадан барлау һәм төзәтмәләр кертү).**

а)Слайдта сүзләр язылган. Укытучы шул сүзләрнең тәрҗемәсен сорый, балаларның җавапларын тыңлана.

(Сәламәтлек. Сәламәт булыгыз! Авырмыйсызмы? Сәламәт булу өчен нишләргә кирәк?)

*Укытучы*.Укучылар, ни өчен сәламәт булырга кирәк?

*Балалар.*Уку өчен,яшәү өчен, имтихан бирү өчен...

*Укытучы.*Дөрес,сәламәтлек –зур байлык, ул һәрвакыт кирәк. Быел сезгә имтихан бирергә кирәк, һөнәр сайларга кирәк. Әйдәгез "Һөнәрләр" темасын искә төшереп китик әле. ("Һөнәр" темасы алдан өйрәнелгән ).

б) Диалог. "Һөнәр сайлау".

-Син киләчәктә кем булырга телисең?

-Мин киләчәктә табиб (укытучы...) булырга телим.

- Ни өчен табиб булырга телисең?

-Чөнки мин кешеләрнең сәламәт булуын телим.

*Укытучы* .Менә шулай, дөрес һөнәр сайлап эшләр өчен дә сәламәтлек кирәк.
Димәк, дәрестә нәрсә турында сөйләшербез?

**3.Уку мәсьәләсен кую. (Укучыларда уку эшчәнлеген мотивлаштыру.**

*Укытучы.*Сәламәтлек турында сөйләшербез. Сәламәт булу өчен нишләргә кирәк?

Китап буенча 79 нчы биттән уку, 3 нче күнегү

Бегать по утрам, умываться холодной водой, делать зарядку...

**Методик күрсәтмәләр: Методик күрсәтмәләр аша элек алган белемнәрен кullланып, чагыштырып хәзерге биремнәрне эшлиләр.**
***Слайд.*** Инфинитив, аның кушымчалары : –ырга, -ергә....
-Иртән йөгерергә, салкын су белән юынырга, зарядка ясарга...
*Укытучы* .Сәламәт булу өчен син нишлисең?
***Слайд.***Инфинитив кушымчаларын алып, хәзерге заман –а, -ә, -ый,-и кушымчалары куела.
*Укытучы* .Димәк, сәламәт булу өчен нәрсә файдалы яки зарарлы?
***Слайд.***
- Дөрес туклану;
- Дөрес йоклау;
- Спорт белән шөгыльләнү;

**Коммуникатив биремнәр эшләү**.(карточкалар)
Укытучы.
- Спроси у друга о его здоровье.
- Пригласи сестру купаться на озере.
- Спроси старшего брата, какими видами спорта он занимался в школе.
- Поинтересуйся, любит ли твой друг играть в теннис.
- Спросите у прохожего где находится стадион "Авангард"(или городская больница).

**Методик күрсәтмәләр:**
***Слайд***.
1. Башта эндәш сүзләрне табу. (Дустым; апа; абый; Гафу итегез, әйтегез әле).
2.Сорауларны табу. (Ничек?, нинди?,-мы/-ме, кайда?,).
3.Фигыльләр җөмләне, ахырында килә.
4.Чакыру-без/-без кушымчалары кую.
***Слайд***.Дөрес җавап (үзтикшерү)
-Дустым, синең сәламәтлегең ничек?
-Апа, әйдә күлдә су коенабыз.
-Абый, син мәктәптә нинди спорт төре белән шөгыльләндең?
-Дустым, син теннис уйнарга яратасыңмы?
-Гафу итегез, әйтегез әле "Авангард"стадионы кайда урнашкан?
***Таныш ситуациядә (типлаштырылган бирем)***
**Текст өстендә эш.**
*Укытучы* .Текстка керешкәнче, яңа сүзләрне искә төшерик:
Тукланырга-питаться
Таләп-требование
Даими-постоянно
Җилләтергә-проветривать
Чыныктыру-закаливание
Истә тотарга- помнить

**Сәламәтлек- зур байлык.**

Сәламәт булу өчен, һәркем тырышырга тиеш. Сәламәт булырга теләсәң, иң беренче чиратта, **яхшы тукланырга кирәк.** Ашый торган ризыкта витаминнар булуы бик мөһим. Шуңа күрә кешеләр ит тә, сөт ашамлыклары да, яшелчәләр дә, җиләк-җимеш тә ашарга тиеш. Ләкин һәр ризыкны норма белән генә ашау яхшы.

Көндәлек гигиена таләпләрен үтәү дә бик әһәмиятле: иртән физик күнегүләр ясарга, ашаганнан соң тешләрне чистартырга, өс һәм аяк киемнәренең чисталыгын сакларга, бүлмәне **даими чиста тотарга** һәм **җилләтергә,** атнага 2-3 тапкыр физкультура һәм спорт белән шөгыльләнергә, саф һавада күбрәк булырга кирәк. **Үзеңне чыныктыру да мөһим эш** булып санала. Мәсәлән, салкын су белән коену бик файдалы.

Кышын да, җәен дә көн саен саф һавада йөрү яки йөгерү кеше организмына файда китерә. Җәен су коеныргa, йөзәргә,көймәдә йөрергә, урманга барырга, футбол яки бадминтон уйнарга мөмкин. Ә кышын тимераякта, чаңгыда, чанада шуу, хоккей уйнау бик файдалы.

Шуны да истә тотыгыз: **сәламәтлегегезне сакларга теләсәгез,** тәмәке тартмаска, аракы эчмәскә, начар кешеләр белән аралашмаска. Стрессларга бирешмәскә кирәк.

**Сәламәтлек- зур байлык ул.** Сәламәт тәндә-сәламәт акыл диләр.

*Укытучы.*Хәзер текстны бер кат үзегез укып чыгабыз.(укучылар укый)

**Тексттан табабыз**:

-надо хорошо питаться, постоянно держать в чистоте, проветривать, очень важно себя закаливать, если хотите беречь здоровье, здоровье-это главное богатство.

-Имтиханда сезгә хат язарга кирәк булачак. Хатның башын һәм ахырын искә төшерик әле. (ике бала сөйли). Хатның уртасында сораулар, сорауларга төгәл җавап бирергә кирәк.

-Хәзер текст буенча сорауларга җавап бирегез, калын хәрефләр белән бирелгән методик күрсәтмәләргә игътибар итегез.(Сораулар карточкада)

-Синеңчә текст нәрсә турында?

Көтелгән җавап: **Минемчә,..**

- Сәламәт булу өчен иң беренче нишләргә кирәк?
- Нинди ризыклар файдалы? **Баллы,майлы, төрле, мәсәлән**
- Сәламәт булу өчен кышын нишләргә кирәк? **Нишләргә?(–ырга/-ергә кушымчалары)**
- Ә җәен нишләргә кирәк?
- Сәламәт булу өчен нишләмәскә кирәк**?**

Көтелгән җавап: **ятып укымаска, тәмәке тартмаска.**

**Үзгәртелгән ситуациядә (конструктив бирем)**

*Диалог төзү.**Спорт безнең тормышыбызда.*** (диалог төзибез һәм парларда сөйләшәбез)

-Син спорт яратасыңмы?

-Сиңа нинди спорт төре ошый?

-Әтиең нинди спорт төре белән шөгыльләнә?һ.б.

**Белемнәрне яна ситуацидә иҗади куллану(проблемалы биремнәр).**
1.Позвоните своему другу в больницу и спросите. Как он себя чувствует. В какой палате он лежит. Как его лечат.
2. Позвони в школу и скажи, что у тебя болит голова и ты не придешь, а пойдешь в поликлинику.
3. Вы пришли в аптеку.Попросите у аптекаря лекарство.
4. Вызовите врача на дом.
5. Два друга встретились на улице.Один из них курит. Друг ему объясняет о вреде курения.
**Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү.**
Үзегезгә ошаган спорт төре турында 8-10 җөмләле хикәя төзеп килергә.
Уку әсбабы буенча 9 нчы вариантны эшләргә.
**Рефлексия.**Дәрестә нишләдек?
-Кагыйдәләрне искә төшәердек, коммуникатив биремнәр эшләдек, сорауларга җавап бирдек, сәламәтлек турында сөйләштек, имтиханга әзерләндек.
**Билгеләр кую.Үзбилге.**

## IX сыйныфта укучы татарбалаларына -татар теле

***Сибгатуллина Фирая Фаһим кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 3 нче гимназиясенең***
***югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы:** Сүз төркемнәрен гомумиләштереп кабатлау.

**Максат:**
1) укучыларның сүз төркемнәре буенча алган белемнәрен тикшерү, БРТга әзерлек күнекмәләре формалаштыру;
2) Өйрәнгәннәрне гамәлдә куллана белү, фикерләү сәләтен үстерү
3) Әниләргә карата хөрмәт, миһербанлылык хисләре тәрбияләү.
**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, интерактив такта, презентация, сүзлекләр, биремле карточкалар.
**Дәрес тибы:** кабатлау дәресе
**Методлар :** әңгәмә, өлешчә эзләнү
**Дәрес барышы:**
**I. Мотивлаштыру.**
Дәрескә әзерлекне тикшерү.

***Слайд.***Эпиграф. “Тышкы матурлык белән мактанма, эчке матурлык белән мактан”
Дәресебезне шушы матур сүзләрдән башлап җибәрик әле.
- бу мәкаль нәрсә турында?
(Укучыларның фикере тыңланыла)

**II. Уку максатын кую.**

- Тактада язылган кагыйдәне карап китик әле.

Мәгънәләре, грамматик билгеләре һәм җөмләдә кулланылышы буенча бер төркемгә берләшкән сүзләр ... дип атала.

- Монда нинди сүз төшеп калган? (сүз төркемнәре)
- Бүгенге дәресебезнең темасы “Сүз төркемнәрен гомумиләштереп кабатлау”. Без сезнең белән һәр сүз төркемен карап киткән идек. Ә бүген гомумиләштереп кабатлыйбыз. Әйдәгез, дәресебезгә бергәләп максат куйыйк әле. Бүгенге дәрестә без нишләргә тиеш? (Укучылар дәрескә максат куялар)

Максат:
-сүз төркемнәрен искә төшерү, кабатлау;
- БРТ биремнәре буенча сүз төркемнәрен тексттан таба белү.

**III. Уку максатын чишү.**

а) - нәрсә ул сүз төркемнәре?
- сүз төркемнәрен нинди төрләргә бүлеп өйрәнәләр? (слайдта сүз төркемнәренең төрләргә бүленеш схемасы күрсәтелә.)
б) Укучылар, сезнең алдыгызда “Матурлык”тексты ята. Әйдәгез, укып чыгыйк әле. (бер-ике укчы чиратлап укып чыга).

## Матурлык

(1) **Бер-ике** көй уйнагач, Бәдретдин, ниһаять, әнисенә дәште.
(2) - Әнкәй, сиңа нәрсә уйныйм?
(3)Әнисе бер мәлгә балаларча кызарып, шул ук вакытта куанычыннан тагы да балкыбрак китте, ләкин кайтарып сүз әйтә алмады.
(4) - Әнкәй <....> син шушы көйне ярата идең бит! — диде Бәдретдин һәм «Салкын чишмә»не уйный башлады. (5) Ул, берәүне дә күрмичә, бары әнисенә, аның йөзенә генә карап, скрипкәсен уйнады. (6) Аның җылы карашында, әнисен өзелеп ярату гына түгел, аны аңлау, кадерләү, юату сизелеп тора кебек иде.(7) Белмим, болай карый алыр өчен, күңелләрдә нинди генә тирән мәхәббәт дәрьясы ятарга тиештер инде?! (8) Әллә бу шулай бик ямьсез ана белән бик матур бала яки, киресенчә, бик матур ана белән бик ямьсез бала арасында гына буламы икән? (9) Соңгысы, ихтимал, еш очрый торгандыр, әмма беренчесен ишеткән дә, күргән дә юк иде.

(10) Шулай да безгә кузгалырга вакыт иде инде. (11) Бәдретдин уйнап туктагач, без хуҗалардан дога кылырг арөхсәт сорадык....
(12) Кояш баюга таба борылган иде инде. (13) Ә шулай да тургайлар, көн яктысыннан туя белмәгәндәй, тагын да биеккәрәк менеп,

берөзлексез сайрыйлар да сайрыйлар. (14) Дөнья киң, киң, киң, әләләләләүү! (15) Җире-күге тын, буш, моңсу, бик моңсу миңа!.. (16) Берни эшли алмыйм үзем белән: самавыр артыннан гына улына карап утырган ана күз алдыма килә дә, эчемнән тагын үкси башлыйм... (17) Кемгәдер йодрык селкеп кычкырасым килә. (18) Ямьсез түгел бит ул, матур бит ул, матур, матур Бәдретдиннең әнисе!

(Ә. Еникидән)

- бу текст нәрсә турында? (укучылырның фикерләре тыңланыла)
- хәзер бирелгән биремнәрне үтибез.
1-2 нче сораулар текстның эчтәлеген аңлауны тикшерү өчен бирелә.

**1.** Кайсы мәгълүмат түбәндәге сорауга җавап була ала?
*Бәдретдиннең әнисенә булган мөнәсәбәте нинди?*
1) Әнкәй, син шушы көйне ярата идең бит.
2) Әнисе бер мәлгә балаларча кызарып китте.
3) Карашында әнисен аңлау, кадерләү, юату сизелеп тора.
4) Кемгәдер йодрык селкеп кычкырасым килә.
Җавап: ______________________________________________.

***2.*** *Малайлар нәрсәне аңлыйлар?.*
1) Тургайлар берөзлексез сайрыйлар да сайрыйлар.
2) Безгә кузгалырга вакыт иде.
3) Матур бит ул, матур Бәдретдиннең әнисе!
4) Кояш баюга таба борылган иде инде.
Җавап: ______________________________________________.

**3.** 5 нче җөмләдә ничә исем булганын цифр белән языгыз.
Җавап: ______________________________________________.

- исем нәрсә соң ул? (укучылар фикере тыңланыла)
**Нәтиҗә:** Слайдта кагыйдәсе чыга.
**4.** 11 нче җөмләдән **алмашлыкны** табып языгыз.
Җавап: ______________________________________________.
- Нәрсә ул алмашлык? (укучылар фикере тыңланыла)
**Нәтиҗә:** Слайдта кагыйдәсе чыга
**5.** 8-9 нчы җөмләләр арасыннан **матур** сүзенә **синоним** булган берәмлекне табып языгыз.
Җавап: ______________________________________________.
- Нәрсә ул сыйфат? (укучылар фикере тыңланыла)
**Нәтиҗә:** Слайдта кагыйдәсе чыга
**6.** 1 нче җөмләдә билгеләнгән сүзнең сүз төркемен билгеләгез.
Җавап: ______________________________________________.
- Нәрсә ул сан? (укучылар фикере тыңланыла)
Нәтиҗә: Слайдта кагыйдәсе чыга

**7.** Калын хәрефләр белән бирелгән **фигыльнең төрен** языгыз.
***Белмим**, болай карый алыр өчен, күңелләрдә нинди генә тирән мәхәббәт дәрьясы ятарга тиештер инде?!*

Җавап: ________________________________________________.

- Нәрсә ул фигыл? (укучылар фикере тыңланыла)

**Нәтиҗә:** Слайдта кагыйдәсе чыга.

**8.** 10-12 нче җөмләләр арасыннан хәл фигыль кулланылган җөмләнең номерын языгыз.

Җавап: ________________________________________________.

- Нәрсә ул алмашлык? (укучылар фикере тыңланыла)

**Нәтиҗә:** Слайдта кагыйдәсе чыга.

***9.*** 9 нчы җөмләдән рәвешне табып языгыз.

Җавап: ________________________________________________.

- Нәрсә ул алмашлык? (укучылар фикере тыңланыла)

**Нәтиҗә:** Слайдта кагыйдәсе чыга.

Сүз төркемнәре турында гомуми нәтиҗә ясала.

**IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту.**

- Без сезнең белән сүз төркемнәрен карап киттек. Хәзер төркемнәргә бүленәбез. Мәкальдән һәр төркемгә берәр сүз бирелә. Алар морфологик анализ ясыйлар. (эш үзара тикшерелә, бәяләнә)

**V. Рефлексия.**

а) - без бүген дәрестә нишләдек, нәрсәләр белдек?

- максатыбызга ирештекме?

- бүгенге дәрестә алган белемнәребезне киләчәктә кайда куллана алабыз? (БРТ биргәндә)

б) Билгеләр кую.

**VI. Өй эше.**

Ике теманың берсенә сочинение язарга.

**21.1. Анын җылы карашында, әнисен өзелеп ярату гына түгел, аны аңлау, кадерләү, юату сизелеп тора кебек иде. Белмим, болай карый алыр өчен, күңелләрдә нинди генә тирән мәхәббәт дәрьясы ятарга тиештер инде?!** Текста китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган 2 дәлил китерегез. Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме 100 сүздән ким булмаска тиеш. Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**21.2 Матурлык** сүзен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **“Матурлык”** темасына сочинение языгыз. Тезисыгызны раслый торган 2 дәлил китерегез: дәлилнең берсен укылган тексттан алыгыз, икенчесен тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Сочинениенең күләме 100 сүздән ким булмаска тиеш. Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

## IX сыйныфта укучы рустеллебалаларга -татар теле

***Минһаҗева Мәдинә Кәрим кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 3 нче гимназиясенең***
***милли белем бирү буенча директор урынбасары***
***Сабирзянова Ландыш Марс кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 3 нче гимназиясенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Тема:** “**Сәламәтлек – зур байлык**”
**Максат:**
1. “Сәламәтлек” темасына караган яңа сүзләр өйрәнү, аларны монологик һәм диалогик сөйләмдә куллана алуларына ирешү.
2. Инновацион технологияләр кулланып, укучыларның үз фикерләрен логик, эзлекле, җыйнак, төгәл, матур итеп сөйләргә һәм фикер йөртергә өйрәтү, аралашу культурасын һәм сөйләм телен үстерү. Өйрәнелгән лексиканы, грамматик конструкцияләрне кулланышка кертеп, сүз, җөмлә төзү үзенчәлекләрен үзләштерүне дәвам итү.
3. Яшь буында сәламәтлек культурасы, сәламәт яшәү рәвеше һәм актив тормыш позициясе тәрбияләү.

**Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре:**
**Шәхескә кагылышлы УУГ**
-укуга карата кызыксыну хисе; -укучы ролен үзләштерү; -нәтиҗәләргә үзанализ һәм үзконтроль
**Метапредмет нәтиҗәләр.**
***Регулятив УУГ***
-Укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;
-укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү
***Коммуникатив УУГ***
-башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
-парларда эшли белү
***Танып-белү УУГ***
-укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү
**Җиһазлау:** Уку өчен текстлар, компьютер, мультимедиа экраны, мультимедиа презентациясе.
**Дәрес тибы:** белем һәм күнекмәләрне системага салу, ныгыту дәресе
**Укыту методлары:** өлешчә эзләнү, гамәли

**Дәрес барышы.**
**I .Оештыру өлеше.**

-Исәнмесез,укучылар?
-...............
-Хәлләрегез ничек?
-..................
-Рәхмәт, минем дә хәлләрем бик яхшы. Дәресебезне башлыйбыз.

**II. Уку мәсьәләсен кую.**

-Укучылар, мин сезгә хәзер аудирование тыңлыйбыз, сез сүз нәрсә турында бара?

( Сәламәтлек турында аудирование тыңлау) ***АУДИО***

- Сәламәтлек турында.
- Дөрес. Без сезнең белән бүген димәк, нәрсә турында сөйләшәчәкбез?
- ...

СЛАЙД № 1

( дәреснең темасын, максатын билгеләү)

- Сәламәтлек өчен нәрсә файдалы, нәрсә зарарлы ?
- ...

СЛАЙД №2

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

а) –Мин сезгә сүзлек таратам. Сез аны дәрестә куллана аласыз.

| | |
|---|---|
| Дөнья | Мир |
| Бай | Богатый |
| Тормыш | Жизнь |
| Һәр | Каждый |
| Кеше | Человек |
| Җавап | Ответ |
| Җаваплы | Ответственный |
| Беренче чиратта | Первую очередь |
| Шөгыльләнергә | Заниматься |
| Төрле | Разный |
| Түгәрәк | Кружок |
| Җиңел | Легко |
| Йөгерергә | Бегать |
| Шуарга | Кататься |
| Саф | Свежий |
| Һава | Воздух |
| Су коенырга | Купаться |
| Кызынырга | Загорать |
| Акыл | Ум |
| Хезмәт | Труд |
| Аралаштырырга | Чередовать |
| Ял итү | Отдыхать |
| Дөрес | Правильно |

| | |
|---|---|
| Туклану | Питание |
| Күп | Много |
| Йокы алдыннан | Перед сном |
| Кыздырылган | Жареный |
| Май | Масло |
| Ризык | Еда |
| Киенү | Одеваться |
| Мөһим | Важно |
| Кием | Одежда |
| Кияргә | Одевать |
| Яланбаш | Без головного убора |
| Авыру | Болезнь |
| Исерткеч | Алкогольные |
| Эчемлекләр | Напитки |
| Тәмәке | Табак |
| Шарт | Условие |
| Саклый | Охраняет, бережет |

**(** Сүзләрне уку, сүзтезмәләр, җөмләләр төзү)

б) - Дәреслектәге “ Сәламәтлек-зур байлык” тексты белән танышабыз.( 80нче бит,№6)

( сәнгатьле уку, аңлау)

СЛАЙД №3

- Сәламәт булыр өчен нишләргә кирәк?

- ... .

в) - Хәзер” Сәламәлек- зур байлык” тексты буенча белемнәребезне тикшерәбез. Мин сезгә ОГЭ вариантына туры килгән текст һәм биремнәр таратам.

**( “Сәламәтлек- зур байлык ” тексты буенча)**

1) -Башта текст буенча эшлибез. Бу җөмләләр текстка туры киләме?

СЛАЙД №4

*А1. Халык: “Дөньяда иң зур байлык- исәнлек- саулык”, - ди.*

1. туры килә 2. туры килми

*А2. Сәламәт кеше үз тормышын яхшырта да, ял да итә ала.*

1. туры килә 2. туры килми

*А3. Сәламәт булу өчен спорт белән шөгыльләнергә кирәк.*

1. туры килә 2. туры килми

*А4. Иртән зарядка ясарга яки йөгерергә кирәкми.*

1. туры килә 2. туры килми

*А5. Көндәлек режимны сакларга, авыр эштән соң ял итәргә кирәк.*

1. туры килә 2. туры килми

*А6. Кыздырылган, майлы, баллы ризыкларны күбрәк, ә яшелчә, җиләк-җимешләрне азрак ашарга кирәк.*
1. туры килә 2. туры килми
*А7. Ел вакытына карап дөрес киенергә кирәк.*
1. туры килә 2. туры килми
*А8. Кыш көне яланбаш йөрергә, җиңел курткалар кияргә ярый.*
1. туры килә 2. туры килми
*А9. Сәламәтлекне саклау өчен, исерткеч эчемлекләр эчмәү, тәмәке тартмау – иң беренче шартлар.*
1. туры килә 2. туры килми
*А10. Һәр кеше сәламәтлеген үзе сакларга тиеш.*
1. туры килә 2. туры килми

2) - Дәвам итәбез! Текстка туры китереп, тиешле сүз ясагыч, килеш яисә заман кушымчаларын дөрес итеп уйлап язарга кирәк. Җөмләләр текстның эчтәлегенә туры килергә тиеш.

СЛАЙД №5

| | |
|---|---|
| В11. Һәр кеше үзенең сәламәтлеге өчен үзе ... | ҖАВАП |
| В12. Сәламәт кеше ... дә, тормышын да яхшырта, ял да итә. | ЭШЛӘРГӘ |
| В13. ... тимераякта яки чаңгыда шуарга кирәк. | КЫШ |
| В14. Җәен ... су коенырга, кояшта кызынырга була. | ЕЛГА |
| В15. Кыска җиңел курткалар кию ... авырулар китереп чыгара. | ТӨР |
| В16. ... яшелчә һәм җиләк-җимеш ашарга кирәк. | КҮП |
| В17. Әлбәттә, ... саклау өчен, исерткеч эчемлекләр эчмәү, тәмәке тартмау – иң беренче шартлар. | СӘЛАМӘТ |

СЛАЙД №6

(*Көтелгән җавап:* җаваплы, эшли, кышын, елгада, төрле, күбрәк, сәламәтлекне*тиешле кушымчалар куюны аңлату*)
3) - Укучылар, мин сезгә төрле ситуацияләр тәкъдим итәм, татарча әйтәбез.

СЛАЙД №7

*В18. Позвоните своему другу и спросите что надо делать, чтобы быть здоровым.*
*В19. Спроси у друга, делает ли он утром зарядку.*
*В20. Скажи другу, что правильное питание полезно для здоровья.*
*В21. Предложите другу зимой покататься на коньках или на лыжах.*
*В22. Посоветуйте своему другу, побольше есть овощей и фруктов.*
4) –Хәзер һәрберегез сәламәтлек белән кызыксынучы укучы буларак бер-берегез белән әңгәмә корабыз ( сөйләшәбез). Сорауларны тыңлагыз, игътибар белән аларга җавап бирәбез.

СЛАЙД №8

**Телдән җавап бирү**

- *Халык сәламәтлек турында нәрсә ди?*
- ...
- *Сәламәт булыр өчен нишләргә кирәк?*
- ...
- *Көндәлек режимны сакларга кирәкме?*
- ...
- *Йокы алдыннан нәрсәләр ашарга ярамый?*
- ...
- *Сәламәт булыр өчен ничек киенә белергә кирәк?*

**IV. Йомгаклау.**

- Укучылар без сезнең белән бүген нәрсә турында сөйләштек?

-. ..

- Сәламәт яшәү рәвеше нәрсә ул?

- ...

- Димәк, сәламәт яшәү өчен нәрсәләр файдалы?

СЛАЙД №9

• гимнастика
• зарядка
• спорт
• витамин
• аэробика
• көндәлек режим
• файдалы ризыклар
• җиләк-җимешләр
• яшелчәләр
• саф һава

- Нәрсәләр зарарлы?

СЛАЙД №10

*Көтелгән җавап:*

• компьютерда озак эшләү
• телевизор күп карау
• баллы ризыклар
• майлы ризыклар
• бактерия
• инфекция
• агрессия
• депрессия
• вирус
• стресс
• сыра
• тәмәке

- Сәламәт кеше нинди ул?

*Көтелгән җавап:*Көчле, җитез, акыллы, чиста күңелле, эшкә сәләтле, җаваплы,сәламәт, ярдәмчел.

**V.Өйгә эш бирү.Сайлап алабыз.**

1)“ Сәламәтлек” темасына хат язарга.

В23. Сез татар дустыгыздан хат алдыгыз. Шушы сорауларга җавап биреп, аңа хат языгыз. Язма эшегез 70 - 80 сүздән торырга тиеш.

. . . *Мин спорт белән кызыксынам. Дәресләрдән соң айкидо секциясенә йөрим. Минемчә, спорт белән шөгыльләнү сәламәтлек өчен файдалы.*

. . . *Син буш вакытыңда нәрсә белән шөгыльләнәсең? Сиңа спортның кайсы төре ошый? Спорт белән шөгыльләнү ни өчен кирәк?*

2) ситуатив күнегүләр уйлап язарга

3)дәрестә кулланган сүзлекне өйрәнергә

**VI. Рефлексия**.

-Хәзер һәрберегез үзебезгә бәя бирәбез. Сез бүгенге дәрестә ничек эшләдегез? Ничек катнаштыгыз? Үзегезгә ничәле куяр идегез?

Бүген барыгыз да дәрестә бик яхшы катнашты. Молодцы! Дәресебез бетте! Сау булыгыз.

## VI сыйныфтаукучы рус балаларына -татар теле

***Халитова Ләйсән Хәмит кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 3 нче гимназиясенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәреснең темасы:** Мин өйдә – булышчы.

**Максат:**

4. *Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):* Өйрәнелгән лексик-грамматик конструкцияләрне, фигыль формаларын сөйләмдә куллана белүне камилләштерү.

*Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):* Укучыларның сөйләм байлыгын арттыру, фикерләү мәләтен үстерү. Үзара аралаша белү *мөмкинлекләрен* үстерү. Үз хезмәтеңне бәяли белергә өйрәтү.

5. *Тәрбияви максат (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):* Эшчән, ярдәмчел булырга, әти-әниләргә, өлкәннәргә булышырга теләк уяту. Бер-береңә матур итеп эндәшә, матур сөйләшә белү күнекмәләрен үстерү.

**Укытучының планлаштырылган нәтиҗәләре.**
**Шәхси УУГ:**
- укуга карата кызыксыну хисе;
- укучы ролен үзләштерү;
- нәтиҗәләргә анализ һәм үзконтроль;

**Метапредмет нәтиҗәләр.**
**Регулятив УУГ:**
- укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү;
- укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү;

**Коммуникатив УУГ**
- иптәшләренең сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү;
- парларда эшли белү;

**Танып – белү УУГ:**
- укытучы биргән сорауларга дөрес һәм аңлаешлы җавап бирә, тиешле мәгълүматны таба белү.

**Җиһазлау:** дәреслек, компьютер, интерактив такта, презентация, сүзлекләр, биремле карточкалар.

**Дәрес барышы**
**X. Мотивлаштыру.**
***9. Дәресне оештыру (исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу)***
-Исәнмесез, укучылар!
- .......
- Хәлләрегез ничек?
-........
- Рәхмәт, минем дә хәлләрем бик яхшы. Дәресебезне башлыйбыз.

***10. Өй эшен тикшерү***
- Укучылар, сез бирелгән шарт фигыльләр белән җөмләләр төзергә тиеш идегез. *(җырласаң, биемәсә, көлсәк, бармасаң, яумаса, китсәгез, кайтмасам).* Әйдәгез, өй эшләрегезне тыңлап үтик.

***11. Уку мәсьәләсен кую.***
- Экрандагы шигырьләрне игътибар белән укыгыз. Бу шигырь нәрсә турында? *(Слайд 1)*

| | |
|---|---|
| Әни утыртты гөлләр<br>Алар үсә зур булып,<br>Утыралар ямь биреп,<br>Бөтен өебез тулып<br>Мин аларга су сибәм<br>Яки иртән. Я кичен, | Әни пәрәмәч пешерә<br>Вак итеп тәмле итеп<br>Без табында чөй эчәбез<br>Бергәләп, тәмле итеп<br>Мин дә булыштым әнигә<br>Пәрәмәчләр ясарга |

| | |
|---|---|
| Әниемә булышам<br>Эш аз булсын өчен. | Үзең эшләгәч тәмле ул<br>Кирәк эшләп ашарга |

Укытучы: - Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшүне дәвам итәбез.
- *Әнигә булышу турында.*
- Әйе, укучылар, без бүгенге дәрестә әнигә булышу турында сөйләшербез.

**XI. Уку мәсьәләсен чишү.**
- Укучылар, сез эти-әниегезгә ничек булышасыз? (үз җавапларын бирәләр)
- Ә хәзер тактага карагыз әле. Бу рәсемнәрдә малай нишли? *(Слайд 2)*



***Укучылардан көтелгән җаваплар:***
- *Малай идән суырта.*
- *Малай тузан сөртә.*
- *Малай кер үтүкли.*
- *Малай чүп чыгара.*
- *Малай идән себерә.*
- *Малай ашарга пешерә.*
- *Малай урынын җыя.*
- *Малай идән юа.*
- *Малай сеңлесенә булыша.*

**Укытучы:** - Укучылар, бу җөмләләрне ничәнче затта кулландык? Ә хәзер беренче затта кулланып карыйк әле. Җөмләләр үзгәрерме?
***Укучылардан көтелгән җаваплар:***
*Мин идән суыртам. (бу формада җавапларын дәвам итәләр)*

**Укытучы:** - Укучылар, дустыгыздан сорагыз әле, ә ул сезгә җавап бирсен. *(Слайд 3)*
***Спросите у товарища, помогает ли он маме:***
- *что он делает?*
- *поливает ли он цветы?*
-*вытирает ли он пыль?*
- *подметает ли пол?*
- *заправляет ли постель?*

- Укучылар, тактагакарагызәле. Диалогларга кирәкле репликаларны өстәп, үзара сөйләшегез. ( бу эш төре группаларда эшләнә, барлыгы 3 группа) *(Слайд 4)*
**1.** - Коля, син өйдә булышасыңмы?
- ........ .
- Нәрсә эшлисең?
- ...... .
- Син тагын кемгә булышасың?
- ......... .
**2.** - Ләйлә, син аш пешерә беләсеңме?
- ....... .
- Тагын нәрсә пешерә беләсең?
- ...... .
- Син торт пешерә беләсеңме?
- .....
**3.** – Азат, син дәү-әниеңә ничек булышасың?
- ..... .
- Чәкләргә су сибәсеңме?
- ..... .
- Сиңа дәү-әниеңә булышырга ошыймы?
- ...... .

**Укытучы:** - Бик әйбәт җавап бирдегез. Әйдәгез бер уен уйнап алыйк. Сүзләр адашканнар, дөрес итеп җөмләләрне төзергә кирәк. *(Слайд 5)*
*Мин тәлинкә ашыйм.- мин тәлинкә юам*
*Син идән пешерәсең.- син идән себерәсең*
*Син аш юам.-син аш пешерәсең*
*Син китап себерәсең. –син китап укыйсың*
(укучылар җөмләләрнең дөрес формасын әйтәләр)

- Дәресебезне дәвам итәбез. Аерым сүзләрдән җөмләләр төзегез. (*Слайд 6)*
*Без, эшчән, түгел, балалар, ялкау, без.*
*Кунаклар, килә, җыештырабыз, шуңа күрә, өй , бүген, безгә.*
*Мин, булышам, әнигә.*
*Барлык, тырыш, эшчән, балалар, сыйныфта, һәм, безнең.*

- Дәвам итәбез. Бирелгән җөмләләрне дәвам итегез. *(Слайд 7)*
*Мин бүген булыша алмый, чөнки ...*
*Мин савыт-саба юа алмыйм, чөнки ...*
*Мин тырыш кыз, чөнки ....*
*Мин әнигә булышам, чөнки ......*
*Әнинең өйдә эше күп, шуңа күрә ...*

- Ә хәзер укучылар тәрҗемә итеп алыйк әле. (*Слайд 8)*

***Как скажете о том, что:***
- *дома очень много работы;*
- *вы  помогаете маме;*
- *вы умеете варить суп;*
***Как попросите сестренку:***
- *быстрее одеться;*
- *подмести пол;*
- *отвести братика в детский сад;*
- *поставить чайник;*

- Сезнең өстәлегездә карточкалар, анда төрле хәрефләр бирелгән, ул хәрефләр буталган **буталган,** алардан булышу темасына караган **сүзләр** төзергә кирәк.

Слайд 9
и,ә,д, н, с, р,е,е, б, ә- идән себерә
к,е,р,а,ю- кер юа
с,с,а,а,ю,в,ы,т,б- савыт-саба юа
ү,т,к,ү,и,л,р,е,к- кер үтүкли
ч,р,т,а,и,т,с,а,р,б,г,ң,е,ә,ә,р- бәрәңге читарта
ш,е,п,а,ш,р,е,ә- аш пешерә
с,с,у,и,б,ә- су сибә
с,т,у,з,ө,р,т,а,н,ә - тузан сөртә
б,з,е,б,л,ы,ч,л,р,а,ы,ш,у,- без булышчылар

- Укучылар, бик дөрес җавап бирдегез.

**XII. Рефлексия**

- Әйдәгез, дәресебезгә йомгак ясыйк. Укучылар без бүгенге дәресебездә нәрсә турында сөйләштек?

Без кемнәргә булышабыз?  Ничек булышабыз? (укучылар җавап бирәләр)

**Өй эше.**

**11. “Мин өйдә зур булышчы” темасына хикәя язып килергә.**
**12. Тема буенча диалог төзергә.**
**13. Мәкаль табып килергә.**

- Сезнең алдыгызда карточкалар бар, үзегезгә бәя бирегез әле. Сез бүгенге дәрестә ничек эшләдегез? Ничек катнаштыгыз?

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ 10 НЧЫ ГИМНАЗИЯСЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

**17 нче апрель, 2017 нче ел**

республиканский семинар - стажировка для учителей татарского языка и литературы общеобразовательных организаций Республики Татарстан по теме «Технологии преподавания татарского языка» в рамках реализации дополнительной профессиональной программы повышения квалификации: «Обучение татарскому языку и литературе в билингвальной среде в условиях реализации ФГОС ОО: теоретический и прикладной аспект»

# “Обучение татарскому языку и литературе в билингвальной среде в условиях реализации ФГОС ОО: теоретический и прикладной аспект”

## “Ике телле мохитта ББО ФДББС гамәлгә ашыру шартларында татар телен һәм әдәбиятын укыту: теоретик һәм кулланма ягы”





**Әсәдуллина Фәния Фарук кызы,**
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 10 нчы гимназиясенең I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәрес темасы:** Табигать һәм без.
**Сыйныф:** 6 В
**Дәреслек:“Татар теле”, 6 нчы сыйныф. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). Авторлар: Р.З.Хәйдәрова, З.Р.Нәҗипова. Казан, “Татармультфильм ”нәшрияты , 2014.**

Федераль дәүләт белем стандартына ачыклык кертүче Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән үрнәк программа:“Рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар теле һәм әдәби уку”, төзүче-авторлары: К.С.Фәтхуллова, Р.З.Хәйдәрова, Казан, 2013.

Әлеге дәрестә укытуның традицион метод һәм алымнары белән беррәттән яңа педагогик технологияләр дә кулланыла.

Дәрес балаларның яшь үзенчәлекләрен, яңа дәреснең заманчалыгын, тормыш белән бәйләнешен исәпкә алып төзелде.

Белем һәм тәрбия бирүгә комплексллы якын килеп эш алып барыла.

Дәрескә түбәндәге **максатлар** куелды:

1. **Балаларны шөгыльгә кызыксындыру, сораулар аша табигать турындагы белемнәрне ачыклау.**
2. **Уңай һәм тискәре факторлар турында сөйләшү алып бару.**
3. **Табигатькә сакчыл караш тәрбияләү һәм табигатьне саклауда үзеңнән өлеш кертү теләген уяту. Балаларның сөйләм телләрен баету.**

Укучыларны дәрескә кызыксындыру максатыннан яңа теманы бирүдә проблемалы эзләнү методы элементларын кулландым. Дәрестә һәрбер укучыга үзенең фикерен әйтү мөһим. Бу исә укучыларны үзләрен шәхес итеп тоярга мөмкинчелек бирә. Дәрес барышында укучыларның белемнәрен, күнекмәләрен, осталыкларын мөстәкыйль рәвештә куллана белү эзлеклелеге тәэмин ителде. Яңа идеялар булган белемнәргә нигезләнеп бирелде, табигать белән бәйләнеш күздә тотылды. Укучыларның белемнәрен бәяләү объектив булды. Өй эше бирү алдыннан әзерлек эше алып барылды. Гомумән алганда, дәреснең тәрбияви, белем һәм үсешле укыту ягыннан әһәмияте зур булды, дип уйлыйм.

**Тема:** Табигать һәм без.

**Максат:**

1) Дидактик максат: Укучыларның лексиканы куллануга шартлар тудыру;балаларның табигать турындагы белемнәрен киңәйтү, табигатьнең кеше тормышында әһәмияте турында балаларның белемнәрен ныгыту, баету.

2) Психологик максат: Укучыларның уйлау(фикерләү) сәләтләре үсүгә йогынты ясау;табигатьтәге уңай һәм тискәре факторларны күрә белергә өйрәтү.

3) Тәрбияви максат: урманда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштерү, табигатькә мәхәббәт тәрбияләүгә йогынты ясау.

**Җиһазлау**: дәреслек, ноутбук, презентация, проектор, А4 форматы кәгазьләре, карточкалар.

**Дәрес тибы**: кабатлау.

**Предметара бәйләнеш:** география, әйләнә-тирә

**Эш алымнары**: индивидуаль, парлап, төркемнәрдә, коллектив.

**Метод һәм алымнар**: укытучы сүзе, сорау- җавап, өлешчә эзләнү, дәреслектән күнегүләр эшләү, карточкалар буенча эш.

**Дәреснең технологик картасы**

| **Дәреснең этаплары** | **Дәреснең барышы** | **Универсаль уку гамәлләре** |
|---|---|---|
| **I.Оештыру моменты. Уңай психологик** | -Исәнмесез,балалар!<br>-Исәнмесез, хәерле көн!<br>-Хәлләрегез ничек? | Коммуникатив:<br>-укытучы-укучы уку хезмәттәшлеген |

| | | |
|---|---|---|
| **халәт тудыру.** | -Сез татар теледәресенәәзерме?<br>Бикәйбәт.Утырыгыз.Дәреснебашлыйк.Ме нәтагынбезнешатландырып,<br>Туганҗиребезгәяңакөнтуды.<br>Яңакөнебезнедәсәламлик.<br>Монынөченбезгәтәрәзәдәнкарапторганкоя шыбызга, көнебезгәелмаергакирәк. | планлаштыру;<br>-иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү. |
| **II. Актуальләштерү.** | 1.Рәсем (картина) белән эш.(1 слайд)<br>-Балалар,әйдәгез, рәсемгә игътибар белән карап, сорауларга җавап бирик әле.<br>-Рәсемдә сез нәрсәләр күрәсез?<br>-Урманда нәрсәләр үсә?<br>-Сез тагын кемнәрне күрәсез?<br>- Сезнеңчә, алар кая бара?<br>-Үзләре белән нәрсә алганнар?<br>Балалар җавабы. | Коммуникатив:<br>-Үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү. |
| **III. Уку мәсьәләсен кую.** | -Балалар, ничекуйлыйсыз, нинди темага сөйләшәчәкбез? Дәреснең темасын билгеләп карагыз әле.<br>Балалар җавабы. Тема билгеләнә.<br>Табигать һәм без.<br>Без дә табигать балалары.<br>-Ә табигатькә чыккач, нәрсәләр эшләргә ярый, нәрсәләр эшләргә ярамый?<br>Балалар җавабы.<br>(уку максатын билгелиләр, белемнәрнең тормышта кайда кирәк булачагын күзаллыйлар)<br>-Балалар, мин сезгә дөрес җаваплар өчен шушы яфракларныөләшәм, ә дәрес ахырында без аларны санарбыз.*(Җаваплар өчен рәсемнәр таратыла.)* | Шәхси:<br>-укуның мөһимлеген(кирәклеген) аңлау хисе;<br>-өйдә шәхси укытуга караганда коллективта белем алуны кулай күрү;<br>-үз мөмкинлекләреңне аңлап, үзеңә дөрес бәя бирү;<br>-үзеңне камилләштерү өстендә эшләргә кирәклекне аңлау;<br>Танып-белү:<br>-танып белү максатын аерып алу һәм мөстәкыйль формалаштыру;<br>-билгеләрен аерып алу максатыннан анализ<br>( мөһим, мөһим түгелләрен |

| | | |
|---|---|---|
| | | билгеләү). |
| | | |
| **IV. Уку мәсьәләсен чишү. Ныгыту.** | 1.<br>-Укучылар, әйдәгез әле хәзер сөйләшеп алыйк.<br>-Балалар, сезнеңчә, нәрсәултабигать? (слайд)<br>-Кеше табигатьтәннәрсәләр ала? (слайд)<br>-Табигатьбезгәнәрсәләрбирә? (слайд) Белемкүнекмәләреүстерү.<br>-Кошларниндифайдакитерә?<br>-Ә без үзебезкошларганәрсәэшлиалабыз?(слайд) Яфракларөләшенә.Календарьдаталар. (слайд)<br><u>2.Ял минуты.</u> “Дөресме, юкмы?” уенын уйнап алыйк әле. Мин сезгә җөмләләр укыйм. Дөрес булса, басасыз; дөрес булмаса-утырасыз.<br>1.Табигать – безнеңдустыбыз.<br>2.Урманда тузанюк, урмандасаф һава.<br>3. Урман безгә агач, тиреләр, җиләкләр, гөмбәләрбирә.<br>4.Урман безгәдаруларбирә.<br>5.2018  ел -Экология елы. (слайд)<br><br>3..Дәреслекбеләнэш. Диалоглар төзү. Парларда эш.<br>113 нче бит, 4 нче бирем.Яфраклар өләшенә.<br><br>4.Шагыйрь <u>Равил Фәйзуллинның “Табигать кочагында”</u> исемле шигырен укыту.(слайд)<br>-Балалар табигать кочагында нишлиләр?<br>-Балалар табигать кочагыннан нәрсәләр алып кайталар?<br>-Балалар урман аланында үзләрен дөрес тоталармы?<br>(Балалар җавабы) Яфраклар өләшенә.<br><br>5.Рәсемнәр белән эш. Дәреслектәге 114 нче бит, 5 нче бирем. | Шәхси:<br>-Яхшы укучы сыйфатын аңлау;<br>-үзеңне камилләштерү өстендә эшләргә кирәклекне аңлау;<br>-үз уңышларыңның һәм уңышсызлыкларыңның сәбәпләрен ачыклау;<br>Коммуникатив:<br>-укытучы-укучы уку хезмәттәшлеген планлаштыру;<br>-конфликтларны чишү;<br>-үзеңнең фикерләреңне тулы һәм төгәл итеп әйтеп бирә белү;<br>-әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра алу,<br>тыңлый белү; сорау кую, җавап бирә белү;<br>-аралашу кагыйдәләрен истә тотып, эзлекле,<br>төгәл итеп сөйли белү, әңгәмә оештыру<br>Регулятив:<br>-максат кую;-прогнозлаштыру;-контроль;<br>-коррекция;<br>-бәяләү;-ихтыяри |

| | | |
|---|---|---|
| | -Кешеләр урманга нинди зыян салганнар?(слайд)<br><br>Сүзлек эше.<br>Сүзләр: чүп-чар, пычрак, ыргыталар, ташлыйлар, сындыралар, янгын, учак.(Слайд.)<br><br>Урманга кергәнчекайбер кагыйдәләрне искә төшерик.<br>Инфинитив фигыль, кушымчалары.(слайд)<br><br><u>-Табигатькә чыккач, нәрсәләр эшләргә ярамый?</u><br>Балалар җавабы. (Яфраклар өләшенә)<br>-Бик дөрес, балалар. Табигатьне нишләргә кирәк?<br>Табигатьне сакларга, яратырга кирәк.<br><br><br>6.<br>- Балалар, сезнең алдыгызда карточкалар ята. Анда җөмләләр бирелгән. Ләкин көчле җил чыгып җөмләдәге сүзләрне бутап бетергән. Әйдәгез, дөрес җөмләләр төзибез. Ребята, сильный ветер перепутал слова в предложениях. Давайте правильно составим предложения. Кем тизрәк төзеп бетерер икән?<br>1.Кирәк, табигатьне, яратырга.<br>2.Татарстанның, суларга, бай, урманнарга, табигате.<br>3.Чыганагы, сәламәтлек, табигать.<br>4.Табигатьне, яратырга, кеше, тиеш.<br>Җөмләләрне балалардан укытып чыгу.<br>- Әйдәгез, хәзер дөрес җавапларны тикшерик һәм нәтиҗә ясыйк.<br>*Нәтиҗә:* -Рәхмәт балалар, сез бу биремне дә дөрес үтәдегез.Яфраклар өләшенә.<br>Ситуатив күнегүләр.(слайд) | үзрегуляция;<br>Танып-белү:<br>-кирәкле мәгълүматны эзләү;<br>-белемнәрне структуралаштыру;<br>-аңлап әйтеп бирү;<br>-кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;<br>-фикерләүдә логик чылбыр төзү. |
| **V.Рефлексия. Үзбәя.** | -Димәк, укучылар бүгенге дәрестә без нәрсәләр белдек? | Коммуникатив:<br>-мәгълүмат җыю |

| | | |
|---|---|---|
| | -Табигатьне саклар өчен, безгә нишләргә ярый, нишләргә ярамый?<br>- Белгәннәр кайда кирәк булыр диеп уйлыйсыз?<br>- Сезгә күбрәк нәрсә ошады? Нәрсәләр кызыклы булды? Ни өчен?<br>Укучылар, түбәндәге җөмләләрне тулыландырыгыз:<br>Мин бүген дәрестә .... өйрәндем.<br>Миңа .. авыр булды, ләкин мин тырыштым.<br>Без бүген .... өйрәндек.<br>Миңа .. аңлашылды.<br>-Булдырдыгыз, балалар! Мине бик сөендердегез!<br>-Укучылар, дәрес барышында мин сезгә яфраклар тараттым.Ә хәзер мине игътибар белән тыңлагыз һәм санагыз. Билгеләр кую(яфракларны саныйлар). | һәм эзләүдә инициативалы хезмәттәшлек;<br>-иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү<br>( контроль, коррекцияләү, аның гамәлләрен бәяләү)<br>Шәхси:<br>-үз уңышларының һәм уңышсызлыгының сәбәпләрен ачыклау;<br>-үзара ярдәмләшү. |
| **VI. Өй эше.** | Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү (слайд)<br>1. Составить рассказ о природе;табигать темасына рәсем бирелә, рәсемгә карап хикәя язарга.<br>2. Составить кроссворд на тему “Природа”;” Табигать” темасына кроссворд.<br>3. Составить диалог на тему “Природа и мы”. ”Табигать” темасына диалог.<br>Саубуллашу. Рәхмәт, укучылар.<br>Дәрескә йомгак ясап, шуны әйтәсе килә, без, булдыра алганча, табигатьне, урманны сакларга, аңа ярдәм итәргә тиешбез. (слайд) | |

**V*II* сыйныфта укучы рус балаларына - татар теле**

**Насыйбуллина Фәнзилә Габбаз кызы,**

***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 10 нчы гимназиясенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

***Тема***: «Алмашлыкларны кабатлау»
***Дәрес тибы***: лексик, грамматик күнекмәләрне камилләштерү
***Дәрес максатлары:***
***Предмет нәтиҗәсе***:

1) Алмашлыкларны сөйләмдә һәм язуда кулланырга өйрәнү;
2) Алмашлыкларны диалог төзегәндә, хатлар язганда урынлы кулана белү;
3) БДТларына әзерләнү

***Метапредмет нәтиҗәсе***: командада эшли белү, үз фикереңне җиткерә, аңлата, дәлилли белү,әңгәмәдәшеңне тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү, үз белемнәреңне бәяли һәм чагыштыра белү, тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.
***Шәхси нәтиҗә***:телне өйрәнүгә уңай мөнәсәбәт тудыру, төрле ситуацияләрне хәл итә белү, яшьтәшләрең , тирә-яктагылар белән итагатьле сөйләшү күнекмәләрен камилләштерү, активлык, мөстәкыйльлек, лидерлык сыйфатлары тәрбияләү.
***Җиһазлау***: дәреслек, дәрес өчен презентацион материал, укучылар өчен терәк сүзлекчә, аудиоязмалар, музыкальбизәлеш.
***Дәреснең барышы***
***1.Оештыру өлеше***:

*(«Что? Где? Когда?» тапшыруыннан музыкаль заставка яңгырый.)*
*Укытучы****:(слайд1)***Бу кайсы телевизион тапшыруга охшаган?
*Укучылар:* «Что? Где? Когда? тапшыруы.»
*Укытучы:* (***слайд 2)***Бүген мин сезгә «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» дигән интеллектуаль уен тәкъдим итәм. Хәзер, әйдәгез, һәр төркемгә капитанны билгеләгез.
*(Капитаннар билгеләнә.Танышып китү.)*

***2.Актуальләштерү-темага чыгу.***
**Укытучы:** Кадерле укучылар, тиздән татар халкының кайсы улының туган көне? Кайсыгыз хәтерли? (Тиздән Габдулла Тукайның туган көне.)
- Дөрес, ә хәзер Тукай турында булган белемнәрегезне кулланып, кроссвордны дөрес чишсәгез, бүгенге дәресебезнең темасын ачыкларбыз.
**(Слайд 3)**
*1. Тукайны кечкенә чакта ничек атыйлар? (Апуш)*
*2. “Шүрәле” поэмасында нинди авыл турында сүз бара? (Кырлай)*
*3. Әнисенең исеме. (Мәмдүдә)*
*4. Г.Тукай иҗатына скульптура ясаган атаклы сынчы. (Урманче)*
*5. Габдулланы тәрбиягә алган карчыкның исеме. (Шәрифә)*
*6. Тукайның туган авылы. (Кушлавыч)*
*7. Тукай Җаекта укыган мәдрәсә. (Мотыйгия)*
*8. Казанда шагыйрьнең музее нинди урамда урнашкан? (Тукай)*
Төркемнәргә кәгазьләрдә бирелә. Эшләп бетергәч, экранга карап тикшерелә.

**(Слайд 4)**

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **А** | п | у | ш | | |
| К | ы | р | **л** | а | й | | | |
| | М | ә | **м** | д | ү | д | ә | |
| У | р | м | **а** | н | ч | е | | |
| | | | **ш** | ә | р | и | ф | ә |
| К | у | ш | **л** | а | в | ы | ч | |
| М | о | т | **ы** | й | г | и | я | |
| | Т | у | **к** | а | й | | | |

1) - Дәресебезнең *темасы* нинди булыр? (Дәресебезнең темасы - “Алмашлыклар”)

-Бу тема буенча дәрестә нәрсәләр эшләрбез? (Алмашлыкларның төркемчәләрен кабатларбыз).
-Дәрестә нинди язучы иҗатына мөрәҗәгать итәрбез? (Г.Тукай иҗатына)*(Үзбәя)*
Укытучы: (***слайд 5)*** Хәзер, слайдка карыйбыз. Бу мәкальләрдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләр турында нәрсәләр әйтә аласыз?Әйдә, бу сүзләрне укып чыгыйк әле.
1.**Кем** эшләми, **шул** ашамый. (Татар халык мәкале.)
2.**Һәр** гөл **үз** сабагында чәчәк ата. (Татар халык мәкале.)
3. **Ни** чәчсәң, **шуны** урырсың. (Татар халык мәкале.)
4.Булма **син** төлке, булырсың көлке. (Татар халык мәкале.)
5.Җир **кемнеке**, икмәге **шуныкы**.(Татар халык мәкале.)

- Бу алмашлыклар турынданиләр әйтә аласыз?
- *Алар исем, сыйфат, сан, рәвеш, фигыльләрне алмаштырып киләләр.*
- *Алмашлыклар сөйләмне кабатлаудан коткаралар.*
- Әйе,укучылар,сез бик дөрес әйттегез.

*Укытучы:* Бүген дәрестә без алмашлыкларны кабатларбыз.
***(Слайд 6)***Хәзербирелгән алмашлыкларны татарча да, русча да әйтеп карыйбыз.
(рус теле белән чагыштырып китәбез) Сүзлек эше ***(слайд7)***
**Кем –кто**
**Шул – тот**
**Һәр – каждый**

**Ни – что**
**Шуны – того**
**Син –ты**
**Кемнеке – кого**
**Шуныкы – того**

3. Димәк, дәресебезнең темасы “Алмашлыкларны кабатлау»***(слайд )***

**Физкультминутка** ***(слайд )***

***4. Дәрес мәсьәләләрен этаплап чишү:***

*Укытучы:* уенны башлыйбызмы?( башлыйбыз)

***Беренче раунд! (слайд )***

***Сезнең алда шигырьләрдән өзекләр бирелгән. Шигырьне сәнгатьле итеп укырга, исемен әйтергә, алмашлыкларны табарга һәм төркемчәләрен билгеләргә.***

1.Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә,
Мөгаллимне олугъ күрсә, белергә кушканын белсә.
(“Бәхетле бала”)

2.Каткан, туңган агачларны хәзер кара:
Һәрбересе яшәрешеп яфрак яра.
(“Яз галәмәтләре”)

3.Тукта,сабрит аз гына, ди, и кадерлеАлмагач,
Һич уенда юк кызык, дәрсем хәзерләп куймагач.
(Эш беткәч,уйнарга ярый”)

4.Һәр тараф тын.Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый;
Нәрсәдәндер күз эленгән һәм тәмам баскан йокы.
(“Пар ат”)

**Шул - күрсәтү алмашлыгы**
**Кайсы - сорау алмашлыгы**
**Һәрбересе - билгеләү алмашлыгы**
**Һич – юклык алмашлыгы**
**Һәр - билгеләү алмашлыгы**
**Әллә ни – билгесезлек алмашлыгы**
**Нәрсәдәндер - билгесезлек алмашлыгы**

Командалар ситуацияләрне чишәләр. (заставка – музыка уйный, яки секундомер) 2 минут вакыт бирелә. Командалар җавапларны әйтәләр.
**Укытучы:**Беренче раундта командадагы эш өчен үзегезгә билге куегыз.

**Икенче раунд (заставка раунд)*(слайд )***

**Җөмләләрне укыгыз һәм биремнәрне үтәгез.**
**- Җөмләләрне текст булырлык итеп билгеле бер тәртиптә урнаштырып языгыз.**
**- Кайсы җөмләдә алмашлык бар?**

**- Ул алмашлыкларның кайсы төркеменә керә?**

***(слайд )***
***1 нче төркемгә***
А. Бу көнне Тукай бүләге лауреатлары билгеле була.
Ә. Бәйрәм Тукайның туган көнендә уздырыла.
Б. Казанда һәр елның апрель азагында Шигырь бәйрәме була.
В. Тукай шигырьләрен укыйлар, җырлар җырлыйлар. (БӘАВ)

**Бу – күрсәтү алмашлыгы**
**Һәр – билгеләү алмашлыгы**

***2 нче төркемгә***
А.Шагыйрь барлыгы 27 ел гына яши.
Ә. Ул калдырган әдәби мирас – милләтебезнең горурлыгы.
Б. Ул бик күп эшли, яза.
В. Габдулла Тукай – әдәбият күгендә иң якты янган йолдыз. (ВӘАБ)

**Барлыгы - билгеләү алмашлыгы**
**Ул – зат алмашлыгы**

***3 нче төркемгә***
А. Алар икесе дә бөек шагыйрьләр.
Б. Тукай – татар әдәбиятын, Пушкин - рус әдәбиятын үстерүче.
В. Аларны зурлар да, кечкенәләр дә яратып укыйлар.
Г.Тукай Пушкинны үзенең укытучысы дип атый. (БАГВ)

**Алар, аларны – зат алмашлыклары**
**Үзенең –билгеләү алмашлыгы**

***Бу раундта үзегезгә командадагы эш өчен билге куегыз. (заставка уйный)***
**Өченче раунд** (заставка раунд)***(слайд )***
Бу раундта бирелгән текстны кабатлаулардан коткарырга кирәк.
***(Слайд 9)***
Текст өстендә эшләү.***(Кулымда конверт.Конверттан хатны алам, экранда хатка таләпләр күрсәтелә)***
Укучылар , безгә Шүрәледән хат килгән. Ачып укыйк әле.
“***Текстны кабатлаулардан коткарырга булышыгыз!***
*Бөек шагыйребез Г.Тукай бик аз гомер эчендә гаять бай иҗат мирасы калдырды. Г.Тукай исән чакта ук татар милләте тарафыннан татар милләтенең рухи юлбашчысы итеп танылды, иҗаты югары бәя алды. Г.Тукайның исеме күңелебезгә бик якын.”*

-Текст матуряңгырыймы?

- *Юк, анда бер үк сүзләр кабатланып килә.*
- Әйдәгез кабатланып килгән сүзләрне алмашлыклар белән алмаштырабыз.
*(Текстны үзгәртеп уку)*
*-Бөек шагыйребез Г.Тукай бик аз гомер эчендә гаять бай иҗат мирасы калдырды. Ул үзе исән чакта ук татар милләте тарафыннан аның рухи юлбашчысы итеп танылды, иҗаты югары бәя алды. Г.Тукайның исеме күңелебезгә бик якын.*
***(Слайд 9)***

## Дүртенче раунд (заставка раунд)***(слайд )***

Бу раундта дустыбызга хат язабыз.***(Кулымда конверт . Конверттан хатны алам, экранда хатка таләпләр күрсәтелә)***

Напиши другу письмо. Сообщи ему(ей):***(слайд)***

1) что сегодня у нас был открытый урок татарского языка;
2) на уроке вы разговоривали о местоимениях;
3) использовали стихотворения Габдуллы Тукая;
4) спроси, слышал ли он о таком татарском поэте.

Укучылар хат язалар(заставка уйный). Хатны бүлешеп языгыз.
***(Слайд 9)***
Хат үрнәге варианты
«Бүген безнең ачык татар теле дәресе булды. Дәрестә без алмашлыклар турында сөйләштек. Габдулла Тукай шигырьләрен кулландык. Ә синең бу татар шагыйре турында ишеткәнең бармы?»

***Рефлексия***

Укытучы: Үзегезне тикшерегез һәм бу раундта билге куегыз. Билгеләү нормаларына таянып, үзегезнең балны санагыз. Командалар уртача балны санап чыгаралар.

Рефлексия: Раундларны искә төшереп китик. Бу раундларда нишләдек? Сөйләп китәләр.*(Без беренче раундта төрле шигырьләрдән өзекләр укыдык. Шигырьнең исемен әйттек, алмашлыкларны таптык һәм төркемчәләрен билгеләдек.*

*Икенче раундта без җөмләләрне текст булырлык итеп билгеле бер тәртиптә урнаштырдык.*

*Без өченче раундта Шүрәлегә ярдәм иттек. Текстны кабатлаулардан коткардык.*

*Дүртенче раундта без дустыбызга хат яздык. Рус телендә бирелгән җөмләләрне татарчага тәрҗемә иттек.)*

Бәяләү битенең икенче ягында белемнәрегезне бәяли аласыз.

Жиңүче билгеләнә, алкышлар. (Иң күп бал жыючы командага 5ле билгесе, калганнарга 4ле билгесе куела).

**Өй эше:**

1) Г.Тукайның Шүрәлесен үзегез күз алдына китергәнчә ясап килергә.

2)Алмашлыклар кергән 5 мәкаль табып өйрәнергә.

3)Дәрестә кулланган элементны кертеп, хатны тулысынча язарга.

**III сыйныфта укучы рус балаларына - әдәби уку дәресе**

***Хафизова Рәйсә Хәмбәл кызы,***

***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 10 нче гимназиясенең***

***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Тема: Кечкенә дусларыбыз. Кем нәрсә ярата?**

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Предмет буенча УУГ:* «Кечкенә дусларыбыз» темасына караган лексик берәмлекләрне сөйләмдә куллануны активлаштыру, камилләштерү; телдән аралашу күнекмәләре булдыру.

*Танып-белү УУГ:* дәрестә алган мәглүматлардан файдаланып, сорауларга җавап бирү; объектларны чагыштыру, аңлап һәм ирекле сөйли белү; белем дәрәҗәсен исәпкә алып, өй эшен сайлау.

*Коммуникатив УУГ:* диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү; коммуникатив максатка нигезләнеп, сүзләрне дөрес, урынлы куллану; үз фикереңне җиткерә белү, парларда эшли белү.

*Регулятив УУГ:* уңай халәт, дустанә мөнәсәбәт тудыру, укытучы ярдәмендә дәреснең максатын һәм темасын билгели белү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу.

*Шәхси УУГ:* татар теленә ихтирамлы караш булдыру; үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләренең кирәклеген аңлау; дүрт яклы дусларыбызга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Дәрес төре:** бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Дәрес тибы:** белем һәм күнекмәләрне ныгыту.

**Метод һәм алымнар:** әңгәмә, өлешчә эзләнү, сорау-җавап, сүзлек эше.

**Предметара бәйләнеш:** татар теле һәм рус теле, музыка.

**Материал һәм җиһазлау:** дәреслек (Татар теле. 3 нче сыйныф: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен) / Р.З.Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова, Л.А. Гыйниятуллина. – Казан: Татармультфильм, 2014), эш дәфтәре, рәсемнәр, карточкалар, компьютер технологиясе.

**Дәреснең технологик картасы**

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|
| **I. Оештыру, мотивлаш-тыру** | Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.<br>– Исәнмесез, балалар. Кәефләрегез ничек? Әйдәгез, бер-беребезгә, | Исәнләшү. Дәрескә әзерлекне күрсәтү. Укытучыны сәламләү, сорауларга җавап бирү, сөйләм | *ШУУГ:* дустанә мөнәсәбәт, укучыга хөрмәт тудыру, үзмаксат кую; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | елмаеп, хәерле көн телик.<br>– Укучылар, тәрәзәгә карыйк әле, бүген көн нинди?<br>– Матур үтсен көнебез!<br>-Көләч булсын йөзебез!<br>-Дөрес,матур утырыйк!<br>-Тырышып җавап бирик! | эшчәнлегенә кушылу. | *КУУГ:* сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү |
| **II. Белемнәрне актуальләш-терү**<br>Фонетик күнегү | – Укучылар, экранда җөмләләр бирелгән. Сезгә аларны укырга һәм кайсы хайван турында сүз барганын әйтергә кирәк.<br>1) *Аның **койрыгы йомшак, колаклары кечкенә, күзләре яшел.** Ул бик чиста. Үзе **сөт** ярата, **тычкан** тота.* (Песи рәсеме күрсәтелә.)<br>2) *Ул **хуҗасын** бик нык ярата. Үзе **озын** колаклы. Командалар үти, тәпен бирә.* (Эт рәсеме күрсәтелә.)<br>– Ә хәзер астына сызылган сүзләрне дөрес итеп укып күрсәтәбез | Укучылар җөмләләрне укыйлар, кайсы хайван турында сүз барганын әйтәләр, астына сызылган сүзләрне дөрес итеп укып күрсәтәләр. | *КУУГ:* дөрес әйтелеш кагыйдәләрен үтәү;<br>*РУУГ:* үз фикерләрен һәм җавапларын телдән дөрес итеп әйтә белү |
| **III. Проблемалы ситуация булдыру. Уку мәсьәләсен кую** | – Укучылар, без бүген дәрестә нәрсәләр турында сөйләшәчәкбез?<br>– Дөрес, яраткан хайваннарыбыз турында. Алар безгә ни өчен кирәк?<br>– Әйе, алар безнең дусларыбыз. Димәк безнең бүгенге дәресебезнең темасы: «Кечкенә дусларыбыз.Кем нәрсә ярата?». Без сезнең белән, өйрәнелгән әсәрләрне искә төшереп, алган белемнәребезне тикшерербез.Экранда язылган сүзләрне бергәләп | Сорауларга җавап бирәләр.<br>Дәреснең темасын билгелиләр. | РУУГ: дәреснең темасын формалаштыру, күзәтүләр нигезендә нәтиҗә ясау, планлаштыру;<br>КУУГ: үз фикереңне төгәл итеп җиткерә белү;<br>ТБУУГ: үзеңнең белем системасына ориентлаша белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | дөрес итеп укыйбыз.<br>-Муен ,йомшак, койрык,хәйләкәр,тәпиләре, колаклары, акыллы, көчле,күзләре.<br>-Бу сүзләр безгә танышмы?(Тәрҗемәсен әйтәләр.)<br>- Экранда бирелгән рәсемнәр буенча җөмләләр төзибез.Эт нишли? Песи нишли?(Эт өрә,йоклый. Песи ашый,уйный.)<br>-Песи нәрсә токкан? (Песи тычкан токкан.)<br>- Кемнең песие бар?(Бер укучы үзенең песие турында сөйли.) | | |
| **IV. Лексик-грамматик күнекмәләр камилләштерү** | – Укучылар, алдыгызда карточкалар ята. Анда татарча сүзләр бирелгән, сезгә аларның янына тәрҗемәсен язарга кирәк.<br>Бәхәсләшәләр-<br>Солы-<br>Сыек-<br>Орлык-<br>Сөяк-<br>Тәмле-<br>Тәмле түгел-<br>– Хәзер партадаш иптәшегез белән эшләрегезне алышынып тикшерәсез.<br>-Бергәләп бу сүзләрне дөрес әйтергә өйрәнәбез<br>– Хәзер бу сүзләр белән җөмләләр төзибез. | Карточкаларда бирелгән сүзләрнең тәрҗемәсен язалар, бер-берсенең эшләрен тикшерәләр.<br>Фонетик зарядка.<br>Сүзләрне кулланып, җөмләләр төзиләр.<br>Лексик һәм грамматик берәмлекләрне бирелгән ситуациядән чыгып кулланалар. | ШУУГ: үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау;<br>КУУГ: коммуникатив максатка нигезләнеп, сүзләрне дөрес, урынлы куллану;<br>ТБУУГ: үз фикереңне төгәл итеп җиткерә белү;<br>РУУГ: биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү |
| **Ял вакыты** | «Елмаю» җырына төрле күнегүләр ясыйлар. | | |
| **V. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту** | – Ә хәзер экранда әкият тыңлыйбыз, хайваннар нәрсә турында сөйләшәләр икән?<br>(«Кем нәрсә ярата?» | Бирелгән әкиятнең эчтәлеге буенча фикер алышалар .Геройларга бәяләмә бирәләр. Диалог, | ШУУГ: белем алу процессына уңай караш белдерү ;<br>ТБУУГ: планнан файдаланып, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | әкиятенең аудиоязмасын тыңлау.)<br>Әкият буенча сорауларга җавап бирәбез.(Группада «Кем нәрсә ярата?» әкияте рәсемнәре буенча җөмләләр төзиләр.)<br>-Песи нәрсә ярата?<br>-Эт нәрсә ярата?<br>-Кәҗә нәрсә ярата?<br>-Әтәч нәрсә ярата?<br>*Ситуатив күнегүләр.*<br>– Узнай у друга:<br>– Есть ли у него кошка (собака);<br>– Что есть его кошка (собака);<br>– Гуляет ли он собакой на улице.<br>*Парларда эш (диалогны тулыландыру).*<br>– Синең песиең (этең) бармы? *(...)*<br>– Аның исеме ничек? *(...)*<br>– Ул нинди? *(...)*<br>– Ул нәрсә ашарга ярата? *(...)*<br>*(Укучылар парларда эшли: башта бер-берсе белән аралашалар, аннан сыйныф каршына чыгып сөйлиләр.)* | монолог төзиләр һәм сөйлиләр | диалогик сөйләм төзү, аңлап һәм ирекле сөйли белү, объектларны чагыштыру ;<br>КУУГ: парларда эшли белү, монологик һәм диалогик сөйләм күнекмәләрен булдыру ;<br>РУУГ: башкаларның сөйләмен тыңлый белү, уку мәсьәләсен дөрес аңлау, үз эшчәнлекләрен планлаштыру |
| **VI. Йомгаклау, өйгә эш** | – Укучылар, бүгенге дәрестә нәрсәләр турында сөйләштек?<br>- Кечкенә дусларыбыз нәрсә ярата?<br>– Кечкенә дусларыбыз ни өчен кирәк?<br>**Өйгә эш.**<br>1) «Минем яраткан песием» дигән темага хикәя язып килергә.<br>2) «Минем дүрт аяклы | Сорауларга җавап бирәләр, әңгәмәдә катнашалар, үз фикерләрен әйтәләр. Өйгә эш алалар | ТБУУГ: фикерне аңлы һәм ирекле рәвештә телдән әйтеп бирү, белем дәрәҗәсен исәпкә алып, өй эшен сайлау;<br>КУУГ: үз фикереңне әйтә белү, тормыш тәҗрибәсен куллану |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | дустым» дигән темага рәсем ясарга һәм аның буенча 3 җөмлә төзергә | | |
| **VII. Рефлексия. Укучыларның белем-күнекмәләрен бәяләү** | – Укучылар сезнең парталарыгызда кояш рәсемнәре бар. Сез кояшның йөзен үзегез ясагыз. Бүгенге дәрестә мин бик актив катнаштым, барысын да аңладым, дип уйласагыз, кояшыгыз көлеп торсын; аңлап бетермәсәгез, кояшыгыз тик торсын; берни аңламасагыз, кояшыгыз еласын.<br>– Дәрестә актив катнаштыгыз, мин сезнең белән канәгать (укучыларның эшчәнлеген бәяләү).<br>– Дәрес тәмам, сау булыгыз | | РУУГ: бәяләү, хаталарны төзәтү ; ШУУГ: үз уңышларың яки уңышсызлыкларың турында фикер йөртү |

**Мингалеева Гөлгенә Хәсип кызы,**

***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 10 нчы гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## Табигать уяна.

(II сыйныф. Рус төркеме)

**Белем бирү максаты**: «Яз» темасы буенча белемнәрне гомумиләштерү, ныгыту, системага салу.

**Фикер сәләтен үстерү максаты**: яңа укыту алымнарын кулланып, укучыларның аралашу күнекмәләрен, логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын үстерүгә ярдәм итү; диалогик һәм монологик сөйләм телләрен үстерү.

**Тәрбияви максат**: укучыларда туган як табигатен саклау һәм ярату хисе тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

**Предмет**: өйрәнгән сүзләрне грамоталы итеп сөйләү күнекмәләрен тикшерү.

**Метапредмет**: балаларның алган белемнәрен күзәтү, ныгыту, бәяләү күнекмәләрен формалаштыру.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

*регулятив универсаль уку гамәлләре:*укытучы ярдәме белән бурычларны билгели белү, укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;

*танып белү универсаль уку гамәлләре:* үз фикереңне язма һәм сөйләмә рәвештә әйтә белү;

*коммуникатив универсаль уку гамәлләре:* әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, үз фикереңне төгәл әйтә белү;

*шәхес эшчәнлеге:* мәгънәви эшчәнлек танып-белү кызыксынучанлыгын үстерү.

**Җиһазлау**: проектор, экран, карточкалар.

**Дәрес этабы**

**I. Мотивлаштыру- ориентлашу**

Уңай психологик халәт тудыру

– Хәерле иртә, укучылар!

– Хәлләрегез ничек?

– Рәхмәт, яхшы! Күрәм, сез дәрескә әзер.

**II. Уку мәсьәләсен кую**

– Укучылар, мин сезгә бер табышмак әйтәм, ә сез аның җавабын белергә тырышыгыз. Бүгенге дәресебез әлеге табышмакның җавабы белән бәйле булачак

Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде.
Еглап елгалар,
Яшьләр түгелде.
Көннәр озая,
Төннәр кыскара.
Бу кайсы вакыт
Я, әйтеп кара?

– Бу – яз.

– Әйе, яз. Димәк, без бүген сезнең белән нәрсә турында сөйләшербез?

– Яз турында.

**Теманы китереп чыгару**

– Укучылар, бүгенге дәресебез язга багышланган. Экрандагы рәсемгә карагыз әле. Сез анда нәрсәләр күрәсез?

– Дөрес, укучылар. Безнең бүгенге дәресебез дә «Табигать уяна!» дип атала ?

– Кояш елмая. Карлар эри. Агачларда яфраклар күренә. Беренче чәчәкләр күренә.

*(Дәрес темасы слайдка чыга)*

**Дәрес максатын әйттерү**

– Димәк, укучылар, без сезнең белән дәрестә нишлибез?

– Яз турында алган белемнәребезне искә төшерербез, белемнәребезне тикшерербез, бәяләрбез.

**III. Дәрес максатына адымлап ирешү** Яз турында әңгәмә.

*(Компьютерда 3 сурәт: кыш, көз, яз)*

– Укучылар, рәсемнәргә игътибар итегез әле. Бу рәсемнәрдә кайсы ел фасыллары сурәтләнгән?

– Көз, кыш, яз.

– Кыш көне табигатьтә нинди үзгәрешләр күзәтелә?

– Бүгенге көнгә кайсы рәсем туры килә? Кайчан табигать уяна башлый?

– Хәзер нинди ел фасылы?

– Яз көне  нинди үзгәрешләр күзәтелә?

– Бу нәрсә?

– Кояш ничек җылыта?.

– Яз көне кар нишли?

– Өй кыекларыннан нәрсә тама?

– Үсемлекләр нишли?

– Болар нәрсәләр?

– Без кошларга нәрсәләр ясыйбыз?.

– Яз көне безгә нинди кошлар кайта?

**Ситуатив күнегүләр эшләү.**

Скажите что:

– Сегодня день теплый

– Весной капает капель

– Весной тает снег

– Ты любишь весну

– Тебе нравится весна

**Спроси друга** *(парларда эш)*

– Любит ли он весну?

– Играет ли он весной на улице?

Ә хәзер экранга карагыз. Сезнең алдыгызда өч өй: яз, кыш, көз һәм җөмләләр бирелгән. Сез шушы җөмләләргә үз өйләрен табарга ярдәм итегез. Помогите предложениям найти свои домики

**Җөмләләр:**

*Көннәр бик салкын.*

*Кояш җылыта башлады.*

*Кошлар җылы якка киттеләр.*

*Елгаларда бозлар туңа.*

*Урамда гөрләвекләр ага.*

*Кошлар Җылы яктан кайтты.*

*Балалар чаңгыда шуалар.*

*Үләннәр яшел төскә керә.*

*Агачлар яфракларын коя.*

**Физминут**«Яз җитә» җыры.

Укучылар, бергәләп, «Яз җитә» җырын җырлыйлар һәм хәрәкәтләр ясыйлар.

**IV. Рефлексия**

– Без бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләштек?

– Яз билгеләрен тагын бер кат әйтеп чыгыгыз әле.

– Бүгенге максатыбызга ирештекме?

– Укучылар, әгәр сезгә дәрес ошаса, кояш нурларын алыгыз һәм тактадагы кояш тирәли ябыштырыгыз, ошамаса, болыт рәсемен алыгыз.

– Менә безнең язгы кояшыбыз нинди матур булды.

Ул безне һәрвакыт җылытып, шатландырып торсын.

**VI. Үзбәя**

– Укучылар, өстәлдә үзбәя бите бар. Бүгенге дәрестә ничек катнашуыгызга , теманы ничек аңлавыгызга карап билге куегыз.

Дәрестә үз эшчәнлекләренә бәя бирәләр.

| Фамилия ______________________________ | | | | Исем | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Мин аңладым, яхшы эшләдем | Мин аңладым, аз эшләдем | Мин аңладым, ләкин дусларымның ярдәме кирәк | |
| | Яз темасын | | | | |

**VII. Өй эше**

– Кемнәр яшел төскә «плюс» куйдылар –1 нче төр, кем сарыга –
2 нче төр, кызылга – 3 нче төр өй эшен языгыз

Яшел – язгы табигать турында хикәя төзеп сөйләргә өйрәнергә.

Сары – «Яз» темасына диалог төзергә

Кызыл – төшеп калган репликаларны куеп, диалогны тулыландырырга.

– Сау булыгыз. Дәрес өчен рәхмәт. Бәяләү битен җыеп бирегез.

***Хәйруллина Гөлнара Абдул кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 10 нчы гимназиясенең***
***I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Тема:** Табын янында. (5нче сыйныф рус төркеме)
**Дәрес тибы:** Диалогик, монологик сөйләм.
**Максатлар:**
1. Белем бирү максаты: «Табын Янында» тексты өстендә эш. Диалогик , монологик сөйләм телен үстерү, камилләштерү.
2.Үстерү максаты: укучыларның тыңлап, аңлап сөйләм күнекмәләрен, аралашу күнекмәләрен, логик фикерләү сәләтләренен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын үстерүгә ярдәм итү, укучыларның үз фикерләрен дөрес һәм төгәл әйтә белүләренә ирешү, шулардан чыгып нәтиҗә ясый белүләренә ирешү;
3. Тәрбияви максат: Саша үрнәгендә тәрбиялелек, әдәплелек, үз-үзеңне тота белү сыйфатлары тәрбияләү. Табын янында утыру кагыйдәләренә өйрәтү.

**Җиһазлау**.Компьютер,презентация,рәсемнәр, карточкалар.
**Материал**. Дәреслек (Татар теле: Рус урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 5 нче сыйныфы өчен дәреслек (рус балалары өчен) / Р.З.Хайдарова - Тулыл. 2 нче басма.- Казан: Мәгариф, 2011. - 99 бит.).

**Дәрес барышы.**
**I.Оештыру.** Уңай психологик халәт тудыру.
- Хәерле иртә, укучылар! "Көнне яхшы сүз белән башласаң, бөтен көнең яхшы үтәр", - диләр. Әйдәгез әле, бер-беребезне яңа көн белән котлыйк һәм бер-беребезгә елмаеп карыйк.
Бүген дәресебездә, укучылар, кунаклар да бар. Әйдәгез, алар белән дә исәнләшик әле!
(Исәнләшү, дежур рапорты)
-Балалар, дәресебезне башлыйбыз.
- Балалар , бүген сез үзегезгә үзегез билгеләр куясыз. (Поставите себе оценки по следующим критериям. (һәр төркем алдында таблица критерийлар белән)
**II.** Укучылар , карагыз әле, мин һәр төркемгә рәсем әзерләдем. Ул сезнең алдыгызда да , экранда да бар. Һәм шул рәсем буенча бишәр сорау бирелгән. Шушы сорауларга җавап әзерлибез.(2минут) (җаваплар тыңланыла) (рәсемдә табын артында утыручы балалар)
Сораулар:
-Балалар кайда утыралар?
-Балалар ничек ашыйлар?
-Балалар үзләрен табын артында тота беләләрме?
-Бу балалар тәрбиялеме?
-Балаларга үзләрен ничек тотарга кирәк?
- Димәк, балалар, без сезнең белән бүген нинди темага сөйләшербез икән?
- Әйе, дөрес, табын артында әдәплелек кагыйдәләре турында, табын артында үз-үзеңне ничек дөрес итеп тоту турында сөйләшербез, шулай ук “Табын янында ” тексты өстендә эшләүне дәвам итербез.
**III.Теманы актуальләштерү.**
**1**.Үткән дәрестә без “Табын янында”текстын өйрәнгән идек. Әйдәгез шушы текстны искә төшерик әле һәм өй эшен тикшереп үтик әле.
(Экранда текст буенча сораулар, шуларга җавап бирәбез)
- Саша- кем ул?
- Саша салатны, ашны ничек ашады?
- Хуҗабикә ашны кемгә бирде?
- Саша итне ничек итеп алды?
- Саша нинди алманы сайлап алды?
- Саша киткәч, өстәл өсте ничек калды?
**2**. Укучылар, Сашага характеристика бирик әле. Саша нинди малай? (Саша әдәпсез, тәрбиясез, игътибарсыз, саран, пычрак малай. Ул үзен генә ярата, үзен кешеләр янында тота белми).
-Укучылар , Саша кебек булырга ярыймы? Әйдәгез аңа киңәшләр бирик.(Саша, салатны үз янына куйма! Саша, чиста аша!Саша, әдәпле бул!)

**3**. Текстка тагын нинди исем биреп булыр иде? (как еще можно озаглавить текст, можете выбрать названия из 9 го упражнения на стр.100)

**4.-** Укучылар, сезнең алда карточкалар, сез бу җөмләләр хикәянең эчтәлегенә туры киләме? (“Әйе” (+ ) яки “Юк”(- ) язарга.)

| | |
|---|---|
| 1. Мин бүген бер гаиләгә кунакка бардым. | |
| 2. Өстәл өстендә салат белән савыт тора. | |
| 3. Хуҗабикә башта Сашага, аннан соң миңа ашбирде. | |
| 4.Саша авызынчапылдатмыйча, матуритепашады. | |
| 5.Саша кулыбеләнаштанбәрәңгеалдыһәмөстәлгәкуйды. | |
| 6. Саша иңкечкенәалманыалды. | |
| 7.Саша киткәч, өстәл өсте пычрак калды. | |

**4. Экранда бирем.**Скажите другу другу о том,(төркемнәргә бүлеп бирелә)
-что он воспитанный мальчик или девочка.
-что он(она)очень внимательный(ая);
-что вам не нравятся жадные, грязные, невоспитанные мальчики.
-моя мама хозяйка;
-хозяйка накрыла на стол;
- я сын хозяина;
-я выбрал яблоко;
-я выбрал самое вкусное яблоко.

**5. Физкультминут**

- Укучылар, мин берничә балага индивидуаль өй эше биргән идем. Бу текстны үзгәртеп язарга кушкан идем. Әйтик , Саша -тәрбияле малай. Хикәя ничек үзгәрер? Әйдәгез тыңлап китик әле.(балалар үзләренең хикәләрен укыйлар.)
- Сез, балалар, ике төрле Сашаны беләсез. Сез кайсы Сашадан үрнәк алыр идегез? Китапта язылган Сашаданмы, яки үзегез язган Сашаданмы?) Ни өчен? Балалар такта янына чыгып, Саша 1гә, Саша 2 гә туры килгән сыйфатларны магнитлар белән ябыштырып куя һәм билгеләмәләрне антонимнар тәртибендә куярга).

**6.**Яңа текст буенча укучылар бер-берсенә сораулар бирәләр (диалог төзиләр). (экранда тәрбияле Саша турында бер вариант бирелә)
мәсәлән
А) Саша салатны ашый башлыймы? (Юк,ул башкаларны көтеп тора)
Б) Саша ашны ашыгып ашыймы? (Юк ,ул ашны ашыгып ашамый).
В) Саша алманы кайчан ала? (Саша алманы ахырдан ала).
Г) Саша тәртипсез малаймы? (Юк, ул тәртипсез түгел).
Д) Бу текстта Саша нинди? (тәрбияле, әдәпле, чиста һ.б).

**IV.Ныгыту.**

**1.-**Укучылар, ә без үзебезне табын янында тота беләбезме соң? Табын янында үзеңне ничек тотарга кирәк соң? Әдәп кагыйдәләрен искә төшереп алыйк әле.Бу биремне без карточкаларда эшләрбез. Бирелгән сүзләрдән җөмлә төзергә кирәк.
1) Терсәкләреңне өстәлгә куерга ярамый.

2) Авызыңда ризык булганда сөйләшмә.
3) Савыттан иң яхшы кисәкне генә сайлама.
4) Авызыңны чапылдатып ашама.
5) Пычактан ризык ашама.
6) Кулларыңны киемеңә сөртмә, салфеткадан файдалан.
7) Табын янында сөйләшергә ярамый.
8) Алдан ашый башларга ярамый.
9) Тиз ашарга ярамый.

**2.** Табын янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен Каюм Насыйри “Китап әт тәрбия” китабында дә язып калдырган.

**Туксан җиденче тәрбия**

Ашаган вакытта уңга-сулга карама, алдыңа гына карап утыр. Кешенең өлешенә вә кешенең кашыгына күз салма. Табакның уртасыннан алма, бәлки табакның үзеңә таба ягыннан вә читеннән алып аша. Вә алдыңа түкмәенчә вә тамызмаенча аша. Хосусән, мәҗлестә олуг адәмнәр булса, оят булыр. Эт ялаган шикелле, шапырдатып ашама. Дәхи дә тарелканың өстенә ятып ашама, мәҗлестә бу гаеп эштер.

**Наставление девяносто седьмое**

Во время еды не вертись, сиди спокойно, глядя перед собой. Не смотри на кусок и ложку соседа. Не тянись за куском, что лежит на середине блюда, возьми то, что лежит перед тобой с краю. Ешь аккуратно, не капая перед собой,— самому же станет неловко, если придется обедать в почтенном обществе. Не сопи и не пыхти над тарелкой. Не пей суп из тарелки.

**3.**Тактада әдәплелек турында татар халык мәкальләре язылган.Шуларны уку, мәгънәләрен ачыклау

Әдәп базарда сатылмый.
Адәмне адәм иткән -әдәп.
Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт.
Кунак ишегеңне ачса, син йөзеңне ач.
Кунак булсаң, тыйнак бул.
Вакытында туя бел,кашыгыңны куя бел.
-Сез бу мәкальләрне ничек аңлыйсыз?

**VIII.Йомгаклау.Нәтиҗә.**

-Балалар ,без бу дәрестә сезнең белән нәрсәләр эшләдек?
-Укучылар, ничек уйлыйсыз,бу дәрес сезнең өчен файдалы булдымы?
- Сез бик тәрбияле балалар икәнсез. Бик сөендем. Минем дә сезгә әйтәсе сүзем бар.
- Әти-әнидән алда табын янына килеп утырмагыз.
- Әти-әнидән алга ашка сузылмагыз.
- Сыныгыгызны ашап бетерегез.
- Ипи валчыгын коеп ашамагыз.

**Өй эше бирү.**

1. “Табын янында” текстын сөйләргә.
2. “Табын янында” темасына диалог төзергә

3. Сашага үз-үзен тоту буенчакиңәшләр бирергә.(Какие советы вы бы дали Саше?)

**Бәя кую**

- Ә хәзер, балалар, үзегезнең дөрес җавапларыгызны саныйсыз һәм үзебезгә үзебез билге куябыз (1-2дөрес җавап -3ле; 3-4 дөрес җавап – 4ле; 5 һәм күбрәк дөрес җавап -5ле билгесе куела)

**Саубуллашу**

***Мингалиева Дания Рәфкать кызы,***
***Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре 10 нчы гимназиясенең***
***татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

**Дәрес темасы:Татарстан – минем республикам**

**Максат**:

—укучыларның Татарстан Республикасы турында белемнәрен арттыру һәм ныгыту; өйрәнгән сүзләрне диалогик, монологик сөйләмгә кертү;

— тыңлап аңлау, аңлап сөйләү күнекмәләрен камилләштерү, укучыларны актив аралашуга тарту; төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен үстерү; бердәм эшләргә, белем алырга өйрәтү;

— туган илебез, Ватаныбыз белән горурлану, аны ярату хисләре тәрбияләү; укучыларның иҗади активлыгын арттыру.

**Җиһазлау:** Татарстан турында альбомнар,төрле биремнәр язылган карточкалар; рәсемнәр, компьютер, презентация.

**Материал:** 4 нче сыйныф өчен татар теле дәреслеге (Р.З.Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова, Л.А.Гыйниятуллина).

**Дәрес тибы:** кабатлау.

**Метод һәм алымнар:**практикум-дәрес, биремнәрүтәү.

*Укучылар дүртәр кешелек төркемнәргә бүленеп утыралар.*

**Дәрес барышы.**

**I.Оештыру өлеше.**

**1. Уңай психологикхаләттудыру.**

— Хәлләр ничек?*(Җиңелчә генә җилкәне җилкәгә тидерү.)*

—Кайда булдың?*(Йомшак кына итеп колак яфрагыннан тоту.)*

— Мин сагындым! *(Кулны күкрәккә кую.)*

— Син килдең! *(Кулларны җәю.)*

— Мин бик шат.*(Кочаклашу, кул кысышу.)*

**2.Дежур укучы белән әңгәмә.**

- Синең исемең ничек?
- Синең фамилияң ничек?

-Синең милләтең нинди?

-Син кайда яшисең?

-Яшел Үзән шәһәре нинди республикага керә?

- Син ничәнче сыйныфта укыйсың?

***II. Актуальләштерү.***

**Укытучы.** Укучылар, мин сезгәшигырь укыйм, игътибар белән тыңлагыз.

*Зур һәм якты*
*Барыр юлларың.*
*Син — туган ягым —*
*Татарстаным!*
Әйдәгез, хәзер бергәләп укыйк, тәрҗемә итик:
зур — *большой*
якты — *светлый*
туганягым — *родной край*
**Укытучы.**Бу шигырь нәрсәтурында,балалар?
**Укучылар.** Туган як турында.
— Нәрсә соң ул Туган як?
— Туган җир, туган ил, Ватан, республика, дәүләт, Татарстаныбыз.
— Шигырьдә Туган ягыбыз турында нәрсә әйтелә?
— Туган ягыбызның юллары зур һәм якты.
— Өстәп, үзегез тагын нәрсә әйтә аласыз**?**
— Безнең Туган ягыбыз — дөньядагы иң матур республика.Татарстан зур, матур һәм бай республика.
— Ә без кайда яшибез?
— Без Яшел Үзән шәһәрендә яшибез.
— Яшел Үзән шәһәре кайда урнашкан?
— Татарстанда.
**Укытучы.** Дөрес, укучылар. Кем әйтә, бүгендәрестә нәрсә турында сөйләшербез икән? *(Җаваплар тыңлана : Туган як, Татарстан, Туган ил турында)*
**Укытучы.**Әйе, без Татарстан турында элегрәк алган белемнәрне искә төшерербез; төрле структуралар кулланып,Татарстаныбыз турында сөйләшүне дәвам иттерербез.
— Әйдәгез, эшне башлыйк. Әйтик, сез чит илдән килгән кунаклар, ди. Сезнең Татарстан турында күбрәк беләсегез килә, ди. Сез нинди сораулар бирер идегез?
**1. Сорауларга җавап бирү.** *(Rally Robinструктурасын кулланып эшләү.)*
**Укытучы.**Биремне үтәү өчен сезгә 1минут вакыт бирелә.
а) индивидуаль эш; ә) «җилкәдәш иптәш» белән тикшерү; б) сыйныфтан «А» тамгалыукучылар«В» тамгалы укучыларгаүзләренең сорауларын бирәләр. «В» тамгалыукучыларҗавап кайтаралар. Дөрес җавап бирсә, мактыйлар.
Сораулар:
1. Син нинди республикада яшисең? (Мин Татарстан республикасында яшим.)
2. Аның башкаласы нинди шәһәр? (Аның башкаласы Казан шәһәре.)
3. Анда нинди истәлекле урыннар бар? (Анда Кол Шәриф мәчете, Кремль, Сөембикә бар.)
4. Татарстанда нинди шәһәрләр бар? (Татарстанда Казан, Әлмәт, Яшел Үзән, Яр чаллы, Болгар шәһәрләре бар). Өстәмә: Буа,Зәй, Мамадыш, Түбән Кама, Чистай, Тәтеш, Норлат, Минзәлә, Лаеш, Алабуга, Әгерҗе, Азнакай, Арча, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Менделеев шәһәрләре.
5. Татарстанның табигате нинди? (Татарстанның табигате бай, матур һәм зур.)
6. Татарстанда нинди елгалар бар? (Татарстанда Идел, Нократ, Кама, Агыйдел елгалары бар.)

7. Кырларда нәрсәләр үсә? (Кырларда иген, арыш, бодай, бәрәңге, карабодай, көнбагыш үсә.)

(*Һәр дөрес җавап өченжетоннар бирелә, ә дәрес ахырында бу жетоннар саны буенча билгеләр куела.)*

**2. Өй эшен тикшерү.**

**Укытучы:**

— Һәр төркемгә Татарстан темасына иҗади эш башкарырга кушылган иде. Хәзер такта алдына чыгып, үз эшегезнеяклларсыз. *(Төркемнәр чыгыш ясый.Чыгыш вакытында альбомнар (яки презентация) күрсәтелә. Укучылар бер-берсен хуплыйлар, мактыйлар.)*

*1 төркем.*Безнең туган илебез – Татарстан республикасы. Ул Россия дәүләтендә урнашкан. Россиянең дә, Татарстанның да үз дәүләт символлары бар. Россиянең дәүләт флагы ак, зәңгәр, кызыл өлешләрдән тора. Дәүләт гербында ике башлы бөркет сурәтләнгән. Флаг (байрак), герб рәсеме.

*2 төркем.* Татарстанның үз гербы, байрагы, гимны бар. Татарстан гербында ак барс сурәтләнгән. Дәүләт флагында яшел, ак, кызыл төсләр бар. Флаг (байрак), герб рәсеме.

*3 төркем.*Татарстан гербында Ак барс сурәтләнгән. Ул республиканың көчле булуын күрсәтә. Татарстан байрагында яшел, ак, кызыл төсләр бар. Ул төсләр яңарыш. Сафлык, яшәү көчен күрсәтә.

*4 төркем.*Гимнның сүзләрен Рамазан Байтимеров, музыкасын Рөстәм Яхин язган. (алдан әзерләнгән ике укучы «Татарстан Республикасы Дәүләт гимны»ннан (Р. Байтимеров сүзләре) өзек укый)

Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,
Халкым тели изге теләкләр!
Гомерлеккә якын туган булып
Яши бездә төрле милләтләр.
Цвети, священная земля моя,
Да будет мирным твой небосвод!
Единый дом у нас, одна семья,
Живет в согласии наш народ.

**III. Төп өлеш.**

**1.Карточкаларга язылган сорауларга җавап бирү.***(Round Table структурасын кулланып эшләү.)* Һәр командага: «Татарстан нинди республика?» дигән сорау куела. Уйлау өчен 1 минут вакыт бирелә. Укучылар *нинди?* соравына җавап бирүче сүзләрнеязарга тиеш. Ләкинсүз кабатланырга тиеш түгел. Ахырдан тикшерәләр: һәр төркемнән 2нче номерлы укучылар җавап бирә. *(4әрләп эшлиләр.)*

*Якынча җаваплар:*бай, зур, матур, искиткеч, әйбәт, бәхетле, безнең, дус, заманча, кадерле, яраткан, көчле, кызык, өлкән (2005 нче елда -1000 ел), туган, файдалы республика.

**2. Диалогик сөйләмне үстерү**. *(Mix-Pair-Share – парларда сөйләшү.)*

**—**Диалогта репликаларны үз урыннарына куегыз.(Кара-каршы сөйләшү килеп чыксын өчен, җөмләләрнең урыннарын үзгәртегез.)

*Янәшә утырган иптәшләре белән парларда эшлиләр. Һәр пар, басып, диалогны сөйләп күрсәтә. Бер-берсен мактыйлар.*

1. — Кичә килдем.
— Казан ошадымы соң?
— Дима,син Казанга кайчан килдең?
— Әйе, бик ошады. Казан — зур һәм борынгы шәһәр.
2. — Әлбәттә, була.
— Автобус яки самолет белән килеп була.
— Ә поезд белән буламы?
— Казанга ничек килеп була?
3. — Син троллейбус белән бар.
— Гафу итегез, аптекага ничек барырга?
— Сиңа кайсы аптека кирәк?
— 14 нче.
4. — Юк, ерак түгел.
— Гафу итегез, икмәк кибете еракмы?
— Урамны аркылы чык та уңга борыл.
— Миңа анда ничек барырга?

**IV.Ял минуты.**(*Mix-Freeze-Groupструктурасын куллану.)*“Әпипә” көенә йөриләр. Музыка туктый. Укучылар «катып» кала. Сорау бирелә. Сораудагы җавап санына карап, төркемнәргә берләшәләр.

— Татарстанның Дәүләт байрагында ничә төс бар? *(Өч төс – яшел, ак, кызыл. Музыка туктауга, укучылар өчәр-өчәр булып берләшә.)*

— Рөстәм Нургали улы Миңнеханов Татарстан Республикасының ничәнче президенты? (*Икенче. Музыка туктауга, икешәр кеше берләшә.)*

— Татарстан аша ничә зур елга ага? *(Дүрт – Идел, Кама, Нократ, Агыйдел.Музыка туктауга, дүртәр кеше берләшә.)*

—Татарстан Республикасында ничә тел — дәүләт теле? *(Ике – рус һәмтатар телләре. Музыка туктауга, икешәрләп берләшәләр.)*

**V.Йомгаклау.**

**1. Әңгәмә өчен сораулар:**

— Дәреснең темасын искә төшерегез. («Татарстан — минем республикам».)

— Татарстан нинди республика? *(Төп өлештәге беренче бирем соравына җавапларны искә төшерәләр.)*

— Татарстан аша агучы елгаларның исемнәрен искә төшерегез. Минем җавапны тулыландырыгыз: Идел, Кама...

— Казанга ничек килеп була? *(Җаваплар тыңлана.)*

— Татарстан Гимнының авторларын әйтегез. *(Җавап бирәләр.)*

— Татарстанда кайсы телләр дәүләт телләре? *(Татар һәм рус телләре.)*

1. **2.Өйгә эш бирү.Белемнәрне бәяләү.** 1.Татарстан шәһәрләре исеме белән ребуслар төзергә.
2. “Казан – Татарстанның башкаласы”- кичәсенә чыгыш әзерләргә, 7-8 җөмлә язырга.
3. 91 нче бит 7 нче күнегү кроссворд чишәргә.

*(Жетоннар саны буенча билгеләр куела.)*

Укучылар алдан әзерләнгән шигырьләрен сөйлиләр.
Айгөл Хәбибуллина “Казан”
Татарстан башкаласы
Бик матур шәһәр Казан.
Заманында Тукай да бит
Шунда шигырьләр язган.

Шәйхи Маннур
Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел.

Нажар Нәҗми “Татар теле”
Туган җирең Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Роберт Миңнуллин “Кунакка килегез!”
Җирнең иң матур җирендә-
Татарстанда торам мин.
Малайлар һәм кызлар! Сезне
Кунакка чакырам мин!

Йөртербез сезне утыртып
Я КамАЗга, я атка
Ашыксагыз – үзебездә
Ясалган самолетка.

Сезне үзебез үстергән
Ипи белән сыйларбыз
Матур итеп Тукай, Җәлил
Шигырьләрен сөйләрбез.

Безнең якларны күрсәгез
Сез шаккатыр идегез.
Дусларыгыз көтә сезне-
Татарстанга килегез.